4 ° 2016

# ФӘННИ ТАТАРСТАН



ISSN 2499-9741

КАЗАН

*Журнал «2014 — 2020 елларга Татарстан Республикасында ТР дәүләт телләрен һәм башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә*

*Массакүләм мәгълүмат чарасын регистрацияләү турындагы таныклык ПИ № ФС77-65242 01.04.2016*

**ЖУРНАЛНЫ ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ

**ИДАРӘ:**

МИҢНУЛЛИН К.М., филология фәннәре докторы, профессор,
идарә җитәкчесе (Казан)
АЛИШИНА Х.Ч., филология фәннәре докторы, профессор (Төмән)
АРСЛАНОВ М.Г., сәнгать фәннәре докторы, профессор (Казан)
БАҺАВЕТДИНОВ Ф.Н., хокук фәннәре докторы, профессор (Казан)
ВӘЛИЕВ Р.И., Татарстан Республикасы Дәүләт Советының мәдәният, фән,
мәгариф һәм милли мәсьәләләр буенча комитеты рәисе (Казан)
ДӘҮЛӘТ НАДИР, тарих фәннәре докторы, профессор (Истанбул)
ГЫЙЛӘҖЕВ И.А., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗАҺИДУЛЛИНА Д.Ф., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ЗӘКИЕВ М.З., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
ҖАМАЛЕТДИНОВ Р.Р., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
КЕРИМОВ И.А., филология фәннәре докторы, профессор (Симферополь)
МИҢНЕГУЛОВ Х.Й., филология фәннәре докторы, профессор (Казан)
МӨХӘММӘТШИН Р.М., сәяси фәннәр докторы, профессор (Казан)
НАСИПОВ И.С., филология фәннәре докторы, профессор (Уфа)
ӨНӘР МОСТАФА, фән докторы, профессор (Измир)
СӘЛАХОВ М.Х., физика-математика фәннәре докторы, профессор,
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты (Казан)
САЛИХОВ Р.Р., тарих фәннәре докторы (Казан)
СИБГАТУЛЛИНА Ә.Т., филология фәннәре докторы, профессор (Мәскәү)
СӨЛӘЙМАНОВ Җ.Ш., техник фәннәр докторы, профессор (Казан)
ТӘСИН ҖӘМИЛ, Бабеш-Больяй университетының Тюркология
һәм Үзәк Азияне өйрәнү институты директоры (Клуж-Напока, Румыния)
ТИМЕРХАНОВ А.Ә., филология фәннәре докторы (Казан)
ФӘТТАХОВ Э.Н., Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары —
мәгариф һәм фән министры (Казан)
ХИСАМОВ Н.Ш., филология фәннәре докторы (Казан)
ХУҖИН Ф.Ш., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШӘЙДУЛЛИН Р.В., тарих фәннәре докторы, профессор (Казан)
ШАМИЛЬОГЛУ ЮЛАЙ, тарих фәннәре докторы, профессор (Мэдисон)

**БАШ РЕДАКТОР**

КИМ МӨГАЛЛИМ улы МИҢНУЛЛИН

**БАШ РЕДАКТОР УРЫНБАСАРЛАРЫ:**

ГОМӘРОВ И.Г., ДӘҮЛӘТШИНА Л.Ш. (җаваплы секретарь)

**РЕДАКТОРЛАР:**

ЗАҺИДУЛЛИН И.К. (тарих), СОЛТАНОВА Р.Р. (сәнгать),
МИРХАЕВ Р.Ф. (тел белеме), ГАРИПОВА Л.Ш. (әдәбият һәм халык иҗаты)

**ГАМӘЛИ ХЕЗМӘТКӘРЛӘР:**

Л.Ш. ГАЛИЕВА, Н.Т. АБДУЛЛИНА, Г.Р. ХӘКИМОВА

**БУ САНДА**

**ТЕЛ БЕЛЕМЕ**

*Йосыпов Ф.Й.* Нагайбәк татарлары сөйләшенең грамматик үзенчәлекләрен өйрәнү тәҗрибәсеннән . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

*Миңнуллин Б.К.* XX гасыр башы татар газетасында мәгълүмати жанрлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17

*Хисамов О.Р.* Татарстан Республикасы топонимнарының электрон картотекасын төзү турында . . . . . . . . . . . . . 21

*Мусабәкова Р.Р.* Татар авыллары исемнәре хакында . . . . . . . . 25

**ФАТИХ ӘМИРХАНГА – 130**

*Ганиева Р.К.* XX гасыр башы татар модернистик әдәбияты һәм Фатих Әмирхан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29

*Гарифуллин В.З.* Фатих Әмирханның журналистлык һәм публицистлык эшчәнлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37

*Гыйлаҗев Т.Ш.* Ф. Әмирханның әдәби-тәнкыйди эшчәнлеге . . 48

*Харрасова Р.Ф.* Ф. Әмирхан хикәяләрендә атама поэтикасы: «Татар кызы» һ.б. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56

*Сәмитова С.Г.* Балалар психологиясен чагылдыруда Ф. Әмирханның иҗади осталыгы . . . . . . . . . . . . . . . . . 63

**ХАЛЫК ИҖАТЫ**

*Хәкимов Р.Ф.* Рекрут җырларында солдат язмышы . . . . . . . . 69

**ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕ**

*Заһидуллин И.К.* «...исемен яхшылык белән сагындырырга җитәрлектер»: Г. Баттал Габделвәли Яушев турында . . . . . . . . 73

*Габделбари Баттал.* Габделвәли Яушев . . . . . . . . . . . . . . 82

**ГАБДУЛЛА ТУКАЙГА – 130**

*Миңнуллин К.М.* Төрки әдәбиятлар бәйләнешләре *(Тукай һәм Сабир иҗатлары мисалында)* . . . . . . . . . . . 94

*Шамилоглу Юлай.* Габдулла Тукай һәм татар үзаңы: чит илдән бер караш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 100

**ШӘХЕСЛӘРЕБЕЗ**

*Гайнуллина Г.Ф., Гафарова В.Р.* Галим, остаз, шәхес *(филология фәннәре докторы, профессор Фәһимә Миргали кызы Хисамова портретына штрихлар)* . . . . . . . . . . . . 106

**ТАТАР ТЕАТРЫНА – 110**

*Салихова А.Р.* Татар театрының үсеш этаплары . . . . . . . . . . 111

*Воронин А.Г.* М.Н. Ермолова исемендәге Мәскәү театры сәхнәсендә Диас Вәлиев һәм Александр Вампилов дебюты . . . 121

*Солтанова Р.Р.* Плакат сәнгатендә татар театры тарихы (1906–1930 еллар) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128
*Абзалина Р.Ә.* Беренче татар спектакльләре *(Рокыя Габитова хәтирәләре)* . . . . . . . . . . . 139
*Вәлиев Р.Р.* Казанда махсус урта театр белеме . . . . . . . . . . 143

**СОЛТАН ГАБӘШИГӘ – 125**

*Галимова Э. С.* Габәши музыкасында фольклор чагылышы . . 148

**СӘНГАТЬ**

*Айдаров Н.Җ.* Музыкага багышланган гомер (*Җ.К. Айдаровның хәтер сандыгыннан)* . . . . . . . . . . . . . . . . 154
*Фәрдиева Д.Р.* XII халыкара мөселман киносы фестиваленә күзәтү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164

**ЯҢА КИТАПЛАР**

*Зәһидуллин И.К.* Алишев С.Х. Галишаһ морза нәселе . . . . . . 169
*Рәмиев З.З.* Ахметова Дина. Габдулла Тукай в фотографиях . . . 175
*Улемнова О.Л.* Татарстан Республикасы Милли музее басмаларына рецензия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 179

**ФӘННИ-ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШЫБЫЗДАН**

**В НОМЕРЕ**

## ЯЗЫКОЗНАНИЕ

*Юсупов Ф.Ю.* Из опыта изучения грамматических особенностей говора нагайбакских татар . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Миннуллин Б.К. Информационные жанры в татарской газете начала XX века . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
*Хисамов О.Р.* О составлении электронной картотеки топонимов Республики Татарстан . . . . . . . . . . . . . . . 21
*Мусабекова Р.Р.* О названиях татарских сел и деревень. . . . . . . 25

## ФАТИХУ АМИРХАНУ – 130

*Ганиева Р.К.* Татарская модернистская литература начала XX века и Фатих Амирхан . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
*Гарифуллин В.З.* Журналистская и публицистическая деятельность Фатиха Амирхана . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
*Гилазов Т.Ш.* Литературно-критическая деятельность Ф. Амирхана 48
*Харрасова Р.Ф.* Поэтика названий рассказов Ф. Амирхана: «Татар кызы» и др. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
*Самитова С.Г.* Творческое мастерство Ф. Амирхана в отражении детской психологии . . . . . . . . . . . . . . . . . 63

## НАРОДНОЕ ТВОРЧЕСТВО

*Хакимов Р.Ф.* Судьба солдата в рекрутских песнях . . . . . . . . 69

## СТРАНИЦЫ ИСТОРИИ

*Загидуллин И.К.* Габдельбари Баттал о Габдельвали Яушеве . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73

## ГАБДУЛЛЕ ТУКАЮ – 130

*Миннуллин К.М.* Созвучие культур в творчестве Тукая и Сабира 94
*Шамильоглу Юлай.* Габдулла Тукай и татарское самосознание: взгляд из зарубежа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .100

## ПЕРСОНАЛИИ

*Гайнуллина Г.Ф., Гафарова В.Р.* Ученый, учитель, личность (к 80-летию доктора филологических наук Фагимы Миргалиевны Хисамовой) . . . . . . . . . . . . . . 106

## ТАТАРСКОМУ ТЕАТРУ – 110

*Салихова А.Р.* Этапы развития татарского театра . . . . . . . . . . 111
*Воронин А.Г.* Дебюты Диаса Валеева и Александра Вампилова на сцене Московского театра имени М.Н. Ермоловой . . . . . 121
*Султанова Р.Р.* История татарского театра в плакатном искусстве (1906–1930 гг.) . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 128

*Абзалина Р.А.* Первые татарские спектакли
*(воспоминания Рукии Габитовой)* . . . . . . . . . . . 139
*Валеев Р.Р.* Средне-специальное театральное образование
в Казани . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 143

## СУЛТАНУ ГАБЯШИ – 125

*Галимова Э.* С. Фольклорные тенденции в музыке С. Габяши . . 148

## ИСКУССТВО

*Айдаров Н. Дж.* Служение музыке:
*(страницы воспоминаний Дж.К. Айдарова)* . . . . . . . . . . . . 154
*Фардиева Д.Р.* XII Международный фестиваль
мусульманского кино . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 164

## НОВЫЕ КНИГИ

*Загидуллин И.К.* Алишев С.Х. Галишаһ морза нәселе . . . . . . 169
*Рамеев З.З.* Ахметова Дина. Габдулла Тукай в фотографиях . . . 175
*Улемнова О.Л.* Рецензия на издания Национального музея РТ . 179

УДК 811.512.145´373

***Ф.Й. Йосыпов***

# НАГАЙБӘК ТАТАРЛАРЫ СӨЙЛӘШЕНЕҢ ГРАММАТИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕН ӨЙРӘНҮ ТӘҖРИБӘСЕННӘН

В предыдущих статьях автора были освещены история формирования говора нагайбакских татаров, их говора и особенности его фонетической системы. Данная статья посвящена изучению грамматических особенностей говора нагайбакских татаров, в частности личных форм глагола. По мнению автора, как в фонетической системе так и в грамматическом строе говора наблюдается много общих черт с татарским литературным языком и говорами среднего диалекта. Это показывает несостоятельность мнения о том, что нагайбаки являются самостоятельным народом, а их язык отличается от татарского языка.

**Ключевые слова:** этнографические группы татарского народа, нагайбаки, диалекты и говоры татарского языка, нагайбакский говор, грамматические особенности, личные формы глагола, изъявительное наклонение, желательное наклонение, повелительное наклонение, условное наклонение.

Грамматика өлкәсендә нагайбәк сөйләше татар әдәби теле һәм урта диалект сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтә. Кайбер күренешләрдә сөйләшнең мишәр һәм көнчыгыш диалектлары белән дә уртаклыгы бар.

Алдагы мәкаләләрдә әйтеп үткәнчә, нагайбәкләрне мөстәкыйль бер халык итеп караргатырышу нәтиҗәсендә, аларның теле дә татар теленнән аерыла дигән карашлар булды. Без биредә, сөйләшнең татар теленә һәм аның диалектларына мөнәсәбәтен ачык күзаллау өчен, әдәби тел белән уртак булган морфологик күренешләргә дә фактлар китерә баруны бурыч итеп куйдык.

**Хикәя фигыль. Нагайбәк сөйләшендә** хикәя фигыль хәл фигыль формаларына нигезләнеп ясала. Сөйләштә хәл фигыльнең *-а, -ә, -й* төренә нигезләнеп ясалган хикәя фигыль киң кулланыла. Белдерә торган мәгънәләре, төрләнеше белән нагайбәк сөйләше әдәби телдән нигездә аерылмый.

Бу өлкәдәге аермалык итеп берлек сандагы фигыльләрнең I зат кушымчасы белән төрләнүдәге кайбер үзенчәлекләрне күрсәтергә мөмкин. Нагайбәк районында яшәүчеләр сөйләшендә хәл фигыльнең *-а, -ә, -й* формасына нигезләнеп ясалган хикәя фигыль беренче зат берлек санда сөйләштәге теләк фигыльләр белән бертөсле үк ясала, ягъни *-ыйым, -ийем (ый + ым, -ий + ем)* кушымчасын ала.

Бу фигыль, әдәби телдәге кебек үк, берничә төрле мәгънәне белдерергә мөмкин:

**1.** Эш-хәлләрнең сөйләү моментында башкарылуын белдерә: *Йуқ, әле җоқламыйым, сезгә*

*иртәгә ашарга ашау пешереп җөрийем. Менә чебешләрне саныйым әле, ничә ҡалган.*

2. Сөйләү моментына карамаган, һәрвакыт гадәти булып тора торган эш-хәлләр турында сөйли: *Мин әр җаз сайын үлән ашы ашыйым. Кешенекен күрмийем мин, белмийем дә. Мин ҡайнараш ашамыйым. Мин җылы сөт эчмийем.*

3. Башлану вакыты ачык билгеле булмаган дәвамлы эш-хәлләрне белдерә: *Ҡарт булсам да эшлийем. Уйлыйым да җөрийем, ни булган дип.*

4. Кайчандыр башланган, ләкин дәвамы белән сөйләү моментына туры килгән эш-хәлләрне ачыклый: *Җырла дигәч, җырлыйым инде. Моңа бороңгы кәлләрне сөйлийем.*

5. Киләчәк заман мәгънәсен белдерергә мөмкин: *Бүген китмийем әле. Килмәсен, мин аңа бупче* (рус. вообще) *бирмийем. Бу арада гына анда бармайым, көтмәсен.*

Хәзерге заман хикәя фигыльнең I зат берлек санын *-ыйым, -ийем* кушымчалары белән төрләндәрү керәшен татарлары сөйләшләренең уртак билгеләреннән санала. Бу үзенчәлек казан арты, Кама буе керәшеннәр сөйләшендә киң таралган [Баязитова, б. 92]. Моннан тыш, хикәя фигыльнең беренче зат берлеген *-ыйым* кушымчасы белән төрләндерү урта диалектның минзәлә [Рамазанова, 1984, с. 98] сөйләше өчен дә хас. Мишәр диалектының Мордва Республикасы [Бурганова, б. 111] һәм Пенза [Махмутова, 1962, с. 144] өлкәсендәге сөйләшләрендә мондый фигыльләр берлек һәм күплектә теләк, боерык мәгънәсендә генә кулланыла.

Чибәркүл районында яшәүче нагайбәкләр сөйләшендә исә хәзерге заман хикәя фигыльнең I зат кушымчаларының тулы формасы *(-мын, -мен)* белән ясау очраклары да күзәтелә: *Мин шунда барамын әле. Мин аны җаҡшы беләмен. Ашарга пешереп йөримен. Уйлыймын да уйлыймын.*

Татар телендә хикәя фигыльләрнең I зат берлегендә зат кушымчасы ике вариантта: тулы *-мын* һәм кыскартылган *-м* кушымчасы белән белдерелергә мөмкин. Урта диалект сөйләшләренең күпчелегендә бу кушымчаның кыскартылган вариантты әйтелә. Хәзерге заман хикәя фигыльнең I зат берлек санын *-мын, -мен* кушымчалары белән төрләндерү керәшен татарларының уртак билгеләреннән санала. Мондый үзенчәлек бигрәк тә әдәби тел йогынтысыннан ераграк булган сөйләшләр (касыйм, нократ-кистем, красноуфим, эчкен, сафакүл) өчен хас. Кыскартылган *-м* кушымчасы белән параллель рәвештә бу форма мишәр һәм себер татарлары диалектларында да шактый актив кулланыла.

Чибәркүл районында яшәүче нагайбәкләр сөйләшендә, сирәк кенә булса да, хикәя фигыльнең *-ып, -еп* формалы хәл фигыль + *утыра,* сирәк кенә *йата* ярдәмче фигыльләре белән ясалган төре кулланыла. Бу форма эш-хәлләрнең нәкъ сөйләү моментында башкарылуын белдерә. Сөйләүче хәбәр ителгән процессның үтәлеше турында үзе хәбәр итә. Зат кушымчалары

ярдәмче фигыльләргә ялгана, ягъни бу фигыльләр хәзерге заман хикәя фигыльләренең төрләнеш закончалыгыннан чыгып үзгәрәләр.

Мисаллар: *Теге монда килеп утыра. Малайлар урамнан китеп утыралар. Тәрәзәләрдән җил кереп утыра. Мин ашарга пешереп утырам. Папау* (эти) *басуга китеп утыра. Сыйыр көтеүдән қайтып җата. Әнә әбийең килеп җата. Анна урамдан китеп җата.*

Эш-хәлләрнең сөйләү моментында башкарылуын *-ып утыра, -ып ята* тибындагы аналитик конструкцияләр белән белдерү ягыннан нагайбәк сөйләше себер татарлары диалекты белән зур уртаклык күрсәтә [Тумашева, 1961, б. 76, 85]. Бу үзенчәлек әлеге диалектның гомум характердагы билгеләре булып санала. Хәзерге заман хикәя фигыльләрнең *-ып утыр, -ып ят* формасы Урал зонасында таралган златоуст, красноуфим, эчкен, сафакүл сөйләшләре өчен дә хас.

Әдәби телдәге кебек үк, нагайбәк сөйләшендә дә *-ды* формалы **категорик үткән заман** башкарылуында бернинди шик булмаган, кабатланмаган, тәмамланган эш-хәлләрне белдерә. Категорик үткән заман формасы, татар әдәби телендәге кебек, сөйләштә дә *-ды, -ты* кушымчалары белән ясала һәм II төр зат кушымчалары белән төрләнә.

Мисаллар: *Кәтүк* (Екатерина) *бирде бу қабақны. Әле кичә генә безгә кергән иде. Син аны сарайга қуйдың. Мәче итен ашамады. Без бу җортны бабай белән салдық. Ул икенче аwылга күчеп китте. Без қоро җиргә утырырга килмәдек, ди қода. Без инде кырга барып җиттек.*

Нагайбәк сөйләшендә *-ды* формалы категорик үткән заман урта диалектның Урал төбәгендә таралган күп кенә сөйләшләрендәге кебек *исә* теркәгече белән килеп, башкарыла торган эш яки хәлләрнең шартын белдерә торган аналитик тезмәләр ясарга мөмкин: *Саудым исә, сөт бирәмен. Китәр бақытлары җитте исә, қодаларның әйберләрен бирә торганнарыйы. Киленнең бүләкләрен урладылар исә, ул аны қақ* (хак, акча) *түләп ала* (туй йоласыннан). *Җылы көннәр җитте исә, урманга чыгалар.*

Категорик үткән заман хикәя фигыльләрнең, *исә* теркәгече белән килеп, шарт мәгънәләрен белдерү ягыннан да нагайбәк сөйләшенең урта диалектның Уралда таралган башка сөйләшләре белән якынлыгы күренә. Шундый сөйләшләрдән нократкистем, минзәлә, бөре, пермь, красноуфим, эчкен, абдулла һәм каргалы сөйләшләрен күрсәтеп китәргә кирәк.

**Нәтиҗәле үткән заман,** әдәби телдәге кебек, нагайбәк сөйләшендә дә *-ган* формалы сыйфат фигыльгә нигезләнә һәм I төр зат кушымчалары белән төрләнә. Үзенең мәгънәләре белән *-ган* формалы нәтиҗәле үткән заман әдәби телдән, керәшен татарларының башка сөйләшләреннән аерылмый. Билгеле булганча, бу заман үткәндә булган, ләкин нәтиҗәсе хәзерге вакытта дәвам иткән эш-хәлләрне белдерә. Берлек һәм күплек саннарда килгәндә, фигыль нигезендәге [н] авазы

кушымчадагы [м], [б] авазлары тәэсирендә ассимиляцияләшә.

Мисаллар: *Син инде бу эштән туйып беткәнсең. Мин барғаммын да барғаммын, анда барасы түгел икән. Ул инде әллә қачан үлгән. Сез аны да күргәнсез икән инде. Парижлар җырлағаннар, без дә җырлыйық әле.*

**Тәмамланмаган үткән заман** нагайбәк сөйләшендә дә, әдәби телдәге кебек үк, *-а, -ә, -й, -и* кушымчалы хәл фигыль һәм *иде* ярдәмче фигыле белән ясала һәм II төр зат кушымчалары белән төрләнә. Ләкин сөйләштә *иде* ярдәмче фигыле, урта диалект сөйләшләренә хас булганча, фонетик яктан үзгәреп, төп фигыльгә кушымча формасында ялганып әйтелә.

Үткән заманның әлеге формасы, әдәби телдәге кебек тәмамланмаган, дәвамлы булган яки кабатланып килгән эш-хәлләрне белдерә. Семантик эчтәлеге белән татар әдәби теленнән аерылмый.

Мисаллар: *Без Нәчти белән бергә барайық, ул лафкадан чығып килә. Сез теге көнне нәрсә эшлийегез? – Бәрәңге алайық. Син андый книгалар уқыйың бит, қарт. Бик күп бороңго җыруларны беләйек, қәзер онотток. Ул көйнө Мәтүк* (Матрена) *тә беләйе.*

Әдәби телдәге кебек үк, бу форма фигыльләр үткәндә башкарылган эшләрнең тәмамланып җитмәвен, аның дәвамлы рәвештә кабатланып торуын белдерә.

**Күптән үткән заман** нагайбәкләр сөйләшендә дә *-ган* формалы сыйфат фигыль һәм *иде* ярдәмче фигыле белән ясала (*барған + ыйы, килгән + ийе*) һәм II төр зат кушымчалары алып төрләнә, урта диалектның күпчелек сөйләшләрендәге кебек, *иде* ярдәмче фигыле, төп фигыльгә кушымча кебек ялганып *(-ыйы, -ийе)*, фонетик яктан үзгәрә.

Үткән заман хикәя фигыльнең *-ган+ыйы (-ган иде)* формасы, әдәби телдәге кебек, үткән заманнан алда булган икенче бер эш-хәлләрне белдерә. Бу фигыль үткәнгә карата перфект мәгънәсен, ягъни эшнең үзеннән бигрәк, аның нәтиҗәсен белдерү үзенчәлегенә ия.

Мисаллар: *Барғаныйық әле кичә генә алар җағына, ул күренмәде. Элек арыш чәчкәннәрийе, булмады, хәзер, бодай ғына инде. Без килеп җиткәндә, афтабуз киткәнийе инде. Әле генә кереп чыққаныйы. Без үскәндә тештемә қуу* (кырау куу йоласы) *беткәнийе. Ышансаң, үзем килермен дигәнийе.*

**Кабатлаулы үткән заманның** сөйләштә берничә төре бар:

1. Хәл фигыльнең *-а, -ә, -й* формасына борынгы *-дыр, -дер* кушымчасы һәм + *иде* (сөйләштә *-ыйы, -ийе*) ярдәмче фигыле ялгау юлы белән ясалган катлаулы аналитик формасы.

Татар теленең урта диалект сөйләшләренә хас булганча, *-адыр + ыйы (иде)* формасы үткәндә булган гадәти, кабатланып торган эш-хәлләрне белдерә: *Барышадырыйық алар белән элек, алар безгә киләдерийе, ашқа йөрешәдерийек. Элек кийәү ат белән чығадырыйы туй бығытында. Җитен үсәдерийе элек бездә. Ул монда буладырыйы. Дәдәй безне бик йаратадырыйы. Ки-*

*беттән ғарыслар* (гарус) *аладырыйық та эшлидерийек.*

Кабатлаулы үткән заманның бу формасын куллануы белән нагайбәк сөйләше урта диалектның казан арты сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтә. Бу форма мишәр диалектында да киң таралган.

2. Сыйфат фигыльнең *-ыр, -ар* формасы һәм *иде* ярдәмче фигыле белән ясалган кабатлаулы үткән заман формасы. Юклык формасы *-мас* кушымчалы нигезгә *иде* ярдәмче фигыле ялгану юлы белән ясала, ә зат кушымчалары *иде* ярдәмче фигыленә ялгана.

Кабатлаулы үткән заманның *-р + ыйы (иде)* формасы урта диалект өчен генә хас булган билгеләрдән санала. Бу форма да, казан арты сөйләшләрендәге кебек үк, югарыда китерелгән *-адырыйы* формасының синонимы буларак, эш яки хәлнең, сөйләү моменты белән чагыштырганда, күптән булып узуын, гадәти, һәрвакыт кабатланып торуын белдерә. Гадәттә, бу хәлләр сөйләүче тарафыннан хатирә рәвешендә искә алына.

Мисаллар: *Без кичен аларға барып утырғанда, шулай дип сөйләрийе. Безнең картлар Бакалы йағыннан килдек дип сөйләрләр ийе. Боронғы заманда шулай чегәннәр җерерләрийе. Уйыннан қайтқанда «Тозға бару» көйөн җырлап қайтырыйық.*

Кабатлаулы үткән заманның бу формасын куллануы белән дә нагайбәк сөйләше урта диалект сөйләшләренә (казан арты, тау ягы, бәрәңге, минзәлә) якын тора [Татар теленең..., б. 636].

3. Сөйләштә аналитик формалы сыйфат фигыльгә *(-а + торған) + иде* ярдәмче фигыле кушылып ясалган *(ала торған идем)* форма да актив кулланыла. Бу заман үткәндә булган гадәти, дәвамлы яки кабатланган эш-хәлләрне белдерә: *Мин җәш бағытта да бик җырлый торғанылым. Алар сату итә торғаннарыйы. Без элек ат белән җөрей торғаныйық. Син бит ул бәйетне әйтә торғаныйың.*

**Киләчәк заман хикәя фигыльнең** сөйләштә өч формасы бар:

1. *-ыр, -ер, -р* формасы. Киләчәк заман хикәя фигыльнең бу формасы *-ыр, -ер, -р* кушымчалы киләчәк заман сыйфат фигыльгә нигезләнә һәм I төр зат кушымчалары белән төрләнә.

Киләчәк заман хикәя фигыльнең *-ыр* формасы сөйләү моментыннан соң үтәләчәк эшләрне билгесезлек төсмере белән белдерә. Сөйләштә I зат берлек формасында тулы *(-мын, -мен)* һәм кыскартылган *(-ым, -ем)* вариантларында кулланыла. Әгәр дә фигыль [р] тартыгына тәмамланса, сыйфат фигыль күрсәткечендәге [р] тартыгы еш кына төшереп калдырыла: *барым* – барырмын, *күрем* – күрермен, *җарым* – ярырмын, *бором* – борырмын.

Әдәби телдән аермалы буларак, сөйләштә кыскартылган вариантлар да кулланыла: *Бозауга каптырым дип, кесәмә ипей тык,к,аныйым. Мин мунчаны үзем булдырып к,айтырым. Карарым әле үзем дә. Мин табарым, син тапмассың. Өйне җыйыштырым син кайтыуга.*

Киләчәк заман хикәя фигыльләрне шушы рәвешчә кыскартып куллану керәшен татарларының башка сөйләшләре өчен дә хас. Әйтергә кирәк, *-ыр* формалы киләчәк заман хикәя фигыльләрне I, II затларда тулы һәм кыскартылган кушымчалар белән төрләндерү татар диалектларының барысында да күзәтелә [Юсупов, с. 71]. Шулай да, Л.Т. Мәхмүтова әйтүенчә, I төр зат кушымчаларны кыскартып куллану аеруча мишәр сөйләшләре өчен хас. [Махмутова, 1978, с. 144].

2. Киләчәк заман хикәя фигыль мәгънәсендә *-асы, -әсе* кушымчалы сыйфат фигыльләр дә шактый актив кулланыла: *Ул да иртәгә барасы әле. Мәтүк* (Матрена) *бу җырны өйрәнеп киләсе. Анда җиләкнең бетәсе дә җук. Бүген балалар машина белән қайтасы. Питүк* (Петр) *бәрәңге алучыларға таwық суйасы.*

Билгеле булганча, *-асы, -әсе* кушымчалы фигыль урта диалект сөйләшләре өчен үзенчәлекле күренешләрнең берсе булып исәпләнә. Бу яктан да нагайбәк сөйләшенең урта диалект, аерым алганда, керәшен татарларының башка сөйләшләре белән зур уртаклыгы күренә.

3. Сөйләштә, сирәк кенә булса да, *-ачак, -әчәк* кушымчалы киләчәк заман хикәя фигыльне куллану очраклары бар. Бу форма, әдәби телдәге кебек үк, киләчәктә һичшиксез башкарылачак яки башкарылырга тиешле эш-хәл турында хәбәр итә: *Алар эрәтләнәчәк хәзер. Мин әйтәчәкмен, ул әйтте дип. Шулай дисәң генә күңелле булачақ. Бәйрәм булды исә, ул тағы қайтып җитәчәк, тағы нәрсә теләсә, шуны эшләп җөрийәчәк.*

Билгеле булганча, *-ачак, -әчәк* кушымчалы сыйфат фигыльләр нигезендә ясалган катгый киләчәк заман формасы, нигездә, урта диалектның казан арты, тау ягы, бәрәңге, минзәлә сөйләшләре өчен хас. Бу форманың нагайбәк сөйләшендә кулланылуы, аның югарыда күрсәтелгән сөйләшләр белән генетик якынлыгы турында сөйли.

**Теләк фигыль.** Сөйләштә теләк, теләк-ният мәгънәләрен белдерә торган түбәндәге формалар һәм конструкцияләр кулланыла.

1. Татар теленең башка сөйләшләрендә дә, теләк фигыльнең төп формасы булып, борынгы *-гай* кушымчалы теләк фигыльләрдән фонетик үзгәреп ясалган формасы кулланыла: *ғай > -ай > -ым+ым; -ый+ық.*

Нагайбәк сөйләшендә бу кушымчалар тар сузыклар белән ясала һәм формасы белән хәзерге заман хикәя фигыльләрнең I заты белән туры килә: *Мин тиз генә сыйыр саwып керийем* (керим). *Бабайның күлмәген җуwыйм* (юыйм) *дип тотындым. Кереп чығыйм* (чыгыйм) *дип кердем. Уйнап қына әйтийем* (әйтим) *дигәнийем. Пидура эштән қайтқанчы, бәрәңге ала торойоқ* (торыйк).

Бу үзенчәлеге белән дә нагайбәк сөйләше керәшен татарларының башка сөйләшләреннән аерылмый [Баязитова, б. 104]. Теләк фигыльләрне тар сузыклы *-ыйым, -ийем* кушымчалары белән белдерү мишәр диалекты-

ның да үзенчәлекле билгеләреннән санала [Юсупов, с. 205].

2. Нагайбәк сөйләшендә *-гай* формалы теләк фигыль, урта диалекттагы кебек үк, юклык кисәкчәсе *-ма* белән генә килә ала һәм булуы мөмкин эш-хәлләрне белдерә. Татар әдәби телендә исә *-гай, -гәй* кушымчалы фигыльләр, моннан тыш, ихтималдан саклану, булырга мөмкин эш-хәлләрне белдерү белән бергә, искитмәү мәгънәсендә дә кулланыла [Современный татарский..., с. 239]: *Җаңғыр җаумағайы әле, чамалағыз. Чиләбегә бармағайық әле бу арада. Син болай сөйләшеп утырғанда, балалар бақчаңны чистартып чықмағайы. Мин дә бу җегет белән Сарашлыға қызларыма китмәгәйем әле. Җәй бик әссе торды, урақ бақытында қына җаңғырлар башланып китмәгәйе.*

Теләк фигыльнең бу төре һәм анда бирелә торган мәгънәсе белән нагайбәк татарларының сөйләше татар диалектының казан арты сөйләшләренә якын тора [Җәләй, б. 25]. Мишәр диалектында һәм урта диалектның тау ягы сөйләшендә мондый фигыльләр искитмәү мәгънәсендә йөри [Татар теленең..., б. 632].

3. *-асы, -әсе* кушымчалы сыйфат фигыль һәм *килә* ярдәмче фигыле белән ясалган аналитик тезмә, татар әдәби телендәгешикелле үк, субъектив теләкне белдерә: *Минем дә барып қарыйсым килә аларның өйләрен. Қунакларның ашыйсылары килә торғандыр инде. Эшлисе килгән кеше эшлисе килә дип кенә сөйләнеп йөрми, эшли дә ташлый.*

4. II зат боерык фигыльгә *иде* ярдәмче фигыле кушылып, киңәш мәгънәсе белдерелә. Ләкин ярдәмче фигыль, әдәби телдән аермалы буларак, зат күрсәткече алмый, зат мәгънәсе *син* алмашлыгы аша ачыклана. Әдәби телдә мондый теләк фигыльләр *-ырга + иде, -ырга кирәк + иде* конструкцияләренә туры килә: *Син тегесен дә алыйы* (ал идең), *монысын да алыйы* (ал идең). *Бәләкәй караватта йатыйы* (ят идең) *син. Син аны әбигә әйтийе* (әйт идең). *Син аны безгә чақырыйы* (чакыр идең).

*Теләк* фигыльнең бу формасы татар теленең Урал төбәгендә таралган сөйләшләрнең күпчелеге өчен хас. Шундыйлардан пермь, златоуст, красноуфим, эчкен, нократ-кистем сөйләшләрен күрсәтергә мөмкин.

Өченче затка караган мондый фигыльләр, әдәби телдәге кебек үк, көчле теләк мәгънәсен белдерә. Бу очракта да зат күрсәткече кыскартып әйтелә: *Ике рәт килсеийе* (килсә иде) *җәш бағытлар. Сүзгә монсо оста булсыйы* (булсын иде), *ичмасам. Мәндә* (кеше) *кеwек* (кебек) *кенә, җақшы ғына җөрсийе* (йөрсен иде).

**5.** *-ыр, -ер, -ар, -әр* формалы сыйфат фигыль һәм *иде* ярдәмче фигыле тезмәсеннән торган форма:

а) беренче зат берлек һәм күплек санда, әдәби телдәге кебек үк, сөйләүченең киләчәктә булачак эш-хәлләрне үтәү, башкаруга булган теләген белдерә: *Мин дә синең белән Сарашлыға барырыйым. Җаңға суйған иттән аш ашарыйым дип уйлағаныйым*

*иртән. Бергәләп, иркенгә чыгып ҹайтырыйык, ичмасам. Икенче килгәндә җыруларның барсын да әзерләп ҹуйарыйык.*

ә) икенче зат берлек һәм күплек санда киңәш, киңәшле теләк, боеру төсмерләрен белдерә: *Син дә барырыйың шунда, кеше барғанда. Айағыңа кийәриең, бүген салҹын бит. Үзеңнең анда барасыңны кийәү артыннан әйтеп җибәрерийең.*

б) киләчәк заман хикәя фигыльнең өченче зат күплеге, *-лар* кушымчасы һәм билгеле бер интонация белән әйтелгәндә, сөйләүченең башкарылырга тиешле эш-хәлләргә үзенең уңай мөнәсәбәтен, теләк-киңәшен белдерә: *Утырырлар, аш әчәрбез. Китерерләр аны өйгә, без барыбер өйдә утырабыз. Аны анда ҹалдырмаслар, җыйыбраҹ куйарлар.*

6. Инфинитивның *-ырга, -ергә* формасы һәм *кирәк* модаль сүзе белән ясалган конструкцияләр теләк, киңәш мәгънәләрен белдерә: *Суймасҹа кирәгийе малларны бу бағытта* (вакытта). *Чәйнекне утыртырға кирәгийе, кайнап чыҹҹан булырыйы инде.*

7. *-мак, -мәк* кушымчалы фигыль + *бул* ярдәмче фигыль белән ясалган тезмәләр ниятле теләк мәгънәсен белдерә. Мондый фигыльләр зат белән төрләнә, зат кушымчасы ярдәмче фигыльгә ялгана:

Мисаллар: *Моннан башымны алып китмәк булам. Син аның белән ничек тормаҹ буласың. Ней күрсәтмәк буласың инде. Ул анда үзе бармаҹ булған.*

Теләк-ният мәгънәләрен белдерә торган бу форма урта диалектның минзәлә, себер татарлары [Тумашева, 1959, с. 177], сирәк кенә подберезье керәшеннәре [Арсланов, с. 23], кайбер мишәр [Махмутова, 1978, с. 75] сөйләшләрендә дә теркәлгән.

8. Татар әдәби телендә ният-максат мәгънәсе *-макчы (-мәкче) + була (бармакчы була), -макчы (-мәкче) + иде (бармакчы иде)* аналитик формалары белән белдерелә; зат кушымчалары өч затта да *була, иде* ярдәмче фигыльләренә ялгана. Нагайбәк сөйләшендә, әдәби телдән аермалы буларак, бу мәгънә үзенчәлекле синтетик форма белән белдерелә:

а) *-макчы* формасы фәкать I зат берлектә генә килә;

ә) зат кушымчасы *-м, -макчы* формасына турыдан-туры ялгана;

б) заман мәгънәсе контекст аша ачыклана: *Көтеүгә берәрсен җаллап та ҹушмаҹчым* (кушмакчы идем, кушмакчы булам), *беркемне дә таба алмыйым. Канфитны җаратмаҹчым* (конфетны яратмакчы идем) *да, ашап бумый, теш начар. Мин аларға бармаҹчым әле* (бармакчы булам). *Уйлап-уйлап, шул йаҹҹа чығып китмәкчем* (чыгып китмәкче булам) *әле. Мин сине аларға алып бармаҹчым* (алып бармакчы идем), *син Мәтүкләргә җыр җазарға киткән.*

*-мәкче* кушымчасы алган *әйтә* фигыле сөйләштә кереш сүз буларак кулланыла һәм әдәби телдәге *әйтмешли* сүзенә туры килә: *Син әйтмәкче* (әйтмешли), *әллә нинди уйлар уйлап утырам. Нәчти әйтмәкче* (әйтмешли), *бөтә керәшен көйләре җазылып беткән. Ул әйтмәкче* (әйтмеш-

ли), *җырчы таwық кеwек берүзем утырам җыру җырлап. Питүк әймәкче* (әйтмешли), *қызық булып китте әле.*

Теләк-ният итү мәгънәләрен күрсәтелгән формалар белән белдерү сөйләшнең үзенчәлекле билгесе булып санала.

Максатлы ният, теләк мәгънәсен сөйләштә тагын *-ырга, -ергә* кушымчалы инфинитив һәм *итә* ярдәмче фигыле белән белдерү дә киң таралган: *Идән җыwарға итә* (юмакчы була) *минем қызым. Мин сыйа пыйма бастырырға иткәйем* (итек бастырмакчы идем). *Бүген буран чығарға итә* (чыгырга җыена). *Бер тазда икегез дә җыwарға итәсезме* (юмакчы буласызмы)? *Менә шу хәлләрне сезгә сөйләргә итәм* (сөйләмәкче булам).

Ният-максат мәгънәсен инфинитив һәм *итә* ярдәмче фигыле белән белдерү татар теленең Уралда таралган сөйләшләренә хас, шундыйлардан пермь [Рамазанова, 1996, с. 21], эчкен, сафакүл, златоуст сөйләшләрен күрсәтергә мөмкин. Бу үзенчәлек башкорт телендә дә күзәтелә. Күрсәтелгән сөйләшләрдә *-ырга + итә* формалы фигыльләрнең кулланылуы башкорт теле йогынтысында барлыкка килгән дип әйтергә нигез бар. Чөнки бу күренеш бигрәк тә башкорт диалектларына күрше булган сөйләшләрдә күзәтелә.

Урта диалект сөйләшләрендәге кебек, ният-максат мәгънәсе *-асы, -әсе + була* (яки *иде)* конструкциясе ярдәмендә дә белдерелергә мөмкин. Мәгънәсе һәм стилистик функциясе белән ул югарыда китерелгән ният-теләк мәгънәләрен белдергән формаларның синонимы булып тора: *Аш пешерәсе булып тотындым. Алар да райунға барасы булғаннар. Иртә белән киләсе булып китте әле ул безгә. Март айында китерәселәрийе, китермәделәр.*

**Боерык фигыль.** Боерык фигыльләрнең формалары һәм мәгънә төсмерләре ягыннан да нагайбәк сөйләше татар әдәби теленнән һәм урта диалектның нигез сөйләшләреннән аерылмый. Билгеле булганча, боеру наклонениесе эшкә кушу, боеру, өндәү, әмер итү мәгънәләрен белдерә. II затның берлек һәм күплек саннарында юклык һәм барлык формаларында килә. II зат берлек санында нуль формасы белән ясала: *Бар әле, дәдәңнең қапчық аwызын тотып тор. Паwыларға әйт, әнисе үзе киләм дигән Чибәркүлгә, бу йалға аwылға қайтмасын. Нәчти безгә қунаққа килсен. Тиз генә кийен, әтийең белән Чибәркүлгә барасың. Сез урамда озақ йөрмәгез, әбиләрегезгә сәғәт бишкә килеп җитегез дидем.*

**Шарт фигыль.** Шарт фигыльләрне куллану буенча да нагайбәк сөйләше әдәби телдән һәм татар теленең башка сөйләшләреннән аерылмый. Сөйләштәдә шарт фигыльләр махсус *-са, -сә* кушымчалары белән белдерелә һәм II төр зат кушымчаларын алып төрләнә:

Билгеле булганча, шарт наклонениесе икенче бер процессның үтәлү-үтәлмәвенә шарт булып килгән эш-хәлләрне белдерә: *Мәтүк* (Матрена) *бағыт тапса, без ул җыруларны җырлап та бирербез әле; Син Сарашлыға*

*барсаң, минем тыwғаннарыма да керерсең; Көннәр салқын торса, малларны суйасы булыр.*

Югарыда әйтеп үткәнебезчә, шарт мәгънәсе *-ды, -де* формалы үткән заман хикәя фигыль һәм *исә* теркәгече белән дә белдерелергә мөмкин: *Ишекне җапмый қалдың исә, хәзер өй сыуwынып қуйа. Ийелеп эшләдем исә, папау* (эти) *бер дә җаратмый.*

Югарыдан күренгәнчә, нагайбәк сөйләше татар теле диалектлары системасыннан читтә тормый. Грамматика өлкәсендә дә ул әдәби тел һәм урта диалектның башка сөйләшләре белән зур уртаклык күрсәтә.

**Әдәбият**

*Арсланов Л.Ш.* Татарские говоры правобережных районов Татарской и Чувашской АССР: автореф. дис.... канд. филол. наук. Казань, 1966. 29 с.

*Баязитова Ф.С.* Говоры татар-кряшен в сравнительном освещении. М.: Наука, 1986. 248 с.

*Бурганова Н.Б.* Говор каринских и глазовских татар // Материалы по татарской диалектологии. Казань, 1962. С. 19–56.

*Җәләй Л.* Татар диалектологиясе. Казан: Татар. кн. изд-во, 1947. 136 б.

*Махмутова Л.Т.* Основные характерные черты мишарских говоров на территории Пензенской области // Материалы по татарской диалектологии. Казань, 1962. С. 125–162.

*Махмутова Л.Т.* Опыт исследования тюркских диалектов. Мишарский диалект татарского языка. М.: Наука, 1978. 271 с.

*Рамазанова Д.Б.* Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии. Казань: Татар. кн. изд-во, 1984. 191 с.

*Рамазанова Д.Б.* К истории формирования говора пермских татар. Казань, 1996. 239 с.

Современный татарский литературный язык. М.: Наука, 1969. 380 с.

Татар теленең диалектологик сүзлеге. Казан, 1969.

*Тумашева Д.Г.* Особенности глагольных форм в тобольском говоре татарского языка // Ученые записки Казанского ун-та. Т. 119, кн. 6. 1959. С. 124–129.

*Тумашева Д. Г.* Көнбатыш себер татарлары теле. Грамматик очерк һәм сүзлек. Казан: Казан ун-ты нәшр., 1961. 241 б.

*Юсупов Ф.Ю.* Историческое развитие неличных и индикативных форм глагола в татарском языке // Вопросы советской тюркологии. Ашхабад, 1985. С. 140–146.

***Йосыпов Феритс Йосыф улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор*

УДК 811.512.145

***Б.К. Миңнуллин***

# XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР ГАЗЕТАСЫНДА МӘГЪЛҮМАТИ ЖАНРЛАР

В данной статье предпринимается попытка систематизации и анализа информационных жанров татарской газеты начала XX в. на примере текстов татарских газет «Вакыт» и «Борхане таракки». Из всех информационных жанров в рассматриваемых газетах чаще всего встречаются заметка и объявление.

**Ключевые слова:** литературный язык, язык газеты, жанры газетного текста, информационные жанры.

Бүгенге көн тел белеме кысаларында галимнәр теге яки бу әдип иҗатының телен фәнни яктан өйрәнүгә зур игътибар бирә. Ләкин шул ук вакытта телнең иҗтимагый тормышның башка өлкәләрендә кулланылышын чагылдыра торган текстлар да юк түгел. Алар арасында вакытлы матбугат битләрендә басылган текстлар аерым бер урын алып тора [Миннуллин, с. 3–4; Мирхаев, Гумеров, с. 49–54].

Билгеле булганча, XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар милли әдәби теленең формалашуында һәм камилләшүендә аеруча мөһим бер чор булып тора. Нәкъ менә XX гасыр башында «татар вакытлы матбугаты» дигән күренеш барлыкка килеп, җәмәгатьчелектә киң таралыш ала. Бүген галимнәр газета текстының жанрлар системасы турында сүз йөрткәндә, аның өч төп төргә бүленүен ассызыклый: мәгълүмати, аналитик һәм әдәби-публицистик жанрлар [Пельт, с. 8].

Мәгълүмати жанрларга иң элек хәбәр җиткерү функциясе хас. Әлеге жанр кысаларында кыска вакыт эчендә һәм җыйнак формада теге яки бу күренеш яисә вакыйга турында хәбәр ителә. Аналитик һәм әдәби-публицистик жанрларга исә тәэсир итү функциясе йөкләнә. Аналитик жанрлар мәгълүмати жанрларга караганда киңрәк вакыт аралыгында языла, аларда фактлар һәм вакыйгалар системасының нигезле өйрәнелеше һәм анализы, логик йомгак урын ала. Әдәби-публицистик жанрлар, нигездә, көчле эмоциональ төсмергә ия.

Тәкъдим ителгән әлеге мәкаләдә без «Вакыт» (Оренбург, 1906–1918) һәм «Борхане тәрәкъкый» (Әстерхан, 1906–1911) газеталары нигезендә XX гасыр башы вакытлы матбугатында урын алган мәгълүмати жанрларга анализ бирүне максат итеп куябыз.

«Борхане тәрәкъкый» газетасында басылган мәгълүмати жанрлар арасында иң киң таралганнарының берсе – заметка (хәбәр). Хәбәрнең төп максаты – билгеле бер вакыт кысаларында укучыга мәгълүмат җиткерү. Әлеге төр текстларның кыскалыгы аларны

әзерләүгә бирелгән вакыт кысаларының чикләнгәнлеге белән аңлатыла. Мәсәлән, «Борхане тәрәкъкый» газетасында басылган хәбәрләрнең күләме бер җөмләдән алып дүрт-биш җөмлә тәшкил итә, ләкин гадәттә алар бер-ике җөмләдән артмый. Әлеге җөмләләр бер баганага урнашкан ун-унбиш кыска юлдан гыйбарәт.

«Борхане тәрәкъкый» газетасында басылган хәбәрләр гадәттә ике төргә бүленә – хроникаль һәм кыска хәбәрләр. Әлеге текстлар, нинди төрдән булуларына карамастан, төрле рубрика кысаларында блоклап биреләләр. Хәбәр жанры иң еш басыла торган рубрикалардан, мәсәлән, «Русия хәбәрләре», «Хаҗитархан хәбәрләре» һ.б. яисә «Хаҗитархан февраль 21», «Хаҗитархан октябрь 15» дип исемләнгән календарь яңалык рубрикаларын атап үтәргә мөмкин. Хәбәр текстларына сирәк очракларда гына исем куела.

Мисал өчен «Борхане тәрәкъкый» газетасында «Русия хәбәрләре» рубрикасы кысаларында басылган хәбәр текстыннан өзекне карыйк: [kief törmäsendä ülem cazasyna xökem qylynğan palitičiskiny asarğa palač bulyp jallanğač aristant puškofny palač bulğanlyğy öčen iptäš aristantlary qajču berlän 16 cirdän cäräxätlägänlär] («Борхане тәрәкъкый», алга таба – «Б.т.», «Палачны җәрәхәтләгәннәр», № 30, 1906). Югарыда әйтелгәнчә, әлеге рубрика берничә кыска информацион текст – хәбәрдән гыйбарәт. Бу очракта һәрбер текстка үз исеме куела.

Хәбәр жанры «Вакыт» газетасы битләрендә дә киң кулланыла. «Борхане тәрәкъкый» газетасыннан аермалы буларак, «Вакыт»та гадәттә киңәйтелгән хәбәр еш очрый. Алар ярдәмендә автор күренеш яки вакыйга турында мәгълүмат кына биреп китми, ә бәлки аларның сәбәпләрен һәм нәтиҗәләрен дә ачып бирергә тырыша. Бу исә текстның күләменә дә йогынты ясамый калмый. «Вакыт» газетасында басылган хәбәрләр шулай ук блоклап «Оренбург хәбәрләре», «Рәсәй хәбәрләре», «Әтраф хәбәрләре», «Рәсми хәбәрләр» кебек рубрикаларда аерым-аерым исемнәр астында бирелә. Мисал өчен чираттагы хәбәр текстының өзеген карыйк: [20 nče januarda fiadosija qalasyna berenče partija xacilar ilä ruski obšesyvanyŋ tsaritsa paraxody kilde. bunda 1,140 xaci qajtty…] («Вакыт», далее – «В.», «Хаҗиларның кайтуы», № 426, 1909). Әлеге текстның «Хаҗиларның кайтуы» дигән үз исеме бар, шул ук вакытта ул укучыга «Рәсми хәбәрләр» дип исемләнгән рубрика эчендә берничә хәбәр белән бер рәттән тәкъдим ителә.

Без тикшерә торган газеталарда еш кулланыла торган тагын бер мәгълүмати жанр – отчет (хисап). Әлеге жанрның максаты теге яки бу фактны яисә вакыйганы җентекле рәвештә укучыга җиткерү. Хисапның күләме хәбәр жанры белән чагыштырганда сизелерлек дәрәҗәдә арта. Гадәттә әлеге төр мәгълүмати жанрның тексты сөйләм теленә якын тора. Газетада нигездә теге яки бу җыелыш, конференция, очрашу һ.б. чараларга багышланган хисаплар урын ала. Хисап, күптән түгел

булып узган чараны, аның реаль хронологик кысаларына нигезләнеп чагылдыра. Хисап авторы бары тик фактлар һәм детальләрне сайлап алуда гына катнаша [Гуревич, с. 26].

«Борхане тәрәккъый» газетасында хисаплар сирәк очрый, ә басылганнары – турыдан-туры хисаплар. Әлеге хисапларның текстында авторның катнашы аеруча чикләнгән була, сөйләүченең чыгышы укучыга сүзгә сүз тапшырыла. Мисал өчен «Борхане тәрәккъый» газетасында басылган «Г. Думаның 26 февраль җыелышында Садри әфәнде Максудов нотыгы» дип исемләнгән хисаптан өзекне китерәбез: [xalyq wäkilläre äfändelär!.. xökümätneŋ bezgä mönäsäbäte alyšuynyŋ berničä säbäpläre bar. İŋ möhime mämläkät säjäsätendäder ki... kinät mämurlar wä xökümät möselmanlarnyŋ inarodis bulğanlyğyn iskä töšerdelär...] («Б.т.», «Г. Думаның 26 февраль җыелышында Садри әфәнде Максудов нотыгы», № 139, 1911).

«Вакыт» газетасында шулай ук турыдан-туры хисаплар гына басылган, ләкин «Борхане тәрәккъый» газетасыннан аермалы буларак биредә алар ешрак очрый. Мәсәлән, «Вакыт» та басылган хисаптан өзек: [g. dumada din kamisiasy ber dindän ikenče dingä küčü xaqyndağy läixäne tämam qabul itmešter. kamisianyŋ läixäse ošbudyr. berenče maddä: 21 jäšenä etkän här ber kešegä här ber törle din wä mäzhäbkä küčärgä irekter...] («В.», «Диндә иркенчелек», № 433, 1909).

Тикшерелә торган газеталарда урын алган мәгълүмати жанрлар арасында игъланнар еш очрый. Игъланнарны без ике төргә бүлеп карыйбыз: мәгълүмати һәм сату-алу игъланнары. Танылган тел галиме М.Н. Кожина ассызыклаганча, XX гасыр ахырында әдәби телнең кулланылыш даирәсе киңәюе нәтиҗәсендә, шул исәптән публицистик стильдә дә, сату-алу игъланнары аеруча таралыш ала [Кожина и др., с. 387]. Шунысы үзенчәлекле, сату-алу игъланнарының татар вакытлы матбугатында инде XX гасыр башында ук, ягъни татар газета-журналлары барлыкка килгәннән башлап, киң кулланылганлыгы күренә. Бүген тел галимнәренең бер өлеше сату-алу игъланнарының югары дәрәҗәдә социальләшкән булуын күздә тотып, аларны публицистик стильгә караган текстларга кертәләр. Галимнәрнең икенче өлеше исә, әлеге текстларда башка функциональ стильләргә караган үзенчәлекләрнең дә булуына нигезләнеп, сату-алу игъланнары текстларының күпстильле булуын ассызыклый.

«Борхане тәрәккъый» газетасында сату-алу игъланнары мәгълүмати игъланнар белән чагыштырганда сирәгрәк очрый. Мәсәлән, мәгълүмати игъланга бер мисал китерик: [borhan taraqi matbäğasyna ečmi torğan jaxüd xezmätendän qalmyj torğan xäref cyjučy kiräk] – («Б.т.», «Игълан», № 81, 1907).

«Вакыт» газетасында исә сату-алу игъланнары да, мәгълүмати игъланнар да һәр санда диярлек урын ала. «Борхане тәрәккъый» газетасында сату-алу игъланнары гадәттә соңгы биттә

басылса, «Вакыт»та мәгълүмати жанрларның әлеге төрен һәр газетаның башында да, ахырында да табарга мөмкин. Аерым саннарда сату-алу игъланнарын бастыру өчен тулы бер бит бүленеп бирелә һәм «Борхане тәрәккый» газетасыннан аермалы буларак, «Вакыт»та әлеге игъланнар рәсемнәр белән бизәлә. «Вакыт» газетасында басылган сату-алу игъланына чираттагы мисалны карыйк: [jaŋa basylyp čyqty! qozğynlar ojasynda. šaxtadağy möselman eščelär tormyšyna dair šärif äfände kamal qalämilä jazylmyš ğyjbrätle ber xikäjäder. xaqy 12 tien. počta ilä 14 tien] – («В.», № 700, 1910).

«Вакыт» газетасында басылган сату-алу мәкаләләренең күпчелеге исемсез бирелә, ә «Борхане тәрәккый» газетасында исә мәгълүмати игъланнар да, сатуалу игъланнары да «Игълан» исеме астында басыла. Шунысы кызык, «Вакыт»та басылган кайбер сату-алу игъланнарының текстлары параллель рәвештә гарәп һәм кирилл хәрефләре белән бирелә.

Шулай итеп, «Борхане тәрәккый» һәм «Вакыт» газеталарында басылган мәгълүмати жанрлар арасында иң киң таралганнары – хәбәр һәм игълан жанрлары. Шул ук вакытта хәбәр, аналитик жанрларга карый торган мәкалә жанры белән бер рәттән, безнең тарафтан тикшерелә торган газеталарда күпчелекне тәшкил итә.

**Әдәбият**


*Гуревич С.М.* Газета: вчера, сегодня, завтра. М.: Аспект Пресс, 2004. 288 с.

*Кожина М.Н., Дускаева Л.Р., Салимовский В.А.* Стилистика русского языка. М.: Флинта. Наука, 2008. 464 с.

*Миннуллин Б.К.* Татарская газета «Борхане таракки». Казань: ИЯЛИ, 2012. 300 с.

*Мирхаев Р.Ф., Гумеров И.Г.* Система форм существования татарского языка в конце XIX – начале XX в. // Филология и культура. 2015. № 1 (39). – С. 49–54.

*Пельт В.Д.* Дифференциация жанров газетной публицистики: Учеб.-метод. пособие для студентов. М.: Изд-во МГУ, 1984. 48 с.



***Миңнуллин Бәхтияр Ким улы,***

*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының гомуми лингвистика бүлеге мөдире*

УДК 811.512.145´373

***О.Р. Хисамов***

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТОПОНИМНАРЫНЫҢ ЭЛЕКТРОН КАРТОТЕКАСЫН ТӨЗҮ ТУРЫНДА

Топонимическая система Республики Татарстан формировалась в течение тысячелетий в сложных географических, исторических и лингвистических условиях, на территории, которая постоянно оказывалась местом соприкосновения, взаимопроникновения и сосуществования различных родственных и неродственных этнических потоков. В статье автор знакомит с опытом составления электронной картотеки топонимов Республики Татарстан, где будут отражены результаты исследований, проведенных в этой области.

**Ключевые слова:** топонимия, топонимическая система, топонимы, ойконимы, гидронимы, оронимы, каталог топонимов.

Географик атамалар иң мөһим мәдәният һәйкәлләреннән санала. Төрле телләрдә, төрле вакытта барлыкка килеп, алар кешелекнең күп гасырлык тарихын: табигый яшәү шартларын, матди, рухи һәм мәдәни тормышларын өзлексез үсештә чагылдыралар. Атамалар белән кызыксыну, аларның яшерен мәгънәләрен, аталган объект белән мөнәсәбәтен аңларга омтылу борынгы чорлардан ук килә, өстәвенә мәгариф һәм мәдәният үсешенә бәйле рәвештә әлеге кызыксыну елдан-ел арта бара. Киң даирә укучыларның кызыксынуын канәгатьләндерүнең бер юлы булып – топонимик сүзлекләр төзү тора.

Татарстан Республикасының топонимнар системасы мең еллар дәвамында катлаулы географик, тарихи һәм лингвистик шартларда, көнчыгыш, көнбатыш, көньяк һәм төньякның төрле тугандаш һәм тугандаш булмаган халыкларның даими рәвештә кушылу, катнашу һәм бергә яшәү урыны булган территориядә формалашкан. Һәр миграцион дулкын үзеннән соң топонимик катламнар калдырган. Шуңа күрә һәр регионның топонимик системасын географик, тарихи һәм лингвистик яктан комплекслы итеп өйрәнү зарур.

Ономастик, шул исәптән топонимик лексика теге яки бу телнең сүзлек составының аерылгысыз өлешен тәшкил итә. Шуңа күрә географик атамаларның семантикасын ачыклау, лингвистик һәм экстралингвистик факторларның атамалар сайлауга тәэсир итү дәрәҗәсен өйрәнү, атама сайлауның мотивларын тикшерү һ.б. хәзерге тел белеменең актуаль мәсьәләләреннән берсе санала.

Топонимик тикшеренүләрнең мөһим бер юнәлеше булып топонимик сүзлекләр төзү һәм географик атамаларның мәгълүмати базасын булдыру тора. Бүгенге көндә дөньяда топонимик сүзлекләрнең төрле төрләре эшләнгән (административ-белешмәле, аңлатмалы-энциклопедик, тарихи-этимологик, сүзясалыш

топонимик сүзлекләр, микротопонимнар сүзлеге һ.б.).

Бу өлкәдә Татарстан топонимиясе бары тик ике сүзлек белән генә тәкъдим ителгән. Болар топонимист галимә, филология фәннәре докторы Ф.Г. Гарипованың икешәр томлык «Татарстан гидронимнары сүзлеге» [Гарипова 1984, 1990] һәм «Татарстан микротопонимнары сүзлеге» [Гарипова 1992, 1993]. Әлеге сүзлекләр бу эшчәнлекнең беренче тәҗрибәсе булып торалар һәм алар иңләгән атамаларның күләме һәм топонимик материалның тасвирлау ягыннан укучыны бүген тулысынча канәгатьләндерә алмыйлар.

Татарстан Республикасының географик атамалар каталогын топонимиканың барлык аспект һәм юнәлешләрен чагылдырачак комлексłы сүзлек рәвешендә төзү планлаштырылды. Ул үзендә аңлатмалы-энциклопедик, тарихи-этимологик һәм норматив-белешмәле сүзлекләрнең принципларын берләштерәчәк.

Каталог үз эченә барлык төр географик объектларның атамаларын – ойконим, гидроним, оронимнарны туплый. Анда атамаларның яңа һәм иске төрләре дә, шулай ук әлеге атаманың башка барлык вариантлары, шул исәптән халык-сөйләмә телендә генә кулланылган вариантлары да кертеләчәк. Каталог 6000 (6600) нән артык топонимны иңләр дип планлаштырыла.

2010 ел халык исәбен алу мәгълүматлары буенча Татарстанда 3113 торак пункт, шул исәптән 22 шәһәр, 18 шәһәр тибындагы бистә һәм 3073 авыл бар. Шулай ук республикада географик ландшафт бик үзенчәлекле булуы белән характерлана. Болар барысы да бай һәм күптөрле топонимик система булдыруның объектив нигезен тәшкил итә.

Татарстан төрле милләтләрнең очрашу, контакт зонасы. Шуңа да әлеге проект татар топонимнарының картотекасын төзүне генә түгел, ә бүгенге көндә республикада булган барлык топонимнарны да туплауны күз алдында тотып тормышка ашырыла. Шул исәптән юкка чыккан торак пункт атамаларын да.

Мәгълүмати-аналитик система ике компоненттан тора: мәгълүматлар базасы һәм картографик мәгълүматларны саклау һәм эшкәртү чарасы. База Интернет челтәренә махсус сайт рәвешендә куелыр дип планлаштырыла.

Географик атамаларны өйрәнгән вакытта картографик анализ методлары топонимик тип һәм модельләр ареалын билгеләргә мөмкинлек бирә.

Ареаллаштыру һәм алынган ареалларны интерпретацияләүнең теоретик нигезе итеп топонимның билгеле бер система кысаларында, географик һәм хронологик яктан билгеләнгән, билгеле модельләр буенча барлыкка килү күренешләрен өйрәнү алына. Нәкъ шундый системалылык топонимияне шактый ышанычлы күп телле тарихи-мәдәни чыганак итә дә. Топонимия торак пунктның формалашу һәм урнашу тарихын, халыкның күченү вакытын, этник багланышларны, төрле хронологик кисешләрдә тел халәтен һәм вәзгыятен өйрәнү мөмкинлеген бирә.

Компьютер технологияләрен куллану субстрат топонимияне тикшерүдә дә үз нәтиҗәләрен күрсәтә, чөнки субстрат топонигез һәм топомодельләр үзәген ачыкларга мөмкинлек бирә. Шул ук вакытта төгәл нәтиҗәгә ирешү өчен топонигезнең төрле фонетик вариантларын эзлекле рәвештә картага төшерү һәм бер карта эчендә берләштерү сорала.

Мәгълүматлар базасы «объектив», ягъни махсус фәнни эзләнүләрне таләп итми торган параметрлар җыелмасыннан һәм махсус фәнни эзләнүләр соралган өлешләрдән торачак. Беренчесе – топонимик карточкада чагылдырылган стандарт мәгълүматлар җыелмасы. Бирегә топоним, аның транскрипциясе, аталу вариантлары, аталган объектның төре, административ һәм географик бәйләнеш, географик координаталары, легендасы (объект, аның исеме турында материал җыю барышында теркәлгән мәгълүматлар, шул исәптән топонимның халыкчан-этимологик интерпретациясе, объектның икътисадый яктан әһәмияте, аның урнашу үзенчәлекләре, аның белән бәйле гореф-гадәтләр һ.б.) һәм информант, җыючы һәм топонимның язу урыны турында мәгълүмат тупланган паспорт керә. Базада торак пунктлар өлешендә җирлекнең танылган кешеләре хакында да мәгълүмат бирелә. Соңгы этапларда топонимнарның әйтелешен аудио форматта тыңлап булыр дип планлаштырыла.

Шуның белән бергә түбәндәге өч кыр махсус фәнни тикшерену эшләре алып баруны сорый:

– төрле язма чыганаклар белән эш. Топоним турында төрле чыганаклардан – карталар, төбәкне өйрәнү, тарихи һәм башка әдәбияттан, архив документларыннан мәгълүмат эзләү һәм аны каталогта чагылдыру;

– топонимнарның структурасын тасвирлау. Биредә географик атамаларның барлык структур төрләрен репрезентацияләү күздә тотылмый, монысы – аерым мәсьәлә. Бу очракта төп максат – структур модель һәм компонентларны эзләү һәм сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итү. Моның өчен структур бүленеш үзенчәлекләре нигезендә тезмә топонимнарда (елга «река» Нарат Елга тибындагы атамаларда) чагылган төп компонентларның, кушма топонимнарда (-су Аксу, Суыксу тибындагы атамаларда) чагылган детерминантларның, регион топонимнарына хас кушымчаларның һ.б. исемлеге төзү сорала.

Мондый структур бүленеш топонимнарның мөһим компонентларын ачыкларга һәм бирелгән критерийлардан чыгып аларны эзләргә һәм сайлап алырга мөмкинлек бирәчәк;

– этимология: Татарстанда яшәгән халыкларның тел үзенчәлекләренә бәйле рәвештә әлеге кырда топонимнарны килеп чыгыш теле ягыннан татар, чуваш, рус, фин-угор, болгар һ б. телләргә кертеп классификацияләүгә мөмкинлек биргән бүлекчәләр карала. Килеп чыгышлары билгесез булган топонимнар аерым бер төркемгә чыгарылачак.

Биредә топонимнарны этимологик яктан интерпретацияләп,

бастырылган текстларны, шулай ук авторларын күрсәтеп, шәхси этимологик эзләнүләр нәтиҗәләрен (мәсәлән, мәкалә яки алардан өземтә) әлеге кырга урнаштыру мөмкинлеге бар.

Бу өч кырны тутыру фәнни тикшеренү эшләре алып баруны күз алдында тота. Аңлашыла ки, әлеге эш бер көнлек кенә түгел. Ләкин шуңа да карамастан, ул план нигезендә башкарылып килә.

Хәзерге вакытта төп басым объектив эзләнүләр җыелмасына ясала. Бүген базага 1680 топоним турында мәгълүмат кертелгән. Әмма, башкарылган эш күп булуга карамастан, без әле эшнең башында гына торабыз дип әйтергә кирәк.

Шул рәвешле, Татарстан топонимнарының электрон картотекасын төзү процессында теоретик ономастика проблемалары да (топонимик ареаллар формалашу, топонимик карта төзү һ.б.) хәл ителә, шулай ук төрле пландагы этнотарихи һәм этномәдәни проблемаларны, безнең очракта Татарстанның мәдәни-тарихи зонасы формалашу тарихы мәсьәләләрен өйрәнү өчен алшартлар да тудырыла.

**Әдәбият**

*Гарипова Ф.Г.* Татарстан микротопонимнары сүзлеге. Беренче китап. Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. 140 б.

*Гарипова Ф.Г.* Татарстан микротопонимнары сүзлеге. Икенче китап. Казан: ТКН, 1993. 140 б.

*Гарипова Ф.Г.* Татарстан гидронимнары сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 224 б.

*Гарипова Ф.Г.* Татарстан гидронимнары сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. 349 б.

***Хисамов Олег Ришат улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының директор урынбасары*

УДК 811.512.145´373

***Р.Р. Мусабәкова***

## ТАТАР АВЫЛЛАРЫ ИСЕМНӘРЕ ХАКЫНДА

В практике перевода большое значение имеет правильная передача имен собственных, в частности названий географических объектов в другом языке. Всякие неточности, допущенные в этом процессе могут привести к фактическим искажениям, к потере национального колорита. При этом, как правило, используется транскрипция, транслитерация и перевод. Однако необходимо знать и помнить также установившиеся традиции и учитывать их при переводе. В статье рассматриваются особенности передачи названий татарских населенных пунктов в русском языке.

**Ключевые слова:** топонимика, топонимы, ойконимы, татарские населенные пункты, транскрипция, транслитерация, перевод.

Кеше туганнан бирле исемнәр дөньясында яши. Бар нәрсәнең – континентлар, илләр, өлкәләр, шәһәрләр, авыллар, таулар, океаннар, елгалар, чүлләр, далаларның һ.б. исемнәре бар. Алар хәттә аерым халыклар, телләр юкка чыкканда да яшәүләрен дәвам итәләр. Дөрес, бу төр сүзләрнең күпмедер дәрәҗәдә яңгырашлары, язылышлары, ә аерым очракта мәгънәләре дә үзгәрергә мөмкин.

Географик атамаларны өйрәнә торган фән – топонимика тел белеменең ономастика өлкәсенә карый. Топонимнарның барлыкка килү мәсьәләләре тел белеме һәм тарих фәнендә өйрәнелә. Аларны бер яки берничә сүзтезмә моделенә кайтарып калдырып булмый. Бу процесс гасырлар буена дәвам итә. Географик атамаларда теге яки бу дәвернең тарихи вакыйгалары, халыкларның мәдәни һәм рухи кыйммәтләре чагылыш таба. Топонимик материалларда телләр арасындагы бәйләнешләр, аларның бер-берсенә йогынтысы һәм халыклар арасындагы мөнәсәбәтләр чагылыш таба.

Топонимнар телгә хас билгеле бер тотрыклылыкка ия. Мәсәлән, теге яки бу территория аерым халыклар тарафыннан яулап алынган очракта да аның элеккеге атамасы озак еллар дәвамында саклана килә. Географик атамаларның күбесе бүгенге географик шартларны чагылдырмый, киресенчә, бик борынгы заманнарга караган вакыйгалар турында сөйли.

Топонимик материаллар төбәк тарихын өйрәнү өчен дә әһәмиятле чыганак булып торалар. Чөнки алар теге яки бу объектның, урынның үткәне һәм бүгенгесе турында күп кенә кызык нәрсәләр турында сөйләргә, ә болар үз чиратында бүтән юллар белән табылган мәгълүматларны тулыландырырга мөмкин [Поспелов, с. 6].

Мәгълүм булганча, топоним атамасы кысаларында макротопоним, микротопоним, некроним, ороним, спелеоним, урбаноним, хороним, ойконим һ.б. төшенчәләр карала. Ойконимның барлыкка килүе очраклы хәл

түгел. Аны кешелек җәмгыяте тудыра. Ул тарихи вакыйгаларга, җәмгыятьнең социаль-икътисади үсешенә бәйле. Атамаларны күпчелек очракларда объектның табигый яки хуҗалык билгеләреннән чыгып, аерым очракларда аларның хуҗалары исемнәренә бәйле рәвештә кушканнар. Алар гасырлар дәвамында яшәп килгән. Бүген теге яки бу авыл исеменең чыгышын төгәл генә аңлатып та булмый, чөнки вакыт узу белән күп нәрсә үзгәргән, кайбер мәгълүматлар югалган, аерым очракларда атамаларның тарихы риваятьләр белән үрелеп киткән. Әлеге проблема аерым өйрәнүне таләп итә. Без бу мәкаләдә игътибарны топонимнарны тәрҗемә итү мәсьәләләренә юнәлтербез.

Мәгълүм булганча, башка халык тарафыннан басып алынган җирләрдә төрле этномәдәни компонентларның миграциясе һәм инфильтрациясеннән тыш, аерым очракта яулап алучыларның һәм җирле халыкның үзара ассимиляциясе, башка этник процесслар, тышкы факторлар белән үзара бәйләнешләре беренче чиратта топонимиягә йогынты ясый [Куклин, с. 119]. Бу күренеш татар халкы яшәгән географик җирлекнең топонимик системасында да чагылыш тапкан.

Мәгълүм булганча, XVI гасырда патша хөкүмәтенең чит җирләрне басып алу сәясәте нәтиҗәсендә Казан ханлыгы дәүләт буларак яшәүдән туктый. Шушы вакыйгадан соң татарлар яшәгән торак пунктларның атамалары рус исемнәре белән алыштырыла башлый. Билгеле бу эш спонтан рәвештә алып барыла. Ул дәвердә географик атамаларны тәрҗемә итү ысуллары турында бернинди мәгълүмат сакланмаган. Татар авылы исемен кем, кайчан һәм нигә шул рәвешле русча язып калдырган, кызганычка каршы, бу сорауларга бүген дә җавап табылмаган.

Руслар тарафыннан яулап алган җирләрдә аларга кадәр формалашкан җирле топоминик система төрле үзгәрешләргә дучар булган. Мәсәлән, М.Н. Мельхеев әлеге мәсьәләгә бәйле рәвештә биш юнәлешне аерып чыгара: 1) җирле халык топонимиясенең бөтенләй юкка чыгуы; 2) җирле топонимия нигезендә яулап алган халык телендә яңа катламның барлыкка килүе; 3) җирле топонимнарны басып алучылар теленә яраклаштыру; 4) җирле атамаларны яулап алган халык теленә тәрҗемә итү; 5) топонимнарны элеккеге объектларыннан яңаларына күчерү [Мельхеев, с. 16]. Бу юнәлешләрне элеккеге Казан ханлыгы җирләрендә барлыкка килгән вазгыятькә карата да кулланып була.

Руслар беркем дә яшәмәгән җирләрдә географик объектларга атамаларны үзләре биргәннәр. Башка очракларда алар җирле халык тарафыннан барлыкка китерелгән топонимик системаны билгеле бер үзгәртүләр белән кабул итәргә мәҗбүр булганнар [Молчанова, с. 168].

Казан ханлыгы яулап алынгач, татар географик атамалары рус теле фонетикасы һәм сүз ясалышы законнары нигезендә адаптацияләнә башлыйлар. Аерым алганда, теге яки бу объектның исеме рус теленең әйтелеш нормаларына яраклаштырыла һәм

шул нигездә ул структур үзгәрешләргә дә дучар була. Үзгәрешләр башта топонимиядә, соңыннан географик карталарда да урын ала.

Бүгенге көндә татар авыллары исемнәренең рус вариантлары бик катлаулы күренеш тәшкил итә. Рус телендә бирелеш үзенчәлекләре нигезендә аларны берничә төркемгә аерып карарга мөмкин:

– тулаем тәрҗемә ителгән атамалар: Җиде Кизләү – Семь Ключей, Татар Суыксуы – Татарский Студенец, Салкын Алан – Холодная Поляна, Салкын Чишмә – Студёный Ключ, Ык Тамагы – Икское Устье, Усаклык – Осиново, Балык Бистәсе – Рыбная Слобода, Актау – Белая Гора, Дүрт Өйле – Четыре Двора, Ташкичү – Каменный Брод, Нарат – Сосново, Кызыл Яр – Красный Берег, Шомыртлы – Черёмушка, Яңа Суыксу – Новый Студенец;

– өлешчә тәрҗемә ителгән атамалар: Юеш Көрнәле – Мокрые Курнали, Урманасты Шынталасы – Подлесная Шентала, Яңа Такталы – Новая Тахтала, Татар Тансары – Татарский Тансар, Югары Казаклар – Верхний Казаклар, Яңа Имән – Новый Имян, Югары Казаклар – Верхний Казаклар, Югары Чура – Село-Чура;

– транслитерацияләнгән атамалар: Салкын Чишмә – Салкын Чишма, Иске Мунча – Иске-Мунча, Шикәрле Каен – Шикарле Каен, Бакчасарай – Бакча-Сарай, Тәмле Чишмә – Тямле-Чишма;

– кыскартылган атамалар: Керкәле Тукмагы – Тукмак, Исәнсеф-Чишмә – Чишма, Уразмәт Чишмә – Чишма, Түбән Сушка – Сушка;

– рус сүзләре һәм кушымчалары ярдәмендә киңәйтелгән атамалар: Чишмә – Хороший Ключ, Көлкәш – Старый Кулькаш, Нәдер – Новое Надырово, Иске Баграҗ – Старый Багряж-Елхово, Ташлы – Каменный Починок, Мортыш – Муртыш-Тамак, Яңа Сала – Околоток-Янгасала, Үри – Уреево-Челны, Кәркәле – Ибраево Каргали, Көтәш – Пор-Кутеш, Гобәй – Губайдуловка, Берлек – Берлек-Михайловка;

– бер өлеше тәрҗемә ителеп, икенчесе рус телендәге охшаш сүз белән алыштырылган атамалар: Татар Шәпкәсе – Татарское Шапкино, Кыркүл – Куркуль, Каргалы – Каргополь, Яңа Ургаагар – Новые Ургагары, Олы Качык – Большая Качка;

– рус телендәге охшаш сүз белән алыштырылган атамалар: Мордыбай – Мордва, Кумырлык – Комаровка, Әндерәш – Андрюш, Күн – Конь, Чыты – Чита, Оет – Уют.

Күп кенә очракларда татар авылларына яңа (русча) исемнәр бирелгән: Яңа Авыл – Берёзовая Грива, Комазан Башы – Крещёная Ерыкса, Ташлыяр – Новое Мочалкино, Киекле – Бурметьево, Казаклар – Сабакаево, Балтач – Юлсубино, Типтәр – Рантамак, Җәнәй – Сосновый Мыс, Яуширмә – Кутлушкино, Абыз – Мингличёво, Чәти – Верхний Китяк, Югары Кыерлы – Верхний Берсут, Кыраул – Сарбаш Пустошь, Түбән Әрнәш – Тёплое Болото, Әдәмса Авылы – Татарское Утяшкино, Югары Ырга – Шетнево-Тулуши, Алан – Пробуждение, Соравыл – Янсуринское, Күзби – Средние Лащи,

Казак Үртәме – Нурняк, Карлы – Мещеряково, Мөкерле – Мокрая Сабалеевка; Тутай – Тойгильды, Кизләү – Курманаево, Апач – Сармаш-по-Ирне.

Авыл исемнәре арасында ике сүздән торган топонимнарның бер сүз итеп кенә бирелгән очраклары да теркәлде: Таш Билге – Тяжбердино; Күк Тәкә – Кук-Тяка; Кичке Таң – Кичкетан; Олы Имән – Улиманово; Алаба Күл – Алабакуль. Моннан тыш бер үк атама ике төрле вариантта кулланылырга мөмкин: Әгерже – Агрыз һәм Агерзе; Балтач – Балтаси һәм Балтачево.

Фонетик үзгәрешләргә килгәндә, биредә, нигездә, сузык авазларны төшереп калдыру күзәтелә: Кырынды – Крынды, Кызыл Сукачы – Кзыл-Сукаче, Бакырчы – Бакрче, Бюрек – Брек, Ташкичү – Ташкич.

Татар топонимнары структур үзгәрешләргә дә дучар булганнар. Монда, аларга рус теле өчен хас булган -анск, -инск, -енск, -овск, -евск, -ов(а), -ов(о), -ева(а), -ев(о), -ин(а), -ин(о) суффиксларының өстәлүен әйтеп үтәргә кирәк. Мәсәлән: Кәче – Качелино, Туйкә – Тойкино, Садык – Садиково, Мерәс – Мрясово, Мәсгут – Масягутово, Акман – Ахманово, Балтач – Балтачево, Кодаш – Кудашево, Иске Теләкәй – Старое Тлякеево, Чирү – Чураево, Актүбә – Актюбинский, Биләр – Билярск һ.б.

Югарыда телгә алынган моментлар татар атамаларының фонетик тышчасын һәм структурасын гына үзгәртеп калмыйча, аларның мәгънәләренә дә зыян китергән. Кайбер очракларда бөтенләй чит, абсурд вариантлар барлыкка килгән: Чарлы – Чарли, Кече Үби – Малый Убей, Ор – Ура һ.б.

Бүгенге көндә татар атамаларының рус вариантлары күңелгә бик ятып бетмәгән күренеш тәшкил итә. Ул халыкны да борчый. Вакытлы матбугатта да әледән-әле бу мәсьәләгә багышланган мәкаләләр дөнья күрә [Вәлиәхмәтов; Гыйлемханов]. Әлбәттә биредә хәл ителәсе проблемалар бик күп. Ләкин аларны бер утыруда гына чишү мөмкин түгел. Моның өчен төрле даирәләрдә (фәнни, административ һ.б.) максатчан рәвештә эзлекле эш алып бару сорала.

**Әдәбият**

*Вәлиәхмәтов З.*. Сәер исемнәр // Ватаным Татарстан. 2006. 15 июль.

*Гыйлемханов Р.*. Корайван маҗаралары // Ватаным Татарстан. 2016. 25 май.

*Куклин А.Н.* Взаимодействие языков Урало-Поволжья в сфере топонимии // Ономастика в кругу гуманитарных наук. Екатеринбург: Изд-во Уральского университета, 2005. С. 119–121.

*Мельхеев М.Н.* Топонимика Бурятии. Улан-Уде: Бурятское кн. изд-во, 1969. 168 с.

*Молчанова О.Т.* Русские и адаптированные русскими топонимы горно-алтайской автономной области // Восточно-славянская ономастика. Материалы и исследования. М.: Наука, 1979. С. 199–175.

*Поспелов Е.М.* Туристу о географических названиях. М.: Профиздат, 1988. 192 с.

***Мусабәкова Рәисә Рәшит кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, ТР ФА Татар энциклопедиясе һәм төбәк өйрәнү институты өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 821.512.145

*Р.К. Ганиева*

# XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР МОДЕРНИСТИК ӘДӘБИЯТЫ ҺӘМ ФАТИХ ӘМИРХАН

В статье рассматривается творчество писателя, журналиста и общественного деятеля Фатиха Амирхана в контексте татарской модернистской литературы начала XX века.

**Ключевые слова:** Фатих Амирхан, татарская литературы начала XX века, модернистская литература.

Татар халкы үзенең тарихи барышында ике мәртәбә Ренессанс баскычы аша үтте. Беренчесе – урта гасырларда, мөселман мәдәнияте, Коръән тәгълиматы белән берегеп яшәгән заманда. Бу – халкыбызның Идел буе Болгарстаны, Алтын Урда империясе, Казан ханлыгы кебек дәүләтләре булган чор. Өч йөз ел дәвамында колониаль бәйлелектә интеккәннән соң, XIX гасырның уртасыннан иҗтимагый һәм рухи төшенкелектән уяну, тернәкләнү, күтәрелү еллары башлана, ә инде XX гасыр башыннан аурупалашуга, җәдитләшүгә, милләткә хезмәт итүгә йөз тоткан, халкыбызның дини, сәяси, икътисади, мәдәни-әдәби үсешендә моңарчы һичкайчан күзәтелмәгән киң колачлы Икенче Яңарыш хәрәкәте мәйданга чыга. Әдәбият мәйданына татар милләтенең бәхете өчен җанатар Габдулла Тукай һәм Гаяз Исхакый кебек даһилар, Галимҗан Ибраһимов, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Галиәсгар Камал, Шәриф Камал, Гафур Коләхмәтов кебек зур талантлар килә. Алар арасында «Җәдитчелек – Яңарыш» (Надир Дәүләт) әдәбиятына, аның алтын хәзинәсен тәшкил иткән төрледән төрле модернистик алым, стиль-агым, юнәлешләргә юл ачкан күренекле җәмәгать эшлеклесе, публицист-журналист, прозаик, драматург, тәнкыйтьче, тәрҗемәче Фатих Әмирхан да (1886–1926) бар иде. Иң элек ул урта гасыр Шәрекъ, шул исәптән, татар әдәбиятларында озак гасырлар дәвамында яшәп килгән, әдәби иҗатта иҗтиһад итү мөмкинлекләрен чикләгән тәкълидчелек, канунчылык, дистәгә якын төре булган нәзыйрәчелекне Америка, Аурупа, рус әдәбиятларында киң кулланылышта булган акмеизм, аң агымы, импрессионизм, концептуализм, символизм, экзистенциализм, экспрессионизм, фрейдизм кебек модерн күренешләрен татар әдәбияты җирлегендә сынап карый, Шәрекъ классикасы казанышларын ауропачыл реализм һәм романтизм эстетикасы белән аерылгысыз бербөтен итеп синтезлап, бөек экспериментатор буларак чыгыш ясый һәм гамәлгә кертә. Әдипнең замандашлары, шул исәптән,

күренекле әдәбият галиме Җамал Вәлиди болай дип язды: «...ул татар әдәбиятын заман теләгенә муафикъ бер калыпка, Көнбатыш әдәбияты калыбына салды, аңа җитди бер форма бирде, телне, өслүбне нечкәләп эшкәртүче булды. ... Ф. Әмирхан нәфис әдәбиятыбызны гарebләштерүдә иң алда чыгучы һәм киң юл ачучыдыр» [Фатих Әмирхан..., б. 41].

Ф. Әмирханның төп идеалы озак гомерләр дәвамында феодаль торгынлыкта яшәгән татар кешесен «хакыйкый европеец», абруйлы репутациягә ия шәхес итеп тәрбияләү. «Яшьләр колагына бер сүз» (1908) дигән чыгышында ул болай дип язды: «Бездән мәгыйшәт эш вә эшлеклелек таләп итә. Бездән мәгыйшәт хакыйкый (чын) европеец булуыбызны таләп итә». «Аяклары бәйле Прометей» гомеренең соңгы көннәренә кадәр үзенең бу шигаренә турылыклы булып калды, әдәби барышыбызга модерн ысулы белән язылган берсеннән-берсе асыл әсәрләр бүләк итеп китте. Аларның кайберләре турында үзебезнең фикерләрне укучыга да тәкъдим итәбез.

* * *

Фатих Әмирхан (1886–1926) – һәм реалист, һәм романтик язучы. Бер үк вакытта аның әсәрләрендә сәнгатьчә фикерләүнең бу ике төре төрледән-төрле модернистик алымнар белән дә мөнәсәбәткә керә. Аларның күбесен әдип Көнбатыш һәм рус әдәбиятлары, аеруча Л.Андреев белән А.Чехов иҗатлары аша кабул итә.

XX йөз башы татар әдәбиятына, шул исәптән Фатих Әмирхан иҗатына зур йогынты ясаган рус язучыларының атаклысы – Леонид Андреев (1871–1919).

Мәгълүм булганча, экспрессионизм (французча – «экспрессио» – тәэсирлелек) өчен хас төп сыйфатларыннан берсе – караңгы, ямьсез сурәтләр, натуралистик тасвирлар, символлар, бәяләмәләр ярдәмендә кешенең субъектив дөньясын, аның кичерешләрен бик тә киеренке, гомумән, яшәешне тәмугъ, фаҗига итеп гәүдәләндерү.

1909 елда Фатих Әмирхан Леонид Андреевның экспрессионистик стильдә язылган «Асылган җиде кешеләр» («Рассказ о семи повешенных») хикәясен тәрҗемә итә һәм бастырып та чыгара.

Язучы Леонид Андреев та, тәрҗемәче Фатих Әмирхан да үлем җәзасы көтеп төрмәдә яткан биш террористның, ике җинаятьченең эчке халәтләрен экспрессионистик алымнар ярдәмендә акылдан шашу дәрәҗәсенә җиткереп тасвирлый. Җинаятьче уголовниклар инде үзләренең кеше икәнлекләрен дә онытканнар. Мәсәлән, Иван Янсон «шыгырдавыклы, ямьсез, ләкин артык рәхәт һәм шатлыклы, каз кычкырган шикелле ка-ка-ка иткән тавыш белән кычкырып көләргә тотына»; Мишка Цыганок исә «дүрт аякланып, калтыранган бүре тавышы белән улый».

Асып үтерелгән террористларның мәетләрен натуралистларча тасвирлаган күмәргә алып китү күренеше дә җир өстендәге коточкыч тәмугъны хәтерләтә: «Җансыз тәннәрне ящикларга тутырдылар. Аннан соң алып киттеләр. Сузылган муеннар, гакылдан чы-

гып акайган күзләр, канлы күбек белән сугарылган иреннәр арасыннан күрелмәгән, коточкыч чәчәкләр шикелле, асылып тора торган шешенгән зәңгәр телләр белән, үзләре терек килеш килгән юлдан, җансыз тәннәр кайтып киттеләр».

Әдәбият галимнәре язганча, Леонид Андреевның «Асылган җиде кешеләр» хикәясе реакция елларындагы патша самодержавиесенең революционерларны асу-кисү, төрмәләрдә черетү, җәзалау сәясәтенә гаепләү акты булып торды.

Леонид Андреевның «Асылган җиде кешеләр» хикәясен татарчага тәрҗемә итү Фатих Әмирханның алдагы иҗатында экспрессионистик стильгә корылган әсәрләр тудыру өчен җирлек хәзерли. Язучының Леонид Андреев иҗаты йогынтысында язылган «Татар кызы» (1909) хикәясе моңа дәлил булып тора. Зур гомумиләштерү көченә ия булган бу әсәрдә образ-сурәтләр, сәнгатьчә фикерләү, жанр, композиция, конфликт гәүдәләнеше бик тә үзенчәлекле. Анда урта гасыр гарәп, фарсы, төрки әдәбиятларына хас кысалы кыйссалар традициясе саклану, эпиграфта һәм хикәянең азагында Коръәндә телгә алынган тереләтә җиргә күмелгән кызлар образы бирелү һәм дә Изге Китаптагыча мөсәҗҗәгъ нәсер (рифмалы проза) стиленә мөрәҗәгать итү рус һәм дә әсәр тукымасына Аурупа әдәбиятларында киң таралган экспрессионистик алымнар һәм экзистенциаль карашлар белән бергә килеп очрашу «Татар кызы» хикәясендә Шәрекъ – Гареб синтезының аерылгысыз, бербөтен тәшкил итүе турында сөйли.

Л. Андреев әсәрләрендәгечә, «Татар кызы» хикәясенең дә тоташ сюжеты юк, анда да кыз баланың яшенә мөнәсәбәттә кино тасмасындагы кебек алмашынып торган күңелсез фрагментлар, кырыс күзәтүләр, авыр хөкемнәр һәм бәяләр генә бар. Татар кызының конкрет исеме дә аталмый; тере колларга әверелдерелгән мөселман хатын-кызлары «җанлы курчаклар», шәригатькә, иске гореф-гадәтләргә турылык саклап, аларны һәлакәт упкынына этәргән аталар образлары «кара көч» символы ярдәмендә гәүдәләнә. Бу үзенчәлекләрнең барысы да – экспрессионистик өслүб билгеләре.

«Татар кызы» хикәясенең эчтәлеген экзистенциализм (латинча: «яшәү») фәлсәфәсе белән дә бәйләп карарга мөмкин. Фатих Әмирхан да татар кызын яшәештә – туу, үсү, мәхәббәт көтү, тормышта борчылу, җәфалану, язмыш сынаулары кебек экзистенциаль чикләр аша үткәрә һәм, ахыр чиктә, аның гомерен үлем белән очлый. Кыскасы, Фатих Әмирхан вакыт һәм хосусиятләр буенча бер-берсеннән бик тә ерак торган мәдәни һәм әдәби традицияләрне янәшә куеп, мөселман һәм Аурупа әдәбиятларының оригинал синтезына ирешә һәм милли алгарышның бик тә актуаль бер алшарты булган хатын-кыз азатлыгы мәсьәләсен көн тәртибенә куя.

Ф. Әмирханның А.П. Чехов реализмы рухында импрессионистик алымнардан файдаланып язылган, зыялы яшьләр

тормышын гәүдәләндергән «Урталыкта» (1912) романы һәм «Тигезсезләр» (1914) драмасы да бар. Аларда да импрессионистик әсәрләргә хас булганча, сюжет, вакыйгачылык үзәк урынны алып тормый. Һәр ике әсәрдә дә Фатих Әмирхан үзенең төп игътибарын билгеле бер сюжет кысаларында, төрледән-төрле хәл-әхвәлләрдә кеше җанының киеренке мизгелләрен күрсәтүгә юнәлтә. Геройларның эчке дөньясы алар яшәгән тирәлек, табигать кочагында, утар-дачаларда, мәдәният учакларында аш-су һәм кием-салым, сөйләшү, ничек итеп сәүдә итү, гыйлем алу, һөнәр сайлау тирәсендә барган фикер алышуларда, әдәбият, туган тел, музыка, мәхәббәт, милләткә хезмәт итү, инкыйлабчылык кебек мәсьәләләр турында барган бихисап әңгәмә-бәхәсләрдә ачыла. Бу яктан караганда Фатих Әмирханның прозасын импрессионистларча тирән психологизм, яңа сюжет алымнары, яңа тип герой белән баетуда тәмамланмаган «Урталыкта» романы аеруча игътибарны җәлеп итә. Иң элек бу әсәр XX гасыр башындагы Россия империясендәге һәм татарлар арасындагы иҗтимагый-сәяси халәтне, татар яшьләренең күмәк рәсемен, милли мәдәният мәсьәләләрен яшәешнең төрле мизгелләрен куеп төрледән-төрле сюжетлар бәйләме ярдәмендә сәнгати яктан ышандырырлык итеп чагылдыруы белән кызыклы.

«Урталыкта» романы күләмнәре ягыннан төрлечә озынлыкта булган 16 бүлектән тора. Аларның кайберләре (1, 5, 6, 7, 10, 12, 13) бик тә кыска, кайберләре исә (2, 3, 4, 8, 9, 11, 14, 15, 16) шактый озын. Шушы бүлекләрдә дөньяга карашлары белән бер-берсенә охшамаган дистәләгән Казан яшьләре (унбер егет һәм алты кыз) образы гәүдәләнә. Алар тормышындагы эреле-ваклы вакыйгаларның барысы да әсәрнең баш герое Хәсән Арсланов образы тирәсенә бер фокуска тупланып, үзәк сюжет җебенә бәйләнә.

Хәсән Арсланов уңышлы гына татар мәдрәсәсен тәмамлаган, ихтирамга лаек шәкерт буларак, беркадәр анда пишкадәм вазыйфасын да үтәгән. Әмма мәдрәсәдә алган белемнәренең тормыш итәргә ярамаганлыгын аңлагач та, үзлегеннән русча укырга тотына, аттестат алырга җыена. Мәдрәсәләрдә укыту-тәрбия бирүнең бик түбән сыйфатлы булуы Хәсәнне «Юләрләр йорты» дигән мәкалә язуга да этәргән. Ул үзенең бөтен барлыгы белән рус мәдәниятенә тартыла. Аның бүлмә диварларына Шекспир, Байрон, Маркс, Пушкин, Тургенев, Толстой, Репин кебек рәссам, язучылар, фикер ияләре рәсемнәре ябыштырылу да аның ауропалашырга теләүче мәгърифәтче һәм җәдитче икәнлеге турында сөйли. Кием-салымны да ул ауропача йөртә; кәләпүш, тужурка киюне «татарщина» дип саный. Русчасы аксаса да, үзен русларга Евгений Петрович дип тәкъдим итә. Әмма Хәсән Арслановның бу «гөнаһлы» адымнары аны руслар белән татарлар арасында буталып калган маргинал тип дип әйтергә хокук бирми. Хәсәннең «татарщина»га каршы чыгуы – һич тә үз милләтеннән йөз чөерүне аңлатмый. Аның

өчен «татарщина» – феодаль җәмгыятьнең искергән традицияләрен, ягъни кадимчелеген кабул итмәү. Хәсәннең милли горурлыгы да җитәрлек. Ул үтә чыккан кызыл эсер Саматовның «Шигырь на татарском языке быть не может!» дигән сүзләренә дә каршы төшә, татар мәдәниятенең, әдәбияты һәм музыкасының киләчәктә үсәчәгенә дә өметләр баглый; Гаяз Исхакыйны «татар тормышының иң зур җәрәхәтен ачучы» «иң зур татар мөхәррире», «иң зур татар таланты» дип атый. Шул ук вакытта ул кайбер татар яшьләренең милли әдәбиятка битарафлыкларын күргәч, каушап та кала, «Юк ла, әдәбият дигән нәрсә татарда булмый ла инде ул» дип, икеләнүле хисләргә, төшенкелеккә дә бирелә.

Романның «Урталыкта» дигән исеменнән күренгәнчә, Хәсән Арсланов көндәлек яшәеш дулкыннарында чайкалучы, бәргәләнүче образ. Ул ата-бабалардан килгән кадими яшәү рәвешен – «татарщина»ны да кабул итми; танышы Саматов кебек үтә радикал инкыйлабчы «таңчылар»ның гамәлләрен дә якламый, үтә сул карашларын да уртаклашмый. Шуңа күрә ул Саматовның аның бүлмәсендә дорфа гына, рөхсәт тә сорамыйча ихтилялга өндәүче революцион эчтәлекле рисаләләр, өндәмәләр, хәреф-шрифтлар, эсерлар партиясе мөһерләр калдырып китүенә җаны сызлана, тәне куырылып киткәндәй була, бәдәне сызлана башлый. Әмма Хәсәннең Саматов турындагы фикерләре импрессионист язучылардагыча үзгәреп, алмашынып тора. Бер яктан, бу бертуктамый кеңкыһ дип борынын тартучы, үзен баһадир итеп күрсәтергә омтылучы, башкалар кулы белән утлы күмер җыярга яратучы Саматовны Хәсән күрә алмый. Аның милли мәнфәгатьләр турында кайгыртуны «татарлык», «позор!» дип тамгалавы өчен дә хурлана. Ә икенче яктан, Саматовның Россиядәге барлык изелгәннәргә, эшчеләргә, сәяси тоткыннарга ярдәм итәргә «общее благо» өчен тырышырга кирәк дигән чакыруларына Хәсән Арсланов күңеленең бер чите белән генә булса да теләктәшлек белодерә. Үткен телле шагыйрь Шәрифнең ирония белән мыскыллы көлүе дә Хәсәндә каршылыклы хисләр уята.

Казанның төрле милләт, төрле холыклы егетләре, кызлары белән очрашулар, әңгәмәләр Хәсән Арслановның рухи халәтен су өстендәге күбек кебек уйнатып, уңга-сулга, алга-артка чайкалдырып тора. Шул рәвешчә, Фатих Әмирхан XX йөз башы татар әдәбиятында импрессионистик стильгә корылган кәеф прозасының беренче сәхифәләрен ачып җибәрә.

Хәсән Арслановның тышкы кыяфәте дә, холкы да матур һәм шыксыз детальләрне, ак һәм кара төсмерләрне импресионист язучылардагыча үзенә туплаган. Бер үк вакытта бу образ индивидуальләштереп тә бирелгән. Хәсән Арслановның дөньяны кабул итүе, эчке дөньясы өчен бер үзенчәлек хас: романның буеннан-буена аның эче поша, кәефсезләнә, үзе-үзен битәрли, Толстой геройларыча вөҗдан газапларына дучар ителә.

«Урталыкта» романының төп герое турында әдәбиятчылар тарафыннан төрле фикерләр әйтелгән. Ул уңай һәм тискәре образ дип тә, урталыкта торучы образ дип тә бәяләнгән. Әйе, Хәсән образы каралтып та, идеаллаштырып та сурәтләнмәгән. Шул ук вакытта кыйбласы булмаган герой да түгел. Яшәешенә бик еш кәефсезлек юлдаш булса да, ул чамадан тыш кызыл булуын да сөйли, милләтне артка сөйрәүче кадимчеләрдән дә ерак тора. Ул бер чиктән икенче чиккә ташлануны да, «ифрат – тәфрыйть» уеннары уйнауны да өнәми. Хәсән Арсланов иҗтимагый һәм рухи яшәештә Арастуның (Аристотель) «алтын урта» фәлсәфәсе тарафдары. Әмма әлеге дә баягы бер сорау туа: ни өчен соң Ф. Әмирхан үз романын «Урталыкта» дип атаган. Моның сәбәбе: унынчы елларда милли хәрәкәтнең яңа бер чоры башлану, рус революциясе һәм реакция елларындагы сыйнфый һәм революцион көрәш идеяләреннән баш тартып, татар халкының барлык катламнарын бергә туплап, милли аңны үстерү, милли кыйммәтләрне саклау, гомуммилли мәнфәгатьләрне яклау юлына басып, мәгърифәтчеләрчә тыныч урталык юлын сайлап, милли мәдәният һәм мәгърифәтне үстерүгә таба хәрәкәт итә. Мондый фикерләр әдипнең Г. Исхакый «Зөләйхасының сәхнәгә куелу уңае белән язылган тәнкыйть мәкаләсендә дә, публицистик чыгышларында да ассызыклана. Февраль революциясе һәм Учредительный собраниягә сайлау көннәрендә Ф. Әмирханның милли алгарыш турындагы карашлары тагын да ачык сәяси һәм мәдәни төс ала. «Кояш» газетасында «Инкыйлаб вә без» (1917, 19 апрель №1094) дигән мәкаләсендә ул болай дип яза: «Милләт арасындагы сыйнфый көрәшне үткенләндерерлек һәрбер хәрәкәт вә һәрбер сүздән сакланып «мәдәни автономия» алу өчен «иң тугры, иң дөрест юл – милләтне бүлендермичә, бер милләт хәлендә сайлауга алып бару юлыдыр».

Ф. Әмирханның тагын бер таҗ әсәре – «Тигезсезләр» (1914) психологик драмасы. Аның сюжет һәм композициясе, табигать, музыка, мәхәббәт мотивлары, образлар системасы, гомумән, әсәрнең бөтен архитектоникасы импрессионистик стильгә нигезләнгән. Пьесаның сюжетында Аристотель заманнарыннан ук кабул ителгән традиционлык – экспозиция, төенләнеш, вакыйгалар үстерелеше, кульминация, чишелеш кебек биш элемент берлеге дә сакланмаган. Белгәнебезчә, импрессионистик язучылар вакыйгачылыкка бик аз урын бирәләр, башлыча персонажларның үзара мөнәсәбәтләрен, хис-тойгылар үстерелешен сурәтләүгә басым ясыйлар. Ф. Әмирханның «Тигезсезләр» драмасында да шул ук хәл. Мәсәлән, драмадагы һәр өч пәрдәнең импрессионистларча бирелгән экспозициясе бар. 400 дән артык ремаркалар бирелү дә пьесаның үз режиссурасын булдыра. Хәрәкәт, вакытның сүлпән агышы, вакыйгаларның пәрдә артында, күренешләр арасында баруы, табигать авазлары, музыка, әдәбият,

сәнгать, мәхәббәт турындагы әңгәмәләр, бер яктан әсәрдәге эпиклыкны көчәйтә, икенче яктан, лирик башлангычны арттыра, психологизмны тирәнәйтә.

«Тигезсезләр» драмасындагы төп образларның берсе – яңа заман сәүдәгәре, акыллы һәм талантлы эшкуар Гомәр. Пьесада ул төрле мизгелләрдә, төрле халәтләрдә гәүдәләнә һәм образлар системасын психологик яктан гына түгел, социаль күзлектән дә бер җепкә бәйләп торучыга әйләнә. Шуны да әйтергә кирәк, социаль мөнәсәбәтләр турындагы фикерләр пьесада, башлыча, Гомәр авызыннан әйттерелә һәм алар әсәр тукымасына импрессионистларча сиздермичә, юл уңаенда гына кертеп җибәрелгән тәэсир калдыра. Аларның кайберләрен искә алып үтик. Мәсәлән, Гомәр, Печән базарындагы татарлар кебек, он-тоз, читек-кәвеш белән генә алыш-биреш итү тарафдары түгел. Ауропадагы кебек, мәдәни бизнес вәкиле буларак, ул югарырак баскычка үрмәли: оптика кибете ачып җибәрә, немецлар, яһүдиләр кебек зурдан кубып сәүдә итү турында уйлана. Гаилә һәм милләт мәнфәгатьләрен дә онытмый. Сеңлесе Сәлимәне немец телен һәм бухгалтерияне үзләштереп, сәүдә эшенә керешергә өнди. Кече сеңлесе Рокыяга да юридик факультетта укырга киңәш бирә, чөнки «юрист һәрвакыт үз-үзен туендыра ала». Гомәр хатын-кыз хокуклары турында да уйлана. Аныңча, икътисади яктан тәэмин ителгән хатын-кызлар гына гаиләдә дә, җәмгыятьтә дә азат һәм бәхетле була алалар. Хатын-кыз язмышын икътисади азатлык мәсьәләсе белән бәйләп, уңай якка үзгәртү мөмкинлеге беренче мәртәбә Г. Исхакыйның «Ике йөз елдан соң инкыйраз» антиутопиясендә әйтелгән иде. Икенче мәртәбә бу мәсьәлә гендер теориясе күзлегеннән әһәмиятле социаль проблема буларак Ф. Әмирханның «Тигезсезләр» драмасында көн тәртибенә куелды. «Минемчә, – ди пьеса герое Гомәр, – татар кызларын үз көннәрен үзләре күрерлек кешеләр итеп тәрбия итәргә кирәк. Шул вакытта гына алар ирләре кулына карап тормаслык бөтенләй хөр була алалар».

Драмада импрессионистик рәссамнар кебек ачык буяулар белән оста тасвирланган образларның икенчесе – гүзәл кыз Рокыя. Ул – шаян, саф күңелле, җор телле, үз ирке, үз ихтыяры белән яшәргә омтылучы иркә җан. Тирә-юньдәге, гаиләдәге һәр кеше аны ярата. Рокыя рус гимназиясен тәмамлаган; рус һәм татар әдәбиятын яхшы белә, рәссам булу турында хыяллана; пианино артына утырып, өздереп «Вальс», «Мөхәммәдия» көйләрен уйный. Табигать аңа матурлыктан да мул өлеш чыгарган; егетләр дә аңа гашыйклар. Рокыя – чәчләренә чал төшкән шагыйрь Сөләйманның да идеалы, намаз укыганда нурлар диңгезендә йөзүче фәрештәсе. Әмма мәхәббәттә алар – «тигезсезләр», чөнки Рокыяның гүзәллеге, бәхетле яшьлеге – шактый олы яшьтә булган Сөләйманның сагышы, йөрәк ярасы, киеренке кичерешләре. Абыйсы Гомәр кебек, Рокыя образы да пьесадагы сюжет җепләрен бер фокуска җыеп, бәйләп тора.

Драманың ике фокуслы булуы – шулай ук авторның импрессионистик стиль чараларына мөрәҗәгать итүдән туган күренеш.

Ф. Әмирханның башка әсәрләрендәге кебек, «Тигезсезләр» драмасындагы яшьләр образлары да кайсыдыр бер сыйфатлары белән индивидуальләштерелеп бирелә. Мәсәлән, «страховой агент» Закир образы курсисткаларга, туташларга, егетләргә сөйләгән мәзәкләр – кара юмор ярдәмендә ачыла. Ул сөйләгән тозсыз мәзәкләр, мәгънәсез фокуслар яшьләрнең күңелен төшерә, авыруга сабыштыра, куркуга сала. Рус әдәбиятында мондый «кара юмор» элементларына А.П. Чехов еш мөрәҗәгать иткән иде. Аның иҗаты аша яшәешнең күңелсез мизгелләрен импрессионистларча кечкенә сюжетларда тасвирлаган, тупас күңел ачуга корылган «кара юмор» Ф. Әмирхан иҗатына да үтеп кергән.

Ф. Әмирханның татар модернистик әдәбияты үсешенә керткән яңалыклары, сәнгати ачышлары рус әдәбиятындагы «Көмеш гасыр» («Серебряный век», икенче атамасы – Ренессанс) вәкилләре эшчәнлеген хәтерләтте. Рус мәдәниятендә һәм әдәбиятында бу модернизм әдәбиятына таба зур борылышны И. Анненский, К. Бальмонт, А. Блок, А. Белый, И. Бунин, А. Ахматова, Н. Гумилев, Ф. Сологуб, Д. Мережковский, Вяч. Иванов, А. Куприннар кебек көчле бер төркем башлап җибәрсә, татар Яңарыш әдәбиятында моңарчы мәгълүм булмаган, күз алдына китерү дә авыр инкыйлабка тиң иҗади эшне Фатих Әмирханның берүзенә башкарырга туры килде.

Илне канга батырган Октябрь түнтәрелеше, гражданнар сугышы, Идел буендагы ачлык афәте, рәхимсез сыйнфый көрәш һәм атеистик сәясәт авыру Ф. Әмирханның көндәлек яшәешендә, әдәби эшчәнлегендә зур кыенлыклар тудырды. Шуңа да карамастан, иҗат эшен туктатмады, бик тә тирән фәлсәфи эчтәлекле ислам дине, Коръән тәгълиматы өйрәтмәләренә таянып яшәү һәм үлем фәлсәфәсен яктырткан экзистенциаль мотивлар белән сугарылган атаклы «Тәгъзия»сен (1922) язды, пролетариат диктатурасы елларында марксистик-ленинчыл идеология белән агулануның классик үрнәге, концептуализм дигән модерн юнәлешенә караган «Шәфигулла агай» пародиясен иҗат итте. Кыскасы, Габдерахман Сәгъди сүзләре белән әйткәндә, «Ничек булганда да, Ф. Әмирхан һәр ягы белән татарның классик буржуаз әдипләренең берсе булып, татар әдәбиятында зур урын тотты һәм татар әдәбиятының иң көчле бер гамиле (хөкемдары) булды» [Сәгъди, б. 380].

**Әдәбият**

*Сәгъди Г.* Татар әдәбияты тарихы. Дәреслек-кулланма. Казан, 1926. (кульязма).
Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 41.

***Ганиева Резеда Кадыйр кызы,***
*филология фәннәре докторы, профессор*

УДК 821.512.145:070

***В.З. Гарифуллин***

# ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ ЖУРНАЛИСТЛЫК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕ

В статье анализируется журналистская деятельность и публицистическое творчество выдающегося организатора татарской периодической печати, писателя и общественного деятеля Фатиха Амирхана. В начале XX века Ф. Амирхан становится ключевой фигурой в становлении системы татарской прогрессивной журналистики. В центре внимания его публицистического творчества – борьба против самодержавия, реформы в области образования, пути развития татарской литературы, разработка норм литературного языка.

**Ключевые слова:** Фатих Амирхан, история татарской журналистики, периодическая печать, публицистика, статья, сатира.

XX гасыр башында дөньяга аваз салган татар вакытлы матбугаты бик тиз арада зур үсешкә ирешә. Чөнки аның башында халык мәнфәгатьләре белән яшәгән бөек шәхесләребез торган. Шуларның берсе – матур әдәбиятта гына түгел, журналистика өлкәсендә дә тирән мәгънәле әсәрләр калдырган, татар журналистикасының тууына, үсүенә һәм алга китүенә зур йогынты ясаган Фатих Әмирхан. Аның журналист эшчәнлеге күләме белән дә, хронологик кысалары белән дә саллы, ул вакытлы матбугат үсешендәге берничә чорны үз эченә ала.

Журналист буларак Ф. Әмирхан күп төрле газета-журналлар белән хезмәттәшлек иткән. Аларның беришендә – «Тәрбиятел-әтфал» журналында, кулъязма һәм басма «Әльислах», «Кояш» газеталарында җаваплы сәркатип сыйфатында эшләсә дә, ул – аларның фактик редакторы, икенчеләрендә – «Аң», «Яшен», «Ялт-йолт» кебек журналларда, «Эш», «Кызыл армия», «Татарстан хәбәрләре» кебек газеталарда төрле жанрларда һәм төрле темаларга язылган әсәрләре белән катнашкан. «Ф. Әмирхан публицистика арсеналындагы күп төрле формалардан файдаланган, иң катлаулы саналган очерк, фельетон жанрларында эшләгән, бөтенләй сирәк кулланыла торган рецензия-памфлет, интервью-фельетон, физиологик очерк кебекләрен дә язган. Аның публицистикасының палитрасы киң: бу өлкәдә ул – зур колачлы фикер иясе, үткен сатирик, нечкә хисле лирик» [Нуруллина, б. 232].

Революцион вакыйгалар нәтиҗәсендә туган татар вакытлы матбугаты Ф. Әмирханның журналистлык эшчәнлеге үсүгә киң мәйдан ача. 1906 елның көзендә ерак кардәше Заһид Шамил чакыруы буенча Фатих Әмирхан Мәскәүгә килә һәм «Тәрбиятел-әтфал» журналында җаваплы сәркатип булып эшли башлый, шушы басманың мәсләген билгели. Басманың баш мәкаләләре,

фәнни-популяр мәкаләләр (татар журналистикасында фәнни-популяр публицистиканың башлангычы) аның тарафыннан языла, тәрҗемә рәвешендәге әдәби әсәрләре дөнья күрә.

Казанга кайткач, Ф. Әмирхан педагог һәм журналист Вафа Бәхтияров белән «Әльислах» газетасын чыгара башлауга ирешә. 1907 елның 3 октябрендә аның беренче рәсми саны дөнья күргән. Рәсми редакторы В. Бәхтияров булса да, «Әльислах»ны фактик оештыручы һәм җитәкләүче Ф. Әмирхан була. «Газетаның татарда демократик фикерне җәелдерүдә әһәмияте искиткеч зур. Ф. Әмирханның әдәбиятка, сәнгатькә кагылышлы бик күп тәнкыйть мәкаләләре, Казан хәлләре, иҗтимагый мәсьәләләргә багышланган очерклар, информацияләрнең зур күпчелеге «Әльислах»та басыла» [Нуруллин, б. 39]. Газетаның беренче санында ук басылып чыккан өч язмасы белән ул «Әльислах»ның төп кыйбласын, юнәлешен билгели. Баш мәкалә жанрындагы «Казан, 3 октябрь», шулай ук «Мөтәгәссыйб Казан татарларына ачык хат» һәм «Думалар» дигән язмалар – Фатих Әмирхан иҗатының югары дәрәҗәсен күрсәтеп торучы гаять җитди һәм үзенчәлекле әсәрләр. «Думалар» мәкаләсендә III Думага вәкилләр сайлау турында сүз бара. 3 июнь законы керткән чикләүләр, аларның Думада зур җирбиләүчеләр һәм фабрика-завод хуҗалары мәсләкләрен яклауны тәэмин итүе, ләкин барыбер сайланучылар арасында сулларның һәм урталарның күп булуы әйтелә һәм хөкүмәтнең, Думада уңнар өстенлек итәр, дигән «хисабы» «бөтенләй үк тугры чыкмас» дип нәтиҗә ясала [Әмирхан, б. 51]. Гомумән, Думаның эшчәнлеге, аның кемнәр кулында булуы, кемнәр җырын җырлавы Ф. Әмирханны даими кызыксындырган. Менә аның «Әльислах»та шул хакта басылган мәкаләләре: «3 нче июнь кануны вә партияләр», «3 нче Дума», «Дума ачылды», «Думада центр», «Зур педагоглар» зур эш эшләп кайттылар», «Мәктәп ляихәләре өчен аяклар!» һ.б. Боларда журналист ил тормышында хәлиткеч урын тоткан мөһим проблемалар турында сүз алып бара: кайсы сәяси партия нинди максатны алга куя һәм көчәя барган реакция аларга нинди йогынты ясый, яңа сайланган Думада хәлиткеч көч кемнәр кулында, Россиянең иҗтимагый-сәяси тормышы алга таба кайсы юлдан барачак, мәгариф алга тәрәккыят итәме? Осталык нисбәтеннән килеп караганда бу мәкаләләр – татар сәяси публицистикасының югары үрнәкләре.

«Әльислах» – хөр рухлы газета. Аның төп бүлекләре дә, төп тематикасы да күбесенчә җәмгыятьне алга таба үстерүгә юнәлтелгән. Ф. Әмирхан публицистикасында татар халкының мәгърифәтчелеген үстерү, мәктәп-мәдрәсәләрне дәүләт карамагына күчерү, уку-укыту эшләрен рус, Европа мәктәпләре үрнәгендә үзгәртү, көндәлек тормышка, хезмәткә кирәкле белем бирә торган дөньяви фәннәр кертү зарурлыгы кебек мәсьәләләрне күрәбез. Ф. Әмирхан халыкның рухи үсешен җайга салу, мәгариф һәм

мәдәният тормышын алга җибәрү өчен иң элек аның икътисадый хәлен үзгәртергә кирәк икәнлеген еш ассызыклый. «Әльислах»-ның 1908 ел, 9 февраль санындагы баш мәкаләсендә: «...бер милләт арасында тәгъмиме мәгариф итәр өчен (гомумбелем алуны кертү өчен) иң әүвәлге шарт та – аларның әхвале икътисадиясен яхшы хәлгә китерүдер. Күз алдымызда: фәкыйрь милләт мәгарифтә гомумән тәрәкъкый итә алмаган шикелле, һәр милләтнең дә фәкыйрь әфрады, бөтен көннәрен фәкать үзләрен вә гаиләләрен ачтан үтермәс өчен сарыф итәргә мәҗбүр булып, мәгариф тәхсиленә бушый алмыйдыр», – дигән юллар бар [Әмирхан, б. 92]. «Көненә унбер сәгать кибеттә басып торган приказчиклар, көненә унбер-унике сәгать эшләп хәлдән тайган фабрик эшчеләре, ачлыктан йөдәгән крестьяннар вә балалары шул хәлләрендә калдырылган вакытта, алар өчен бер авылга, бер мәхәлләгә берәр түгел, унар мәктәп ачсаң да, әллә нинди мәгариф тарата торган җәмгыятьләр вөҗүдкә китерсәң дә, алардан файдалана алачак вә зыялана алачак түгелдер» [Шунда ук, б. 92–93]. 1908 елның 9 мартында басылган «Казан, 9 март» исемле баш мәкаләдә Ф. Әмирхан бу мәсьәләгә яңадан кайта: «Горфи бер крестьянга, бер рабочийга баласын ике-өч йөз сум расход тотып фән мәктәпләрендә укыту мөмкин түгеллеген кем инкяр итә аладыр? Мәкятибе галиягә фәкать кереп укыр өчен генә йөз сум түләргә кирәк булгач, анда укучылар күбрәге байлар булырга кирәклеге бик табигыйдер. Менә нәрсә өчен без, гавам халык мәгарифе аның әхвале икътисадиясе белән баглы, димез» [Әмирхан, б. 103].

Нинди генә темага язса да, Ф. Әмирхан саллы һәм ышандырырлык дәлилләр системасын оста эшкә җигә. «Әльислах»тагы «Тел мәсьәләсенә бер караш» (1908, 14 гыйнвар) дигән публицистик мәкаләсе авторның дәлилләү осталыгы уңаеннан аеруча игътибарга лаек [Әмирхан, б. 82–88].

Автор текстның башлам өлешендә телләр өлкәсендәге мөһим проблемаларны санап үтә, анналары җитди мисаллар белән фикерләрен дәлилләп бирә. Мәсәлән, тел мәсьәләсенең сәясәт белән турыдан-туры бәйләнеше турындагы тезис Польша, Австрия һәм Венгрия мисалында исбат ителә:

Тезис: *Тел мәсьәләсе күп заманнардан бирле сәясәткә дә иштирәк итеп килә вә актык елларга кадәр мөстәбид хөкүмәтләрнең башка милләтләргә каршы тоткан коралларыннан берсе булып киләдер.*

Дәлил: *Актык елларда поляклары шулкадәр мәшәкать белән тәкмил ителгән вә шулкадәр әдәбиятка мәлик булган телләренә каршы һөҗүмнәр, Австрия вә Маҗарстан парламентларындагы таяклар белән сугышлар һәммәсе шул җөмләдәндер.*

Тел һәм матур әдәбиятның бер-берсенә йогынты ясавы турындагы тезис та конкрет фактлар нигезендә дәлилләнә:

Тезис: *Телнең әсасән җуелуы, һичбер вакытта дияргә мөмкин, читтән ителгән һөҗүмнәрдән генә килмичә, бәлки телнең*

*әдәбиятының юклыгы вә эшләнмәгәнлегеннән киләдер.*

Дәлил: *Әдәбияты куәтле тел әллә нинди куәтле һөҗүмнәргә каршы да бирелми икәнлегене поляк теленнән вә фәнни истиляхларга бай телләр әллә нинди сәяси бәхетсезлекләргә дә чыдый икәнене хәзергә кадәр фәнни нәрсәләрдә истигъмаль итеlә торган латин вә төрек телләреннән күреп белә аламыз.*

Аннары автор гарәп теленең башка, көчсезрәк телләргә йогынты ясавы турындагы фикерне үткәрә, дәлилләү өчен башка милләтләрнең күренекле вәкилләре гарәп культурасына хезмәт итүе турындагы фактларны китерә:

*Мисал уларак, тугрыдан-тугры гарәп теленә хезмәт иткән Габделкаһир, Фәйрүз абади, Зимәхшәри кебиләрне рәттән санап китәргә мөмкин.*

Ә инде татар теленең чит тел сүзләре, бигрәк тә гарәпнекеләр белән чуарлануы хакындагы фикерен Ф. Әмирхан «Әльислах» редакциясенә шәкертләрдән килгән хатлардан өзекләр белән дәлилли:

*...башындагы заказ язылган «зате сәгадәтелмәаб, хәзрәте галиҗәнаб» дигән сүзләрдән башлап, «мәдрәсәи бракдым, утамә сукылдыкымда Хуҗа әфәндеми күрдем. Ядеңези пус идеюрем» дип тәмам булганчы, минем күңелләрем болганып, тәмам саруларым кайнап бетәдер.*

Күргәнебезчә, алдагы өзекләрдән аермалы буларак, бу дәлилдә конкрет фактлар гына түгел, авторның *күңел болгану, сару кайнау* кебек фразеологизмнар белән белдерелгән эмоциональ рухтагы шәхси бәясе дә бар.

Татар теленең көчсезлеге һәм әдәби эшләнеп җитмәве турындагы тезисны тиешенчә дәлилләгәннән соң гына автор укучыны төп тезис белән таныштыра: татар зыялыларының бурычы – туган телне киң халык катлаулары аңларлык дәрәҗәдә камилләштерү. Аннары төп тезис ярдәмче тезислар ярдәмендә конкретлаштырыла, автор куелган максатка ирешү өчен мөһим булган җиде максатны аерып күрсәтә. Алар һәммәсе дә нигезле итеп дәлилләнә. Мәсәлән, ана телен камилләштерүдә язучыларга аеруча мөһим бурыч йөкләнүе турындагы тезисны Ф. Әмирхан рус теле мисалында дәлилли:

*Рус әдәбияты белән белеш кешеләргә мәгълүм: рус теле хәзерге хәснене фәкать Пушкин кеби берничә мөхәррирләрнең иҗтиһады соңында гына хаиз була алгандыр.*

Мәкалә төп тезиста билгеләнгән максатка ирешү юнәлешендәге конкрет тәкъдим белән тәмамлана:

*Занымча, хәзер тел хезмәтенә әсас куяр өчен, интисабле затлар җыелу шарты белән киң бер съезд игълан итәргә вә игълан иткәндә дә хәзерләнерлек кешеләр хәзерләнеп өлгерер дәрәҗәдә алдан игълан итәргә кирәктер.*

Мисал итеп китерелгән бу текстның төзелеше ныклап уйланылган. Башта автор укучыга үзе күтәргән проблеманың мөһимлеген раслый торган дәлилләр китерә, аннары әлеге проблеманы чишүнең юлларын күрсәтә, текст азагында проблеманы хәл итүгә юнәлдерелгән конкрет һәм реаль тәкъдимнәр кертә. Тезиста ман-

тыйкый дәлилләү өстенлек итә: барлык тезислар җитди фактлар белән беркетелгән. Шул ук вакытта дәлилләрнең кайберләре, тел чараларын уңышлы куллану нәтиҗәсендә, психологик тәэсир көченә дә ия. Мәкаләдә халык телен өйрәнү, әдәби һәм фәнни әсәрләрне гарәп, фарсы алынмаларыннан, грамматик элементларыннан арындыруның, әдәбият тарихын булдыруның һәм аның бүгенге үсешен тәэмин итүнең бөтен бер программасы бирелгән.

«Әльислах»ның үзенең теле дә ул вакытта чыга торган газеталарның теленнән бик нык аерыла. Монда госманчылык-төрекчелектән баш тартып, татар телен мөстәкыйль тел итеп тану чагыла. Ф. Әмирхан язмаларының теле бер яктан гади, икенче яктан бизәкләү чараларына, шулай ук шәхсилекне ассызыклаучы чараларга бай булуы белән аерылып тора. Ул, җәмгыятьне дулкынландырган мөһим социаль күренешләрне чагылдырып, аларга карата үзенең шәхси мөнәсәбәтен белдерә, шул ук вакытта зур гомумиләштерүләр дә ясый. Текстларын төзегәндә кабатланмас алымнарга мөрәҗәгать итә. Әйтик, «Әльислах»та чыккан «Авырулар галәмендә» исемле язмасын (1908, 20, 27 июнь, 14 август) ул көчле контрастлар кулланып иҗат иткән [Әмирхан, б. 123–132]. Автор табигатьтәге тигезсезлек һәм шәфкатьсезлек белән кешелек дөньясындагы тигезсезлек арасында параллель уздыра:

*Әй сез, агачлар, ник берегез озын да, берегез кыска булып үстегез? Кем сезнең белән шаярды? Кемгә сезнең берегез озын булганда, икенчегезнең кыска калуы кирәк булды?*

Шулай да текст авторы социаль тигезсезлекнең юкка чыгачагына ышаныч белән карый. Язманың соңгы юллары оптимистик рухта:

*И таң, ат инде тиз генә! Мин сине көтәм һәм тиздән булуыңа ышанам.*

Шулай итеп, кешеләрне яшәү ләззәтеннән мәхрүм итә торган чирләр иҗтимагый тормыштагы тигезсезлек, золым һәм кара көчләр бер рәткә куела. Авырудан, табигатьтән зарлануның социаль тигезсезлекне күреп эч пошудан, реакциянең көчәя баруыннан килеп чыгуы аңлашыла. Әмма бу хисне тормышның яңарачагына, прогрессив көчләрнең котылгысыз рәвештә җиңәчәгенә ышаныч җиңә. Бу язманың жанрын сәяси эссе буларак билгеләргә мөмкин.

Үз иҗатында Фатих Әмирхан хат күзәтү жанрына да зур игътибар биргән. Аның «Гәзитәләр галәменнән» дигән язмасы (Әльислах, 1908, 14 гыйнвар) шушы жанр өчен хас үзенчәлекле төзелешкә ия [Әмирхан, б. 91–92]. Язмадагы һәр яңа тезис риторик сорау белән беркетеп куела:

*«Вакыт» гәзитәсе бик тырышып-тырышып социализм белән сугыша, ахыргы номерда «Җыелыгыз, бөтен дөнья эшчеләре!» дип башлап бер мәкалә язып, социалистлардан бик хур итеп көлде.*

*Фәкать шуны гына беләсе иде: мондый һөҗүмнәрдән социализм фикеренең ничә шөребе какшады икән?*

*Әстерханда нәшер ителә торган «Идел» гәзитәсе бик*

*тырышып «Шураи Ислам» белән сугыша.*

*Шуны беләсе иде: кайчан аңар җеназа укырга тели икән?*

*«Әхбар» газитәсендә Г. Ибраһимовның «Менә шундый вакытларда русның табигате яхшы күренә инде» дип, бөтен рус милләтенә бер-ике кешенең эшләгән эшләрен иснад иткән мәкаләләре языла башлады.*

*Беләсе иде: рус милләте мондый һөҗүмнәргә ничек итеп кайгыра икән?*

*...«Әльислах» газитәсе дүртенче ай мәдрәсәләр мәсьәләсен чәйни.*

*Беләсе иде: кайчан өзәрем дип уйлый икән?*

Автор үзе тәкърар иткән тезисларның тискәре характерын бер үк калыптагы риторик сорау җөмләләрне (Шуны беләсе иде..., беләсе иде...) кабатлаулы куллану аша гына түгел, алар составындагы лексик-фразеологик характердагы көлкеле сурәтләү чаралары белән дә (һөҗүм, ничә шөребе какшады, җеназа укырга, кайчан өзәрем дип уйлый) белдерә. Текстның әнә шундый үзенчәлекле төзелеше нәтиҗәсендә берничә татар вакытлы басмасының юнәлеше сатирик рәвештә кискен тәнкыйть утына тотыла.

Ф. Әмирхан публицистикасында аерым урынны сатира алып тора. Әйтик, «Кечкенә фельетон (Гласный булган идем дә, 300 шар җитми калды)» исемле фельетоны – сатирик публицистиканың матур бер үрнәге булып тора [Әмирхан, б. 151]. Публицист биредә сатираның көчен искелеккә, торгынлыкка каршы юнәлдерә. Татар журналистикасында беренчеләрдән булып Фатих Әмирхан вакытлы матбугат битләрендә диалогик төзелешле текстлар бастыра. Мондый әсәрләргә (мәсәлән, интервьюга) карата куела торган мөһим таләпләрнең берсе – әңгәмәдәшнең сөйләм үзенчәлекләрен мөмкин кадәр саклау. Моның өчен автордан телнең мөмкинлекләрен яхшы белү сорала. Кызганыч ки, бүгенге журналистикадагы диалогик язмаларның күпчелегендә әйтелгән таләп төгәл үтәлми. Ф. Әмирхан әсәрләрендә исә сөйләшүдә катнашучыларның индивидуаль сөйләм үзенчәлекләре гаять оста бирелә. Бу уңайдан аның «Әльислах» газетасында чыккан һәм диалогик текст формасында язылган «Зурлар белән мәдрәсәләр берләштерү хакында мөзәкәрә» дигән фельетоны игътибарга лаек [Әмирхан, б. 110–116].

Бу әсәрен автор язманың темасы игълан итүдән һәм әңгәмәдәшләр белән таныштырудан башлап җибәрә:

*«Әльислах» мөхбирлеге сыйфатым белән Казан мәшаһиренең мәдрәсәләр берләштерү хакындагы фикерләрен сораштырып йөрдем. Әүвәл бу мәсьәләдә бик мөһим урын ишгаль иткән кешеләр дип муллаларга барырга карар биреп, алар арасында да картрак вә зуррак дәрәҗәлесе дип ахундка бардым.*

Аннары автор Йосыф ахун белән булган сөйләшүен тәкъдим итә:

*Йосыф хәзрәттә.*

*Мин:*

*– Тәхсир, хәзер мәдрәсәләр берләштерү мәсьәләсен кузгат-*

*тылар. Шул тугрыда сезнең дә фикереңезне белергә телим.*

*Ахун:*

*– Әнәтерәк, инде һәммәсен дә бер ясыймыз диләрмени? Әнәтерәк, мулла Галимҗанмы инде? Шулай димени инде?*

*Мин:*

*– Тәхсир, шулай диләр.*

*Ахун:*

*– Әнәтерәк, байлар ни диләр соң?*

*– Белмим.*

*– Әнәтерәк, без байлардан узмамыз инде. Шулай инде. Мулла Галимҗан минем мәдрәсәне бетермәкче димени инде?*

Ф. Әмирхан әңгәмәдәшенең сөйләм үзенчәлекләре аша аның характер чалымнарын да тапшыра алган. Сораугa сорау белән җавап бирү – икеләнү, ныклы фикер булмау билгесе. Автор ахунның сөйләм үзенчәлекләре аша (әнәтерәк, инде кебек паразит сүзләр куллану) аның үз фикерләрен беркадәр ашык-пошык, уйлап җиткермичәрәк әйткәнен дә белдерә алган.

Ә менә Галимҗан хәзрәтнең уйланган, төпле һәм төгәл җаваплары аның тыныч холыклы, вәкарьле (автор моңа үзе дә басым ясый) кеше икәнлеген ассызыклый:

*Галимҗан хәзрәттә.*

*– Тәхсир, тәүхиде мәдарис хакында фикереңез?*

*(Вәкарь белән генә):*

*– Мәдрәсәләрне берләштерү, инша аллаһ, файдадыйн хали булмаз. Аллаһ вә рәсүлә ризалыгы сарый ашыгучылар бу эштә гыйнад вә мөкябәрә итмәскә ляземдер. Берләштерү матди җәһәт сартин да файдадин хали булачак дәгел.*

*– Рәхмәт, әссәләмәгаләйкем.*

Кыска гына диалогик өзектән әңгәмәдәшнең гаять динле кеше булуы (*инша аллаһ, аллаһ вә рәсүлә ризалыгы сарый ашыгучылар* кебек гыйбарәләр), өстәвенә дини гыйлемнәргә ия кеше булуы ачыклана.

Тагын берничә дин әһеле янында булганнан соң, Ф. Әмирхан газета мөхәррирләренә сорау бирә. Алар арасыннан Һади Максудиның сөйләме гади һәм аңлаешлы булуы белән аерылып тора. Ә Борһан Шәрәфнең сөйләм үзенчәлекләреннән аның кызу канлы, тиз кабынучан һәм хисле кеше булуын чамаларга мөмкин. Аның бу үзенчәлекләрен сөйләмендәге сорау, өндәү һәм тойгылы җөмләләр, риторик сораулар, ымлыклар (*һа-һа*), кабатлаулар (*фикерме – фикер; шул Казан муллаларыннан – шул бары алар өстеннән кеше көлсен өчен генә яратылган кешеләрдән; кайда эш эшли алганнары бар – кайда зарар китерми калганнары бар; берләштерү дә булмый – башка да булмый*), шулай ук ремаркалар аша әңгәмәдәшнең ишарәләрен тасвирлап бирү кебек чаралар тапшыра.

Әсәр автор сөйләменә караган түбәндәге очлам белән төгәлләнә:

*Мәзкүрә әфкяре кыл кадәр улсын ихтирафтан башка тәблигъ иттек.*

Чынлап та, сөйләм ияләренең фикерләре дә, тел чаралары да бер-берсеннән нык аерылып торуы бу фикерне тагын бер кат раслый.

Ф. Әмирхан күп кенә сатирик әсәрләрендә кадими

мәдрәсәләрдә укыту рәвеше, тәрбия чараларының искергәнлеген, мәгънәсезлеген кискен тәнкыйтьли. «Мәктәпләрдә хөррият рухы», «Зыялы» шәкерт» фельетоннары, «Егерменче гасыр әфьюнчысы» дигән памфлет-рецензия әнә шул максаттан язылган.

«Әльислах»та Ф. Әмирхан, фикердәше Г. Тукай белән берлектә, татар әдәби тәнкыйтенә нигез сала, шагыйрь белән дуслыгы тагын да ныгый. Газетада ул татар әдәбияты торышы, аның үсеше проблемаларын тикшерүгә киң урын бирә. «Әдәбият кичәсе», «25 ндә татарча театр уены», «Әдәбиятка гаид», «Мәктәпләребездә әдәбият дәресләре», «Татарча спектакльләр» исемле мәкаләләрендә татар халкында «мәгыйшәте гомумиянең» башлануына зур шатлану белдерелә. Әдип бу публицистик әсәрләрендә татар яшьләре күңелендә «әдәбият, театр», «музыка вә хәяте гомумия хиссиятләренең» нык урын алачакларына ышана һәм татар халкында «әхлакы хәсәнә тәгаммем» итә башлавына чын күңелдән сөенә. «Әльислах» битләрендә «Яңа китаплар» яки «Китаплар хакында мөхакәмә» дигән аерым бер бүлек тә яшәп килә. Анда яңа әсәрләргә багышланган рецензияләр урнаштырып барыла. Ф. Әмирхан тәнкыйди публицистика жанрында гаять актив эшли. Фикердәшләренә таянып, ул тулаем әдәбият-сәнгать проблемаларына гына багышланган яңа журнал чыгару идеясе белән яна башлый. Нәтиҗәдә, 1912 елның декабрь уртасында әдәбият, сәнгать юнәлешендәге «Аң» журналы чыга башлый. Г. Тукай беренче сан өчен махсус «Аң» исемле шигырь иҗат итсә, Ф. Әмирхан «Шәрекъ йоклый» дигән мәкаләсен яза. Исеменнән үк аңлашылганча, Ф. Әмирхан халыкны озакка сузылган йокыдан уянырга чакыра. «Аң» моннан соң да аның әсәрләренә киң урын бирә. Фатих Әмирхан исә бу чорда үзенең бөтен тырышлыгын яңа матбугат органы – «Кояш» газетасына күчерә. Биредә ул карагруһчылыкны, милләтчелекне, империалистик дәүләтләрнең реакцион халыкара сәясәтен тәнкыйть иткән байтак материал урнаштыра.

1913–1917 елларда татар әдәбияты, публицистикасы һәм тәнкыйтендә Ф. Әмирхан кадәр актив эшләүче булмый, дип билгеләп үтә М. Мәһдиев [Мәһдиев, б. 78]. Чөнки бу вакытта Г. Тукай вафат, Г. Камал һәм Г. Коләхмәтов авырыйлар, Ш. Камал «Акчарлаклар»дан соң тынып калган, Г. Ибраһимов зур романга керешкән. Ф. Әмирхан бөтен татар әдәбияты, мәдәнияте мәсьәләләре өстендә берүзе эшли, көн-төн яза.

Совет власте елларында да Ф. Әмирхан иҗтимагый тормыштан читтә яшәми. «Кызыл Армия», «Татарстан», «Татарстан хәбәрләре» газеталарында, «Шәрекъ кызы», «Кызыл шәрекъ», «Безнең юл» журналларында яңа тормыш идеалларын пропагандалый.

Ф. Әмирхан публицистикасы төп сыйфатларының берсе – максат аныклыгы. Ул нәрсә өчен язганын, нәрсәгә ирешергә теләгәнен аңлап эш иткән. Шул максатына ирешү өчен журналистик чараларны дөрес сайлый

һәм барлык жанрларда да бертигез әйбәт яза белгән. Ф. Әмирханның иҗтимагый-сәяси темага язылган очерк һәм мәкаләләре җитди гомумиләштерүләргә ия. Җәмгыятьтә яшәп килгән тискәре күренешләрне тәнкыйтьләү өчен ул фельетоннар язган. Киң колачлы проблемалар куярга мөмкинлек бирә торган жанрлардан тыш, Ф. Әмирхан рецензия, интервью, репортажларны яратып кулланган. Аның күренекле язучылар иҗатына, яңа дөнья күргән китапларга багышланган рецензияләре тирән эчтәлеккә ия. Ф. Әмирхан хисап, хәбәр, репликаны да эшкә җиккән. Аларны матбугатның иң хәрәкәтчән, җитез, үтемле формалары дип санаган.

Ф. Әмирханның матбугат һәм журналистикага карашлары кызыклы. Вакытлы матбугат нинди булырга, нәрсәләр турында язарга, халык белән нинди элемтәдә булырга тиешлеге 1913 елны дөнья күргән «Төркстан шивәсендә матбугаты мувәкъкатә» исемле мәкаләсендә ачык чагыла [Әмирхан, б. 230–234]. Бу мәкалә бүген дә аерым өйрәнүгә лаеклы. Ул татар матбугатының беренче көннәреннән үк мәгърифәтчелек һәм халык азатлыгы рухында эшләвен күрсәтә. Мисал буларак, Ф. Әмирхан Төркстанда чыгарылып килгән берничә газетаны тасвирлап китә – мөхәррирләре, газеталарның юнәлешләре турында сүз йөртә, Сәмәрканд халкының газета алдырмау сәбәпләрен ачыклый. «Сәмәрканд» газетасының мөхәррире – «үзе төркстанлы, Төркстанның шивәсен дә, тормышын да яхшы белә торган голәма хезмәтендәге зат булганга күрә, аның гәзитәсенең Төркстан өчен кирәкле бер гәзитә булып чыгуы бик өмидле иде» [Шунда ук, б. 232]. Ләкин бу газета, укучылары булмау сәбәпле, чыгудан туктый яза. Ни өчен? Газета көндәлек түгел. Димәк, ул, беренчедән, хәбәрләрне вакытында ирештереп тора алмый. Икенчедән, анда барлык хәбәрләр өчен урын җитмәячәк. Димәк, газета аларны «бик чүпләп кенә дәреҗ итәргә, бик күп нәрсәләрне бөтенләй дәреҗ итми узарга мәҗбүрдер» [Шунда ук]. Газетаның ике номеры арасында шактый вакыт үтә. Укучылар вакыйгаларның тәртибен һәм «мантыйкый төзелешен югалтып өлгерә», алар вакыйгаларның эзлеклелеген югалталар. Шуңа күрә «халык матбугаты мувәкъкатәдән ләззәт алырга өйрәнми, ягъни үзенең истикъбале өчен мөштәриләр хәзерли алмый» [Шунда ук]. Икенче яктан, газета ни өчен көн саен чыкмый? Чөнки мөхәррирләр газетаның көн саен чыгып торган ихтималда сатып алынып бетүенә ышанмыйлар шикелле.

Ф. Әмирхан газетаның көн саен чыгып торуы мәҗбүри икәнен энә шулай аңлата. Бу – вакытлы матбугат өчен беренче шарт. Көн саен булмаса, газета атнага һич югы дүрт тапкыр чыгарга тиеш. Дөрес, кемнәрдер: «Моның өчен зур капитал кирәк», – диярләр. Әмма Ф. Әмирхан аларга: «Бу капиталны табарга кирәк», – ди. Бәлкем, бер-ике ел мөхәррирләр файда урынына зарар күрерләр, әмма шул арада халык газетага «комарланып өлгерер»,

дип фикер йөртә Ф. Әмирхан. Һәрхәлдә, газетаны чыгаручылар әнә шуңа ашкынырга тиеш. Ә аннан соң газета инде «үз расходын үзе күтәрә башлый вә, яңадан берәр ел үткәч, һич шөбһәсез, наширләренә файда китерә башлый» [Шунда ук, б. 233]. Бу уңайдан Ф. Әмирханның мөхәррирлек хезмәтенә бәйле бер истәлек кызыклы. К Мостакаев язучыдан «Әльислах»ның торышы турында сорый:

«Үз нәүбәтемдә мин дә Фатихтан “Әльислах” турында сораштырдым. Ул теләр-теләмәс кенә итеп:

– Хәзергә мәгънәви яклары канәгатьләндерми әле, ә материаль ягына килсәк, анысы инде безнең, шул җөмләдән сезнең дә, халыкны ни дәрәҗәдә мавыктырырлык тырышып эшләвебезгә бәйләнгән» [Мостакаев, б. 79].

Димәк, Ф. Әмирхан газетада басылган материалларның эчтәлегенә бик зур әһәмият биргән. Ә матди ягын газетаның эчтәлегенә бәйле дип санаган. Икенче шарт – газеталарда илдә барган вакыйгаларның барлык нечкәлекләрен җентекләп сурәтләп бару. Ягъни газета алдыручылар «комарлансын» өчен шартлар тудыру. Бу очракта без Ф. Әмирханның көн тәртибендә торган материаллар турында сүз йөрткәнен аңлыйбыз. Укучы бүген ни турында уйлый, нәрсәләр турында укырга тели – журналист әнә шуларны белергә һәм язарга тиеш. Көндәлек вакыйгаларны сурәтләп барган газета һәр көн укучы тарафыннан күтеп алына.

Өченче шарт үзеннән-үзе алдагылардан килеп чыга – вакытлы матбугатта сурәтләнгән вакыйгаларның үзара эзлеклелеге, логик бәйләнеше саклану. «Җитди вә хәзалыкның рухын вә мәнафигын аңлап яза торган бер гәзитә лязем», – дип яза Ф. Әмирхан [Әмирхан, б. 232]. Бүген бер нәрсә турында башлап, иртәгесен икенче нәрсәгә сикереп, яза башлаганны ташлап, ярты юлда калдырып киткән матбугат җитди укучыга кирәкми. Шуңа күрә ул көндәлек булырга да мөмкин түгел. Аны көн саен алмаячаклар.

Әлбәттә, газета алдырып китсен өчен, аның башында тәҗрибәле мөхәррир тору мәҗбүри. Ф. Әмирхан илдә хәтта хөррият булмаганда да, газета, шундый мөхәррире булганда, чиновникларга артык бәйле булмыйча, басылудан тукталмаячак, ди һәм мисалга Исмәгыйль Гаспринскийны һәм аның газетасын китерә.

Газета сәяси яктан уртача булырга, милли мәсьәләләрне ишарәләр белән генә әйтергә, ачык дәгъвалар урынына ноктәлар гына куеп китәргә мөмкин, әмма ул яшәсен, халыкны укырга, вакытлы матбугатны дөньяны күзәтергә өйрәтсен, халыкка мәдәният алып барсын – аның бурычлары әнә шул! Бүгенге журналистикабыз өчен дә гаять мөһим фикерләр бу.

Фатих Әмирханның журналистика өлкәсендәге бөтен булган иҗаты да милләтне тәрәккыят иттерүгә, халыкны рухи азатлыкка алып чыгуга, дөньяның алдынгы милләтләреннән берсенә әверелдерүгә хезмәт итә.

**Әдәбият**

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр. 4 томда. III том. Публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 512 б.

*Нуруллин И.З.* Прометей из Новотатарской слободы. Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. 270 с.

*Нуруллина Р.М.* Тарих яза каләмем... Казан: Казан ун-ты нәшр., 2009. 336 б.

*Магдеев М.С.* Фатих Амирхан: Краткий очерк о жизни и творчестве писателя. Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. 83 с.

*Мостакаев К.* Габдулла Тукай һәм Фатих Әмирхан белән күрешү // Фатих Әмирхан турында истәлекләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. Б. 76–82.

***Гарифуллин Васил Заһит улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Казан (Идел буе) федераль университетының*
*татар журналистикасы кафедрасы мөдире*

УДК 821.512.145

***Т.Ш. Гыйлаҗев***

# Ф. ӘМИРХАННЫҢ ӘДӘБИ-ТӘНКЫЙДИ ЭШЧӘНЛЕГЕ

В данной работе рассматривается литературно-критическая деятельность Ф. Амирхана. Оценивается вклад писателя в формирвание татарской литературной критики. В статье выявляются основные темы и характеристики данного вида его творчества.

**Ключевые слова:** критика, писательская критика, типы критики, реалистическая критика, народность, жанры, методы, репутация.

Әдәби җәмәгатьчелек арасында тирән белеме һәм фикер үткенлеге белән танылган абруйлы Ф. Әмирхан татар әдәби тәнкыйтенә нигез салучыларның берсе булып тора. Ул киң карашлы, нечкә зәвыкле, эрудицияле тәнкыйтьчеләрдән санала. Аның бу төр эшчәнлегендә агымдагы тәнкыйди барышны бәяләү төп юнәлешне тәшкил итсә дә, тәнкыйтьнең предметы, жанрлар системасы, әсәрне бәяләү принциплары, алым-методлары, типлары һәм юнәлеш-агымнары кебек нәзари мәсьәләләр дә гыйльми күзаллана. Г. Сәгъди аның үткен каләмен, таләпчән, принципиаль тәнкыйтен күздә тотып, «карчыга күзле» беренче әдәби тәнкыйтьче» [Сәгъди, б. 15] дип атый.

Яңа татар әдәбиятының үсеш юнәлешен билгеләгән реалист Г. Исхакый, Г. Тукай, Г. Камал, Г. Коләхмәтов, М. Гафури иҗатлары Ф. Әмирхан тәнкыйтенең бәяләү объекты булып тора. Аларның әдәби әсәрләре басылып чыгу уңаеннан дөнья күргән мәкаләләрендә, рецензияләрендә әдәбиятның иҗтимагый роле, чынбарлыкка мөнәсәбәте, сүз сәнгатенең милли характеры, реализм, халыкчанлык һәм әдәби осталык, театр тәнкыйте мәсьәләләре күтәрелә. Әдәбият һәм сәнгатьнең бурычын ул мәгърифәт тарату һәм әхлак төзәтүдә билгеләү белән бергә, иҗтимагый-милли мәсьәләләрне күтәрүдә, сәяси һәм икътисади стройның асылын сәнгатьчә ачып бирүдә билгели, ягъни «әдәбиятның иҗтимагый ягын югары күтәрә, аның җәмгыятькә тәэсир көчен фәнни мәктәп, юнәлешенең нигезен сала, җәмгыяви һәм милли мәсьәләләрне хәл иткәндә төп сүзне әйтүче икәнлеген күз уңында тота» [Заһидуллина, б. 173].

Ф. Әмирхан башлангыч чор тәнкыйди эшчәнлегендә, шушы ноктадан якын килеп, заман таләпләренә җавап бирмәгән Г. Тукайның тәүге шигырьләрен, Я. Вәли, М. Гафури, М. Фәүзи әсәрләрен тәнкыйтьли. Мәсәлән, Г. Тукайның «Мужик йокысы» исемле А.В. Кольцовтан (1809–1842) ирекле тәрҗемәсендә авыл мужигы үзенең ялкаулыгы аркасында ярлы, авыр тормышта яши дигән идея үткәрелә. Ә Ф. Әмирхан «Мал юк дип зарланма, үзеңнән күр аны» дигән шигырьләрнең мәгънәләре берлә

Русия җир тарихын вә сәясәтен белгән кешеләр канәгать итмәячәктер» [Әмирхан, 1986, б. 22], – дип искәртә. Я. Вәлинең пьесасына язылган «Ачлык кушты» (1908) рецензиясендә тәнкыйтьче иҗтимагый-социаль проблемаларны Россиянең социаль-икътисади җирлеге белән тыгыз бәйләнештә сурәтләүне таләп итеп чыга: «Мондый олуг темалар *(ачлык темасы. – Т.Г.),* хосусән, бөтен бер халыкның, хәтта бер мәмләкәтнең халәте икътисадиясеннән *(икътисади хәленнән. – Т.Г.)* килгән күренешләр хакында язылган драмалар социальный характерда язылырга вә асыл сәбәп булган ямanлык, төрле тарафларыннан вә сәбәпләре белән тәфтиш ителеп *(аңлатылып. – Т.Г.),* укучы күз алдына тәрсим ителергә *(сурәтләнергә. – Т.Г.)* тиештер. Әмма «Ачлык кушты» драмасы нәкъ шушы нәрсәләрдән мәхрүм» [Әмирхан, 1986, б. 85]. Г. Коләхмәтовның «Яшь гомер»ендәге Зөләйха образы гәүдәләнешендәге җитешсезлек тә капитал, акча-товар мөнәсәбәтләре яссылыгында күрсәтелә: «Мөхәррир монда капиталның тугрыдан-тугры көчләве буенча кияүгә чыгуны тасвир иткән булса, драманың гомуми фикеренә кәмаль *(камиллек. – Т.Г. )* вә яңа рәүнәкъ *(төс. – Т.Г.)* биргән булыр иде» [Әмирхан, 1986, б.41].

Әдәби иҗатка йогынты ясаган шартлар, иҗтимагый күренешләр, милли чынбарлык вакыйга-хәлләре белән әсәр арасындагы бәйләнешләр беренче планга чыгарылу, әдәби әсәрне җәмгыятькә, андагы процессларга бәйле тикшерүгә йөз тоту Ф. Әмирхан тәнкыйтен публицистик тип кысаларында тикшерергә мөмкинлек бирә. «Әдәби әсәргә нисбәтле язылган текстта иҗат мәсьәләсе, аңа эстетик яктан бәя бирү теге яки бу дәрәҗәдә урын алса да, язма авторы яшәешнең күп төрле сорауларын читләтеп үтә алмый, ягъни чор-заман проблемалары фәлсәфи, әхлакый, сәяси, тарихи мәсьәләләр белән үрелеп, ялганып китә» [Закирзянов, 2011, с. 209], – дип яза Ә. Закирҗанов. Ф. Әмирхан тәнкыйте белән XX гасыр башында үсеш юлына чыккан публицистика арасында бәйләнеш аеруча көчле.

Әдәби тәнкыйтьнең юнәлешләрен һәм агымнарын аерып чыгарып, аларның үзенчәлекләрен билгеләү омтылышы 1920 еллар татар тәнкыйтендә үк башлана. Әдәби-тәнкыйди фикерне тарихи процесс буларак тикшерү юлында беренче сукмакны салган Г. Сәгъди, Ф. Әмирханның әдәби әсәрне бәяләү принципларына таянып, аны «реалист тәнкыйтьче» [Сәгъди, б. 16] дип атый. «Реаль тәнкыйть нигезендә чор картинасын тудыру, ягъни заман, хакимият, гомумән системаның бөтенлекле образын күз алдына бастыру тора. Аның концептуаль җирлеген әсәрләрдә тудырылган тормыш моделе үзенчәлекләре билгели» [Закирзянов, с. 238].

Ф. Әмирханның Г.Исхакый әсәрләренә язылган рецензияләрендә матур әдәбиятның реаль чынбарлыкны тулы һәм дөрес чагылдыру хасияте бары тик җанлы һәм тормышчан образлар, табигый типлар тудыру, детальләр

дөреслеге ярдәмендә тормышка ашырыла дигән фикер, кагыйдә үзәккә куела. Мәсәлән, «Алдым-бирдем» рецензиясендә тәнкыйтьче пьесаның сюжеты нигезендә яткан төп каршылыкны – яңа тормыш белән иске тормыш арасындагы көрәшне билгеле, милли чынбарлыктагы тартышны типлар аркылы анализлый. Тип терминын түбәндәгечә аңлата: «Тип» дип, мәгыйшәттән *(тормыштан. – Т.Г.)* алып ясалган вә тасвир ителә торган мәгыйшәтнең халыклары арасында махсус бер фиркагә *(катлауга. – Т.Г.)* тугры килә торган сурәте әдәбиягә әйтеләдер» [Әмирхан, 1989, б. 71]. «Алдым-бирдем»дәге һәрбер персонажның татар тормышыннан алынып, тип дәрәҗәсенә җиткерелеп эшләнүе билгеләнә.

«Солдат» (1908), «Мөгаллим» (1914), «Зөләйха» (1917) рецензияләрендә дә Ф. Әмирхан реалистик тәнкыйть кануннары белән эш итә. «Гаяз» (1907) мәкаләсендә, иң беренче нәүбәттә, Г. Исхакый каләменең реалистик табигатен тотып ала: «... язган нәрсәләре белән йөрәкләрне кузгата, күңелгә әллә нинди фикер вә хисләр бирә вә мәгыйшәтнең начар вә яхшы якларын ачык күрсәтә торган мөхәррир» [Әмирхан, 1989, б. 28]. Ул әдип әсәрләрендә гәүдәләнгән тормыш материалының иҗтимагый-социаль, милли азатлык мәсьәләләре белән тыгыз бәйләнешенә һәрдаим үз игътибарын юнәлтеп бара.

«Солдат» рецензиясендә, автор җәмгыятьтә хөкем сөргән сәяси хәлгә бәйле рәвештә, повестька тиешле, теләгән бәя бирә алмавын сиздертә. Г. Исхакыйның иҗтимагый-сәяси эшчәнлеген, шуның бер өлеше «Зиндан»да тасвир ителүен хуплый. Әсәрне әдәбият һәм фикер үсешен күрсәтә торган повесть дип атый. «Мөгаллим» рецензиясе пьесаның «Шәрык» клубында уйналу мөнәсәбәте белән язылу сәбәпле, театр тәнкыйте белән үрелеп китә. Кимчелек буларак күрсәтелгән бертарафлылык, безнең карашыбызча, әсәрдә сыйнфый көрәш, азатлык хәрәкәтләре яктыртылуга тиешле игътибар бирелмәүне белдерә. Алдагы рецензияләрендәгечә пьесаны бәяләүдә төп бизмән булып татар тормышын реаль вакыйгаларда дөрес итеп үз кыяфәтендә чагылдыру принцибы тора: «Татар мөгаллиме тормышының Гаязның маһир куллары тарафыннан ясалган картинасы безнең алда авыр, фаҗигале вә өмидсез булып басып торадыр. Моны күреп җан ачына, сызлана, пьеса бер трагедиягә, рухани трагедиягә әйләнә» [Әмирхан, 1989, б. 247].

Билгеле булганча, «Зөләйха» фаҗигасе 1912 елда язылып бетсә дә, 1917 елга кадәр рәсми төстә тыелып килә. 1917 елгы февраль инкыйлабы биргән мөмкинлекләрдән файдаланып, «Зөләйха» пьесасы «Сәйяр» труппасы тарафыннан аның җитәкчесе һәм режиссеры Г. Кариев бенефисына 1917 елның 17 мартында Казанның Зур драма театры сәхнәсендә күрсәтелә. Бу зур тарихи фаҗига милли театр хәрәкәтендә әле күрелмәгән яңа сәхифә ача. Җәмәгатьчелек бик җылы кабул иткән бу спектакль вакытлы матбугатның да игътибарын бик тиз

арада үзенә җәлеп итә. Газетада басылган беренче язманың авторы Ф. Әмирхан әсәрнең темасының иҗтимагый-милли әһәмиятенә басым ясый: «Зөләйха – талантлы каләм, хәссас (сизгер) рух белән язылган, урыны-урыны белән гаять тирән рухани фаҗигане караучының алдына китерә торган пьесадыр. Бу иске хөкүмәткә каршы гаять куәтле бер обвинительный акт булуы белән бергә, милләтемезнең үз кодсияте *(изге. – Т.Г.)* юлында һичбер төрле фидаилектән кире тормас дәрәҗәдә рухка малик фәрдләре *(ия шәхесләре. – Т.Г.)* барлыгын күрсәтә вә бөтенлегебезне саклауда исламның нинди шәрәфле бер роль уйнаганлыгын исбат итә торган бер васикадыр *(нигезле дәлилдер. – Т.Г.)*» [Әмирхан, 1989, б. 327–328]. Рецензия эчтәлеге, Ф. Әмирханның киң диапазонлы публицистикасы белән кушылып китеп, татар халкын милләт буларак саклап калуда ислам диненең ролен күрсәтә. Аерым фактлар, сыйфатлар белән конкретлаштырылмаса да, «Зөләйха» фаҗигасе сәнгатьчә эшләнеше, камиллеге ягыннан татар драма әсәрләреннән аерып куела: «халис *(саф. – Т.Г.)* әдәби җәһәтеннән дә, пьеса мәүҗүд *(бар булган. – Т.Г.)* пьесаларыбызның 99 фаизеннән өстен тора вә урыны-урыны белән гүзәллекнең югары дәрәҗәләренә ирешәдер» [Әмирхан, 1989, б. 329].

Ф. Әмирхан тарафыннан әдәби тәнкыйтьнең теоретик мәсьәләләре эшләнүгә аның Рус – Аурова әдәбият белеме, мәдәнияте ирешкән казанышлар белән танышлыгы зур йогынты ясый [Gilazov, Karabulatova..., 2015, p. 510]. Аңа типик характерлар тудыруда И.С. Тургенев тәҗрибәсе ярдәмгә килсә, психологик анализга ирешү осталыгы Л.Н. Толстой ярдәменнән башка була алмаган. Н.В. Гогольнең тууына 100 ел тулу уңаеннан язылган юбилей мәкаләсендә әдипнең рус әдәбияты мәйданында тоткан урыны хакындагы уйланулары Ф. Әмирханны татар әдәбиятының үсеш юнәлеше мәсьәләсенә тоташтыра. Ул татар халкының көнитешен, яшәешен уңай якка үзгәртү, милли әдәбиятны яңарту өчен рус әдәбиятына йөз тотарга тиешлекне дәлилли: «Ватандашларыбыз русларның мәгыйшәти руханилары (*дөньяви караш иҗат итүчеләре. – Т.Г.)* белән белешләнү безгә файдалы гына түгел, бәлки ваҗибтыр *(тиештер. – Т.Г.):* без алар аркылы Гарби Европа белән белешләнәчәк һәм тормышыбызда һәр көнне рус мәгыйшәте белән очрашып торабыз һәм торачак; билахирдә *(ахырда. – Т.Г. ),* рус әдәбияты безнең яңа әдәбиятыбызга күп тәэсир итә генә түгел, бәлки күп ярдәм итәдер» [Әмирхан, 1986, б. 94].

Ф. Әмирханның әдәби-тәнкыйди эшчәнлегендә Г. Тукайның шигъри осталыгын, халыкчанлыгын һәм миллилеген, тел-үзенчәлекләрен ачып бирү, шәхесенең иҗтимагый кыйммәте кебек мәсьәләләр зур урын алып тора. Шагыйрь иҗатын чагыштырма-тарихи ысул белән әдәби-мәдәни багланышлар контекстында тикшерү юнәлешенең юл башында да Ф. Әмирхан тора. Тәнкыйтьче шагыйрьнең

басылып чыккан һәрбер шигырь җыентыгына язылган бәяләмәләрендәге караш-хөкемнәре, аның шигъри дөньясын бәяләү принциплары һәм кагыйдәләре белән Тукай гыйльмиятенең фәнни концепциясен эшләүгә зур өлеш кертә. Г. Тукайның шигырьләренең телен этрафлы итеп анализлый, үзгәрешен күзәтә һәм шуның белән тел-өслүбне әсәр бәяләүнең мөһим үлчәменә әйләндерә. «Аның «Ислах»тагы каләм иптәше булган Г. Тукайның шигырьләрен яңа эзгә төшерүдә, бигрәк шагыйрьнең телдә татарлашуына бу тәнкыйтьләрнең (һәм, гомумән, араларындагы якын мөнәсәбәтнең. – *Җ.В.*) тәэсире булганлык һич шөбһәсез» [Кара: Гыйлаҗев, б. 182], – дип яза Җ. Вәлиди.

Ф. Әмирханның әдәбиятта халыкчанлык һәм миллилек турындагы әдәби-эстетик карашлары төгәлләнгән бер системаны барлыкка китерә: «Үз милләтеңне кирәгенчә сөяр өчен, аның рухын аңларга, аның халәте руханиясендәге бик нечкә мусика *(музыка. – Т.Г.)* тамырларын чиертеп, шуларның чыгарган тавышларын тыңлый белергә кирәктер. Шул вакытта гына кабык астына яшерелгән куәи руханияне *(эчке көчен. – Т.Г.),* ләтафәт *(гүзәллек. – Т.Г.),* матурлыкны күреп яратырга мөмкин буладыр. Бер кавемнең рухын аңлау фәкать аның әдәбияты аркылы гына мөмкиндер [Әмирхан, 1986, б. 106]. Монда ул, һичшиксез, милләтнең язмышы, аны борчыган проблемалар, уй-фикерләрен аларның кайгы-шатлыкларын күздә тота, милләтнең ерак данлы һәм шанлы тарихын, үсешен белергә чакыра.

Тәнкыйтьче Г. Тукай шигъри дөньясының халыкчанлыгын аңлауга да шушы ноктадан якын килә: «Тукаев кайгы-хәсрәт баласы, моңнар шагыйре, авыр тойгылар, авыр мәшәкатьләр җырчысы иде... Милләтебезнең бөтен халык җырларындагы төп аһәң, кайгы, хәсрәт, авыр моң аһәңе аның шигырьләрендә дә төп көй, әсас *(нигез. – Т.Г.)* иде. Менә шуңар күрә аны халык бик яшьләй үз шагыйре итеп таныды; аны аңлады, ул җырлаган нәрсәләрнең үз рухындагы нәрсәләр икәнен тойды» [Әмирхан, 1986, б. 115].

Аерым бер мәсьәләләрдә Г. Ибраһимов, шулай ук Г. Исхакый карашлары белән дә уртаклык-якынлык сизелгән «Күпме какканны вә сукканны күтәрде бу ятим» (1923) мәкаләсендә Ф. Әмирхан шагыйрь иҗатына бәя биргәндә, культура-тарих мәктәбе кагыйдәләренә таяна. Иске мәдрәсә биргәннән артмаган гыйлем, иске төрек-татар әдәбияты җыйганнан бер генә карыш та уза алмаган «әдәбият танышлыгы»; «төньякның ярлы, мескен табигате белән чикләнеп калган табигать тәэсираты», Казан белән Җаек арасында чикләнгән тормыш; фикере, гыйлеме, зәвыгы яхшы тәэсир итәрлек даирәгә кермәү, Ф. Әмирхан карашынча, Тукайның тумыштан килгән талантына киңәергә, үсәргә мөмкинлек бирми, ул тумыштан бирелгән сәләт, «талант бөресен ачмыйча, ача алмыйча һәлак булды» [Әмирхан, 1986, б. 176].

Ф. Әмирханның бу төр иҗатында Г. Тукай шигърияетен

пропагандалау, рухи мирасын һәм шәхесен субъектив бәядән, нахак сүзләрдән саклау, әдәби абруе проблемасы кызыл җеп булып сузыла [Гилазов, с 181]. Шундый хезмәтләрнең берсе – «Татар шагыйрьләре» 1908 елда язылып, «Дамелла» имзасы белән «Әл-ислах» газетасында басылып чыга. «Волжско-Камская речь» газетасында цензор, педагог, мәктәпләр инспекторы һәм Татар укытучылар мәктәбе укытучысы Альберт Петрович Пинкевич (Пенькевич) (1884–1939) «Очерки новейшей татарской литературы» дигән мәкаләсен бастыра. «Камско-Волжская речь» – 1908–1918 елларда Казанда рус телендә нәшер ителгән көндәлек иҗтимагый-сәяси, әдәби һәм икътисади газета. А.П. Пинкевич XX гасыр башы татар әдәбиятына күзәтү ясап, Г. Тукай һәм М. Гафури иҗатлары нигезендә татар шигъриятендә күзәтелгән тенденцияләрне барлый. А. Пинкевич үзенең мәкаләсендә «У Тукаева много истинной поэзии, но морализм, проповедь сводит на нет его произведений. Он касается всех сторон татарского быта и диктует правила жизни. <…> Это *(М. Гафури. – Т.Г.)* яркий националист, в глубоком значении этого слова и поэтому большой популярности не имеет» [Пинкевич, 1908] дип, Г. Тукай шигырьләрен сәнгатьчә эшләнеше ягыннан югары бәяли, анда язучылык таланты барлыгын таный; ә М. Гафури әдәби әсәрләренең тар милли характерына үзенең тискәре мөнәсәбәтен белдерә. Шагыйрь иҗатының тәрҗемә эшчәнлеге мәкалә авторы тарафыннан югары бәяләнә: «У Тукаева много подражаний Байрону, Лермонтову, Пушкину. <…> Точных переводов нет. Даже такие стихотворения, как «Что ты спишь, мужичок» он переделывает на свой лад, применяя его к татарскому быту» [Пинкевич, 1908].

Бу мәкаләгә җавап төсендә «Волжский листок» газетасында Касыйм Уралец тәхәллүсе белән «Татарские поэты» язмасы дөнья күрә. «Волжский листок» – 1904–1909 елларда Казанда рус телендә нәшер ителгән газета. Язма авторы А. Пинкевичның фикерләрен кире кагып, киресенчә, Тукайны шигырьләр саны азлыкта, тәрҗемәләре уңышсыз булуда, тел-стиле ямьсезлектә, урам теле белән язуда гаепли: «Мы со своей стороны заметим, что эти “томики” не более, как две тощие книжонки, заключающие в себе 10–15 оригинальных стихотворений, а в остальном заполненных неудачными переводами из Лермонтова и Пушкина» [Уралец, 1908]. К. Уралец Гафуриның Россиядә һәм Себердә танылганлыгы һәм популярлыгы турында яза. Аның карашынча, М. Гафури, шөбһәсез, яңа татар әдәбиятының бизәге. Аны Америка шагыйре Уитмен Уолт (1819–1892) белән янәшә куя.

Татар әдәбиятының үсеш тенденцияләре хакында А. Пинкевич карашлары белән килешкән хәлдә, К. Уралец тарафыннан шагыйрьләр иҗатына бирелгән бәя бәхәс уята. Тел чуарлыгы, гарәп, фарсы сүзләренең еш кулланылуы шул чор шигъриятте өчен гомуми күренеш. Тукайда гына түгел, М. Гафурида

да башка телләрдән алынган гыйбарәләр белән язылган шигырьләр бар. Тукай, тәрҗемә эшен үзенчәлекле әдәби иҗат алымы дәрәҗәсенә күтәреп, рус һәм аның аша Аурупа шагыйрьләренең әсәрләрен уңышлы тәрҗемә итә һәм шул юл белән татар халкын Европа әдәбиятына һәм мәдәниятенә якынайта.

Дөрес, полемикада катнашучылар бәхәс кызулыгы аркасында урыны-урыны белән арттырып җибәрәләр, төгәлсезлекләр ычкындыралар [Нуруллин, б. 33], Ф. Әмирханга да урыны белән объективлык җитми. Г. Тукай шигъриятен хата, ялгыш бәяләүчеләрне кире кагу белән мавыгып китеп, ул аерым бер мәсьәләләрдә М. Гафури шигъриятенә тенденциоз якын килә. Шагыйрь поэзиясенең иҗтимагый-милли әһәмиятен, аның байлыгын күреп бәяләп җиткерми.

Күзәтүләргә нәтиҗә ясап, түбәндәгеләрне әйтергә мөмкин. Татар әдәби тәнкыйте үткән юлны өйрәнүче галимнәр хезмәтендә Ф. Әмирхан бертавыштан бу иҗат төренә нигез салучы буларак таныла. Тәнкыйтьче үзенең күпсанлы мәкаләләре, рецензияләре белән татар әдәбиятының яңару процессын тизләтә. Ул тәнкыйди эшчәнлегендә рус әдәбият белемендә калыплашкан һәм XX гасыр башында милли әдәби-гыйльми фикер тарафыннан үзләштерелгән культура-тарих мәктәбенең кагыйдәләре, әдәби кануннарына таянып татар реалистик тәнкыйтенә нигез сала. Татар әдәби тәнкыйтенең нигез принциплары, әдәби әсәрне бәяләү кагыйдәләре, фән буларак асыл хасиятләре Ф. Әмирханның тәнкыйди гыйльми эшчәнлегендә фәнни югарылыкта эшләнә һәм хәл ителә.

**Әдәбият**

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр: дүрт томда. 3 т. Публицистика. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 512 б.

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр: дүрт томда. 4 т. Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. 390 б.

*Вәлиди Җ.* Әдип Фатих Әмирхан // Гыйлаҗев Т.Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. Б. 182–186.

*Гилазов Т.Ш.* Проблема литературной репутации Г. Тукая в научно-критической мысли первой четверти XX века // Филология и культура. Philology and Culture. 2013. № 3 (33). С. 181–185.

*Gilazov T.Sh, Karabulatova I.S., SayfulinaF.S., Kurakova Ch.M. and Gulphiya Maratovna Talipova.* Between the East and the West: Phenomenon of Tartar Literary Criticism in the Lingvo-Cultural Aspect // Mediterranean Journal of Social Science. 2015. Vol 6, No 3, S 2, May 2015. P. 508–517. Doi:10.5901/mjss.2015.v6n3s2p508

http://www.mcser.org/journal/index.php/mjss/article/view/6534/6261

*Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман (Татар әдәбият нәзариясенең барлыкка килүе һәм үсеш баскычлары). Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 271 б.

*Закирзянов А.М.* Основные направления развития современного татарского литературоведения (кон. XX – XXI в.). Казань: Ихлас, 2011. 320 с.

*Нуруллин И.З.* XX йөз башы татар әдәбияты. Урта мәктәп укытучылары, студентлар һәм югары класс укучылары өчен дәреслек-кулланма. Казан: татар. кит.нәшр., 1982. 288 б.

*Пинкевич А.* Очерки новейшей татарской литературы // Волжско-Камская речь. 1908. 21 мая.

*Сәгъди Г.* Бездә әдәби тәнкыйть / Үктәбрнең унъеллыгына. Казан: «Безнең юл». 1927. 22 б.

*Уралец К.* О татарских поэтах // Волжский листок. 1908. № 34.10 июня.

***Гыйлаҗев Таһир Шәмсегали улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Казан (Идел буе) федераль университетының*
*татар әдәбияты кафедрасы доценты*
*tgilazov@bk.ru*

УДК 831.512.145

***Р.Ф. Харрасова***

## Ф. ӘМИРХАН ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ АТАМА ПОЭТИКАСЫ: «Татар кызы» һ.б.

Статья посвящена изучению поэтической составляющей заголовков произведений Фатиха Амирхана.

**Ключевые слова:** Фатих Амирхан, татарская литературы начала XX века, поэтика заголовков.

Әсәргә куелган исемнең, бер яктан, синтаксик позициясе бар, икенче яктан, күпчелек очракта ул тексттан аерымланып алынган һәм шуның белән калкуландырылган сөйләм берәмлеге булып тора, өченчедән, ул һәрвакыт нинди дә булса функция башкара. Шул ук вакытта исем нәфис текст структурасында аерым өлеш кенә тәшкил итеп калмый, әсәр төзелешенә органик кушылып та китә, анда тел чараларының һәр төре сәнгати файдаланыла ала.

Нәфис текстларны мотивлар җыелмасы калыплаштыра, аларның сыйфатламалары тулы бер иҗатның мотив поэтикасы турында сөйли. Димәк, аның атама поэтикасы белән дә турыдан-туры бәйләнеше бар. Теге яки бу прозаикның иҗат лабораториясен чагылдырганда, әсәрләренең сюжет логикасын, хәрәкәтен өйрәнгәндә, мотивлаштыру проблемасын тикшерү әнә шуңа күрә дә алгы планга чыгарга тиеш. Әдип иҗатын зур күләмле хезмәтләрдә бу яссылыкта тулысынча өйрәнеп чыгу – әле алда торган зур эшләрдәндер.

Заманына күрә бик оригиналь язучы булуына карамастан, Ф. Әмирхан атамалауның барлык алымнарын да кулланып бетергән дип булмый. Бу мөмкин дә түгел. Икенче яктан, әдипнең әсәрне исемләгәндә аерым төргә өстенлек биргәнлеге ачык күренә. Ф. Әмирхан прозасында әсәрләрне тасвир объекты һәм үзәк герой исемнәре белән атамалау очраклары күбрәк. Болай эшләгәндә, автор, атаманың отышлы куелганлыгын да аклап, әсәрдә мөһим урын тоткан геройны шактый үзенчәлекле тудырырга, тирәлектә нык аерылып торган кеше яисә заман тибын чагылдыручы бер зат итеп күрсәтергә, бигрәк тә аларны психологик планда ачарга тиеш була, шунлыктан ул аның теге яки бу гамәлләрен калку тасвирлый, үзенчәлекле холык сыйфатларына бик нык игътибар итә. Ф. Әмирханның «Нәҗип», «Габденнасыйр», «Мостафа», һәм башка әсәрләре шул турыда сөйли. Күрәсез ки, китерелгән атамаларны бер сүзле җөмләләр тәшкил итә.

Әдип еш кына атамада геройны теге яки бу сыйфатлары

белән ачыклый, бәяли: «Мәсләксез кеше», «Мәхәббәтсез үрдәк баласы», «Сәер шәкертләр», «Куркыныч дошманнар». Ул тасвир объектының социаль төркемен, чыгышын искәртергә мөмкин: «Салихҗан кари», «Сәмигулла абзый», «Кечкенә хезмәтче», «Хәкимә әби». Кайвакытта бу төр атамалар хикәянең сатира-юмор әсәре икәнлегенә ишарәли: «Хуҗа Насретдин кызының угылы».

Ф. Әмирхан хикәяләренә куелган атамаларның күпчелеген номинатив җөмләләр тәшкил итә, һәм шул ук вакытта аның баш кисәге күбрәк исемнәр белән бирелә. Семантик яктан караганда, атама эчендә кулланылган исемнәр, кешедән, әдәбият яисә фольклор героеннан тыш, топонимик төшенчәләрне, теге яки бу урынчалыкларны чагылдырырга мөмкин: «Идел ярында», ««Шәрекъ клубы»нда», «Шакир Петроградта». Ф. Әмирхан прозасында атама еш кына вакыйга-күренешләр барган вакытка һәм урынга ишарәли: «Бәйрәмнәр», «Көндезге сәхәр яки рузасызлар», «Бер хәрабәдә…», «Балалар атавы», «Яз исереклегендә», «Зөләйха театрда», «Дачада». Әдипнең «Хәзрәт үгетләргә килде», «Милләт тәрәккый иттерү», «Беренче танышу» һәм башка әсәрләренә куелган исемнәр исә билгеле бер дәрәҗәдә сюжет переспективасына ишарәли.

Белүебезчә, татар әдәбиятында атамаларга жанр билгеләмәсен чыгару традициясе озак вакытлар дәвам итә. «Йосыф кыйссасы», «Таһир-Зөһрә дастаны», «Чура батыр хикәяте» һ.б. әсәрләр фикеребезгә дәлил була ала. Яңа заман әдәбиятында бу традиция какшый, әмма ул төр атамалар да әледән-әле күренгәли. Ф. Әмирхан иҗатында да аңа мисаллар бар: «Тәгъзия (Мәрхүм анам Рәбига Зиннәтулла кызының хатирәсенә багышлыйм). Кайчак ул әсәрнең жанрын, тормышны чагылдыру методын атамадан соң ачыклап уза: «Гарәфә кич төшемдә» (Хыялый хикәя), «Хакарәт саналган мәхәббәт» (Романтик дустым тормышыннан). Бу төр ачыклаулар, белгәнебезчә, татар прозасы өчен чагыштырмача яңа була.

Ф. Әмирхан уйлап тапкан атамалар, гади генә тоелсалар да, семантик яссылыктан караганда, күпсыйдырышлы. Авторның сүзләр белән отышлы уйнавы аркасында, үзенчәлекле яңгырашлы көтелмәгән гыйбарәләр барлыкка килә. Мәсәлән, әсәрне укып чыкканчы, «Танымаганлыктан таныштык»та беренче сүз артыктыр кебек тоела. Аерым бер атамалар табышмакны төсмерләтә: «Ай өстендә Зөһрә кыз», пародокс рәвешендә дә яңгырарга мөмкин: «Зәгыйфь карчыкның корбаны». Текстның гап-гади тамгасы кебек тоелган исемнәр, чишелешкә җиткәндә, инде бөтенләй башкача ачыла, чөнки аңа төп текстка салынган тирән мәгънә дә күчерелә.

Ф. Әмирхан әсәрләренең атамалары еш кына үтә моңсу яңгырый: «Ул үксез бала шул!», «Картайдым!», «Бер хәрабәдә», ә кайвакыт укучыны ниндидер куркыныч алдында калдыргандай: «Коточыргыч бер

төш», укучыны фаҗига белән таныштырырга хәзерләгәндәй: «Хәкарәт саналган мәхәббәт».

Атама – әсәргә реклама, башкалардан аерымлау-аерымлану тамгасы, әгәр дә инде хикәяме, повестьмы, башкасымы автор мирасында аерым урын тота икән, аның визит карточкасы да булып тора. Төп текст белән идея-тематик бәйләнгән атама еш кына – аны ачучы, яңгырашын һәм фәлсәфилек дәрәҗәсен билгеләүче ачкыч та ул. Теге яки бу әдип иҗатында атамалар төрлелеге каләм иясенең талантлылыгын күрсәтсә, аларның охшаш юл-алымнар белән сайлануы иҗатка һәм андагы атамаларга хас уртак поэтика турында сөйли. Ф. Әмирхан хикәяләре арасында визит карточкалары булырлыклары шактый: «Чәчәкләр китерегез миңа!», «Кадерле минутлар», «Корбан» һ.б.

Бүгенге көндә генә түгел, әдәби барышның һәр этабында атама әсәрнең товар бәясен күтәргән дә, төшергән дә, әдипләр аның коммерция тамгасы икәнлеген һәрвакыт аңлаган. Әйтик, Г. Исхакый, үз әсәрләрен «Кәләпүшче кыз», «Теләнче кыз», «Бай углы» дип исемләгәндә, төп адресатын һәм укучысын шактый ачык күзаллаган. Башка тормыш белән яшәгән, яшьлеген кичәләрдә, клубларда, кызлар белән аралашып, шәһәр тәрбиясе алган зыялылар яисә заманча карашлы, тирән укымышлы яшьләр тирәлегендә уздырган Ф. Әмирхан әсәрләрендә шул тормыш шактый киң чагылыш таба: «Танс кичәсе», «Канвалардан берсе», «Дачада», «Зөләйха театрда»...

Теге яки бу әсәргә атама төрле юллар белән сайлана. Кайвакыт аның ничек барлыкка килгәнлеген исемнең үзеннән дә чамалау мөмкин. Әйтик, текст атау җөмләләр белән идентификацияләнсә, ул күп очракта әдип башында тема, төп тасвирлау объектын ачыклау белән бер вакытта уйлап табылган була һәм әлеге дә баягы объектны чагылдыра. Кайчак вакытлыча гына дип куелып торган андый исемнәр, алмаштырырлык яңасы табылмаганлыктан, әсәрнең мәңгелек атамасы булып китә, еш кына үзгәрә дә. Нәфис текст тамгалауның иң гади, иң җиңел юлы – герой исемен яисә төп теманы күрсәтүдер, әмма төп идея, тема рәвешендәге атамалар еш кына башкаларныкын кабатлый, үзенчәлекле яңгырамый. Ул чагында, исем отышлы тоелсын өчен, төп текст ярдәмендә, мәгънә трансформацияләре кичерүе кирәк.

Укучылар өчен эчтәлеге алдан ук аңлаешлы символлар белән исемләнгән текстларны күбрәк әлеге тропның текстның буеннан-буена кабатланып килүе, мәгънә киңлекләре үзгәрүе, киңәюе-тараюы, хәтта көтелмәгәнчә ачылуы кызыклы итә, үтәли мотив исә әсәрнең бербөтен итеп кабул ителешенә дә булыша. Була шундый очраклар да: гап-гади, беренчел мәгънәсендә аңлашылган исем текстны уку барышында метафоралаша, символга ук әйләнергә дә мөмкин («Корбан», «Сүнгәч»).

Кайвакыт, атамадан этәрелеп китеп, әдип теге яки бу күренешләрне аңлау-аңлату, аларга мөнәсәбәтле шәхси фикер җит-

керү концепциясен дә эшли. Төп текстта һәм атамада, автор әйтергә теләгән мөһим фикердән тыш, теге яки бу җәмгыятьтә, социаль катламда, дини-милли тирәлектә, илдә, дөньяда булган карашлар да чагылырга мөмкин. Ф. Әмирхан прозасында үзенчәлекле урын тоткан «Татар кызы» хикәясендә геройга карата автор күрергә теләгән мөнәсәбәт белән җәмгыятьтә нык урнашкан карашлар капма-каршы килә. Без горурланып танышырга тиеш кебек Татар кызы язмышы кызгану, үкенү тойгылары уята, ә бәлки, кемдәдер хәтта көчле рәнҗеш хисе дә туадыр. Шул ук вакытта ул миллионнарча рухи басылган, шәхси ирекеге буылган, кеше икәнлеге исәпкә алынмаган, теге яки бу күләмдә хокуксызландырылган татар кызларын гына түгел, башка социаль катлам вәкилләрен дә, үзләрен яклап, баш калкытырга әйдидер. Автор, әлбәттә, әсәрне үз чорында чагыштырмача ныграк кысылган хатын-кыз җәмгыятен уяту, ә башкаларның аңа карата мөнәсәбәтен үзгәртү максатыннан язган.

Мәкаләбезнең кереш абзацларындагы исем уйлауга мөнәсәбәтле кайбер җөмләләрне Ф. Әмирханның «Татар кызы» хикәясенә карата да кулланып була торгандыр. Бердән, аның исеме атау җөмлә белән белдерелә; икенчедән, әсәрнең буеннан-буена кабатланып килгән гыйбарә булып тора; өченчедән, укучы, текст белән танышканда, аңа салынган мәгънә тирәнлекләренә торган саен ныграк төшә һ.б.

Әдәби әсәрләр атамасының поэтикасын сюжет өлешенә карап мотивлардан аерып өйрәнеп булмауны, ягъни аның мотивлар комплексын тәшкил итүче вак һәм эре күренешләрдән оешкан сюжеттан чыгып куелуын әйтеп узыйк. Атама эчтәлекне гомумиләштереп күрсәтергә яисә текстның идея эчтәлеген ачарга, укучыга лейтмотивны җиткерергә, аны мәгънәви киңәйтергә, ә бәлки, хәтта тарайтырга да, игътибарны аерым бер моментка юнәлтергә дә мөмкин. Текстны «Татар кызы» гыйбарәсе дип исемләү алдан ук героиняның кемлегенә, ни дәрәҗәдә гомумиләштерелгәнлегенә ишарәли, ул аның милләттәшләре, иле, дөнья халыклары эчендә аермалы урын тотканлыгына, үзгә бер характерга һәм мөнәсәбәткә ия икәнлегенә дә күрсәтә.

Ф. Әмирханның «Татар кызы» хикәясе белән тулысынча танышып чыкканнан соң, сюжет эчтәлегенең һәм аны җиткерү концепциясенең автор башында алдан ачыклангалыгы, боларны уйлау янәшә барганлык күренеп тора. Искә төшерик: әсәрнең төп герое соң дәрәҗәдә гомумиләштерелгән, хикәя аерым бер кеше язмышын чагылдырмый, ягъни аерым бер социаль катламга, шуның вәкиленә – Татар кызына мөнәсәбәт, андагы үзгәрешләр тарихы рәвешен ала. Аның «Туды... / Туганда ул кеше иде» дигән җөмләләр белән башлануы үзен аклый, шул юллар ук атамага салынган төп мәгънәне үзгәртә башлый. Беренче бүлек яңа гына дөньяга килгән җан иясенең хокук-мөмкинлекләрен ачыклау рәвешендә башлана: бала булдыра алган-

ча хәрәкәтләнә, көлә, теләгәнен аваз-тавыш белән белгертә, ир балалар янәшәсендә ята, анасы тарафыннан иркәләнә. Кыскасы, бар табигать аны адәм дәрәҗәсендә күрә, башкаларга тиң итә.

Хикәянең икенче бүлегендә беренче җөмлә алдагысыныкы кебек сайланса да, калган абзацлар инде икенчерәк башлана: аларда кызның туганда тереклегенә, әлеге тереклекнең алты яшькәчә кадәр генә баруына басым ясала, шуннан соң елын-елга, үз чиратында, аның әле бер, әле икенче хокукы киселә. Кара көч исеме белән гомумиләштерелгән җәмгыятьтәге нормалар, шул кагыйдәләрне үтәү сагында торучылар, шул торучыларны тәрбияләгән китаплар, сүзләр аны, ниһаять, ир балалардан бөтенләй аера. Өченче бүлек инде бу аермаларның кешене белем, һөнәр планында аскы баскычта калдырганнарын санауга багышлана. Ир балалардан аермалы буларак, Татар кызы, мәктәпкә йөрми, сабакны абыстайдан ала. Дүртенче бүлектә исә ул үзен киемнәр белән томалый һәм гаүрәт икәнлеген, хәтта кешегә күренүнең оятлыгын аңына сеңдерә башлый. Бишенче бүлектә өлгереп җиткән татар кызы дүрт дивар эченә ябыла да үзе белән уйнаячак «хайванны» көтүгә, каршы алуга хәзерләнә башлый, әмма әлегә аның яшәү теләге, ярату теләге бөтенләй үк сүнмәгән. Алтынчы кисәктә кызның бәхетле булыр өчен алда кылып караган гамәлләрен автор «үлем алды селкенешләре» дип атаячак. Инде «хайван» дәрәҗәсендәге ирне тыңлау да Тәңре ризалыгы өчен башкарылачак. Сатылган, сатып алынган кыз бөтенләй товарга әйләнәчәк. Ниһаять, җиденче бүлектә ул Кара көч алдында тез чүгә – үзенең иргә уенчык сыйфатында һәм бала табар өчен генә яратылганлыгын таный. Каһкаһә, нәфрәт хисләре ташыган, боерык-таләп рәвешендәге җөмләләр текстның тәэсирен торган саен көчәйтә, аны авыр тойгылар калдырган әсәргә әверелдерә.

Атаманың яңгырашы башламныкы, тулы текстныкы белән туры килергә, аерылып торырга мөмкин. Ф. Әмирхан әсәренә куелган, тойгы тыныш билгеләре белән тамгаланмаган «Татар кызы» исемен без аңа карата нейтраль мөнәсәбәт белдереп, гади сөйләм интонациясе белән укыйбыз. Әгәр язучы, Татар кызлары белән горурланса, укучыны тасвирланачак объектның Татар кызы исемен йөртергә хаклымы-юкмы икәнлеге хакында уйланырга чакырса, аны өндәү, сорау куеп язар, без дә әлеге җөмләдә тасвирланачак күренешләргә карата автор мөнәсәбәтен алдан ук күпмедер чамалый алыр идек. Ә болай барыбыз да көтелмәгәнчә ачылып китәр кебек билгесезлек алдында тора. Шул ук вакытта шартлаулы авазлар доминанта позиция алганлыктан, никадәр нейтраль яңгырамасын, «Татар кызы» атамасыннан чыгып, кемдер алдан ук сюжеттан шомлылык, фаҗигалелек, хәтта катастрофа да көтәргә мөмкин.

Әсәр ахырына дөньяга бәхет китереп, бәхетле булып туган баланың физиологик үсеш этаплары аша узганда хокуксызлана

баруы, бәхетсез бер җанга әверелүе аркасында, Татар кызы дигән мөһер трагик тамга рәвешен ала, әлеге төшенчә коллык психологиясе, хокуксызлык билгеләмәсенә әйләнә. Әдип, татар яшәешендә хатын-кыз тормышы аерым бер урын алып тора, аның өчен җәмгыятьтә аерым кануннар язылган, хикәядә сүз сирәк күзәтелгән очраклар турында гына бармый, ди. Икенче төрле әйткәндә, «Татар кызы» әсәрнең социаль концептын чагылдыра.

Әдип хикәядә, тәгаен яшәешебезнең көндәлектәге вак күренешләрен читләп үтә. Абстракцияләнү, гомумиләштерү юлы белән, һәр татар кызының бер үк язмыш борылмаларыннан, психологик киртәләреннән узып чыгып, тормышының алдагы этабына атларга, аңа ярашырга, шул күчешкә рухи хәзерләнергә тиешлеген, бу исә җаныңны әкренләп теленүен-теткәләнүен, ахыр чиктә юкка чыгуын һәм инде үзенең җансыз курчакка тиңләшүен күрсәтә. Татар кызының әлеге әверелешләре вакытында гомумкешелек кыйммәтләре җимерелә, гаделлек, кешелеклелек кебек төшенчәләрнең тамырына балта чабыла. Ф. Әмирхан шул ук вакытта, бөтен җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать итеп, татар милләтенең рухи яңарышына, үзгәрешләренә өмет күзләре белән карарга да чакыра кебек.

Әсәрдә автор үз позициясен «Коръән»нән алынган өзек ярдәмендә бик ачык белдерә. Аңа ни өчендер Ф. Әмирханның күптомлыгында аңлатма бирелмәгән. Әлеге өзек татар кызына XX гасыр башында булган мөнәсәбәтнең тамырларын ачып бирә, исламгача яшәгән гарәпләрдәге традицияләр белән бәйле. Татар кызына хас проблемалардан, шулай итеп, автор ислам дөньясындагы мәсьәләләргә һәм гомумән дөнья хатын-кызлары турында уйлануларга килеп чыга.

Бик борынгыда Гарәпстан ярымутравында гаиләдә кыз бала туу мәсхәрә саналган, кайбер ата-ана аны чит гаиләгә кыерсытылырга бирергә кызганган, үзе тарафыннан үтерелүен дә җиңелрәк санаган. Баланы шунда ук тере килеш җиргә күмеп калдырырга тырышканнар. Ислам дине исә кыз кешенең мондый хәлен кискен рәвештә тәнкыйтьләгән. Димәк, Ф. Әмирхан җәмгыятьтәге хатын-кызга карата әхлаксыз мөнәсәбәтләрне, аны җансыз курчакка тиңләүне ислам дине белән бәйләмәскә чакыра. Аллаһе Тәгалә шулай дигән: «Әгәр ул мөшрикләрнең берсенә «кыз балаң туган»лыктан сөенеч бирелсә, хатынына ачуланып, дусларыннан оялып, йөзе каралып китәдер. Кыз белән сөенеч бирелгәнлектән хурланып, кауменнән качадыр, бу кызны хурланып кына асрыйммы яки тереләтә туфракка күмеп таптыйммы икән, дип уйлап торадыр. Әгәһ булсыннар, кылган эшләре – нинди яман кабахәт эштер!» («Нәхел»нең 58–59 нчы аятьләре).

Аллаһе Тәгалә яңа туган кыз баланы терелэй җиргә күмүнең нинди зур бозыклык, җинаять икәнен шушы рәвешчә күрсәткән: «…Вә тере хәлдә күмелгән кыз балалардан – ни сәбәпле үтерелдең; (башкалардан) нинди

гөнаһы бар иде, нигә үтердегез, дип соралса» («Тәквир», 8–9 нчы аятьләр), шул вакытта кыямәт көне якынлашыр. «Татар кызы» хикәясенең шул хактагы юллар белән тәмамлануы ахырзаман хакында искәртүдән битәр, аны җанлы курчакка әйләндерүнең кыямәт газабына тәңгәллеген, ә шул әверелешнең тереләй күмелүгә тиңлеген сөйли.

Кыскасы, «Татар кызы» атамасында автор тарафыннан инде тема белдерелгән, әмма аны ахыргача аңлау, ачу юлы нәфис текст ахырынача бара. Әсәрне укып бетергәннән соң, атамага салынган мәгънә үзенең күпсыйдырышлыгы, тирәнлеге белән таң калдыра. Герой исемнәренә, әсәр атамаларына игътибар аеруча зур булган XX гасыр башы татар прозасын, шул исәптән Ф. Әмирханныкын, бигрәк тә хикәяләрен мотив-мотивлаштыру һәм атама поэтикасы ноктасыннан өйрәнү өчен бик кызыклы икәнлеген дә тагын бер кат ассызыклыйк.

***Харрасова Рифә Фәтхрахман кызы,***
*филология фәннәре кандидаты*

УДК 821.512.145:159.922.7

***С.Г. Сәмитова***

# БАЛАЛАР ПСИХОЛОГИЯСЕН ЧАГЫЛДЫРУДА Ф. ӘМИРХАННЫҢ ИҖАДИ ОСТАЛЫГЫ

В рассказах Ф.Амирхана о детях расскрываются этико-психологические проблемы, возникающие от столкновения ребенка с взрослым миром. Рассказы о сиротах, обездоленных и лишенных самого необходимого будят разум и совесть читателя.

**Ключевые слова:** Фатих Амирхан, рассказы о детях, нравственность, сочувствие ребенку, этико-психологические проблемы, эмоциональное состояние.

Татар әдәбияты классигы Фатих Әмирхан иҗатында балалар өчен яки балалар турында язылган әсәрләр дә бар. Язучы, балалар турында уйланып, тормыштагы, җәмгыятьтәге үзе килешә алмаган мәсьәләләрне күтәрә. Бу – беренче чиратта – бәхет, бәхетле, ирекле кешеләр, тормышның, табигатьнең, кешеләрнең матурлыгы мәсьәләсе.

Фатих Әмирханның тормышта иң әрнеп кабул иткән күренешләренең берсе – ятимнәр тормышы. Бу проблема язучының «Ул үксез бала шул!», «Ай өстендә Зөһрә кыз» хикәяләрендә ачыла. «Ул үксез бала шул!» хикәясендә язучы ятим баланың бәхетсезлеген аның башка балаларның мөнәсәбәте аша ачып бирә. Хикәянең эчтәлеге болай: Гает көнне бөтен бала яңа киемнәрдән, араларында ятим малай Нури гына иске киемнәреннән чыккан. Нури узышып йөгергәндә беренче килә. Шул мизгелдән әле генә уйнап йөргән шат балалар тискәре энергия үзәгенә әверелә. Алар ятим баланың җиңүен күтәрә алмыйлар. Нуриның иске киеме аны кимсетергә, рәнҗетергә сәбәп итеп алына. Яклаучысыз булуы да башка балаларга үзләрендәге бөтен явызлыкны чыгарырга мөмкинлек бирә. Амбицияләр, үз-үзен ярату, хөсетлек – бу сыйфатлар балалар өчен дә хас. Шул ук вакытта, балалар шактый беркатлы булып, үзләрендәге бу сыйфатларны яшереп тә калмыйлар. Балалар теләкләренә ирешә – Нури үзенең фәкыйрьлеген, бәхетсезлеген, көчсезлеген тагын бер кат таный. Бу эпизод түбәндәгечә бирелә:

«Ул, минем шушы сүземне генә көтеп торган шикелле, кинәт кенә коймага таба әйләнде, йөзен койманың бер тактасына сөяде дә кычкырып елап җибәрде:

– Мин үксез бала шул! Әтиәнием булса, минем дә читек-кәвешем булыр иде».

Балалар шул вакытта гына үзләренең гамәлләренең никадәр түбән булуын аңлый. Лирик герой бу күренешнең озак вакытлар күз алдыннан китмәвен дә яза. Бала, тискәре энергиягә каршы тора алмый. Әмма әхлакый яктан җиңү – ятим бала ягында. Ул балалардагы явызлыкны җиңеп чыга, аларда кешелеклелек

сыйфатларын уята. Әмма ятим бала үзен җиңүче санамый. Ул җылы сүзгә, башкалардан шәфкатьлелеккә мохтаҗ.

Америка психологы Карен Хорни күрсәткәнчә, бу очракта шәхес тирән шөбһә хисе кичерә, ә ул хисләрдән вакытында арына алмау, киләчәктә дәвалап булмый торган халәткә китерә. «Бу шөбһәдән арыну очен бала невротик ихтыяҗларны канәгатьләндерә торган: мәхәббәт һәм хуплау, нәрсәдә дә булса узенең башкалардан өстенлеген күрсәтү, җәмгыятьтә танылу, үз-үзе белән горурлану кебек саклангыч стратегия (механизм) кулланырга тели. Соңрак бу ихтыяҗлар, шәхси мөнәсәбәт-аралашуларның нигезенә ятып, шәхеснең әйдәп баручы ролен карап, өч төрле бәйләнештә чагылалар:

– киләчәктә кешеләргә баш июче, үз фикере булмаган, бөтен әйләнә-тирәгә ярарга тырышучы шәхес;

– кешеләрдән читтә йөрүче битараф шәхес;

– кешеләргә карата һәрдаим дошманлык күрсәтүче шәхес» [Асмолов, с. 123].

Нурида ялгызлык һәм чарасызлык, беркемгә дә кирәксезлек, әти-әтисез ятим булу, беркем тарафыннан да кайгыртучанлык тоймау, баланың куркынычсызлык һәм иминлек тойгыларын югалтуга китерә. Бары шушы күренештә генә булса да, ягъни ярышта беренче килеп, әйләнәтирәдәгеләрнең игътибарын җәлеп итү, үзенең шәхес булуын дәлилләү максаты шундый каршылык белән бәрелешү, Нуриның эчке проблемасын тагын да тирәнәйтә. Ул берни дә эшли алмый, елап читкә китеп бара. Елау, үз чиратында, сабый өчен тирән нигезле кичерешләреннән бераз арыну чарасы да. Елау аша күпмедер дәрәҗәдә ул эчке конфликт яки киеренке халәттән арына.

З. Фрейд теориясе буенча, «шәхеснең структур компонентлары – Эго-Мин, Супер-Эго һәм Ид. «Мин, бер яктан, кешене хайвани инстинктлар белән тулыландыручы Ид, икенче яктан – кешедә булган үз-үзеңнеярату-эгоизм, үзең өчен генә яшәү кебек түбән ихтыяҗларны тыючы («табу») Супер-Эго тәэсирендә формалаша» [Романин, с. 34]. Әгәр шәхес күбрәк социум ихтыяҗларын өстен куеп, аларны Ид таләпләреннән өстен куя икән, анда кискен эчке конфликт туа. Ә бу конфликт, үз чиратында, усаллык, явызлык кылуга, я булмаса, төрле психик авыруларга, хәтта үзенә кул салуга да этәрергә мөмкин. Нуриның исә, беренче килеп үзенең башкалардан өстенлеген күрсәтү теләге бу конфликттан арыну чарасы буларак аңлатылырга мөмкин. Чөнки шушы мохиттә бу балалар арасында, аның башкача үзен күрсәтер, ягъни Супер-Эго, ягъни эгоистлык ихтыяҗларын канәгатьләндерү мөмкинлекләре юк.

Фатих Әмирхан үзе күзәткән, яхшы белгән күренешне тасвирлый. Әлбәттә, якын-тирәдәге күпсанлы ятимнәр тормышы да әдипнең җанын әрнеткән. Фатих Әмирханның бердәнбер апасы яшьтән үлеп киткәч, аның өч баласын Фатих Әмирханның әнисе тәрбияли. Әлбәттә, житеш гаиләдә балалар ятимлек ачысын

тоймасын өчен бөтенесе эшләнгәндер. Әмма ана мәхәббәтен бер кеше дә бирә алмый.

Дусты Габдулла Тукайның тормышыннан, аның ятим балачагыннан да хәбәрдар булып кына калмыйча, ул шагыйрьнең аянычлы язмышын соң көненә кадәр күрә. Г. Тукайның балачагында ата-ана назына, мәхәббәткә булган ихтыяҗы, аларны ала алмавы, үсеп җиткәч тә, шагыйрьнең кешеләр белән мөнәсәбәтендә чагыла. Ул яратырга тели, әмма үзе мәхәббәттән кача, кешеләргә артык ышана, һәм шул ук вакытта бер кешегә дә ышанмый.

Ятим балалар ул чорда күп һәм аларны бик кечкенә яшьтә асрау итеп бирү күренеше татар тормышында да киң таралган була.

Ф. Әмирханның бу герое укучыда кызгану хисе генә уятып калмый, укучы бу темага кайта-кайта уйлана, җанында авырту, әрнү тоя. Ятим малай Нури образы кешенең акылын, намусын уята, кешенең әхлак сыйфатларына мөрәҗәгать итә. Әмма әсәрдә әхлак, кешелеклелек буенча дәрес булса да, мораль уку юк. Әсәр шул ягы белән дә көчле. Нури образы ятимлек, ялгызлык символы дәрәҗәсенә күтәрелгән. Хезмәтче бала образы язучының тәмамланмый калган «Кечкенә хезмәтче» хикәясендә дә сурәтләнә. Тәмамланмаган өзек буенча нәтиҗәләр чыгару авыр булса да, бу әсәр А.П. Чеховның «Спать хочется» хикәясенә ияреп языла башлаган булырга мөмкин дип фаразларга мөмкин. Ике әсәрдә дә бары йокы теләге эшкә ашмастай хыял дәрәҗәсенә ирешкән хезмәтче балалар турында сүз бара.

Ятимлек проблемасы «Ай өстендәге Зөһрә кыз» хикәясендә дә күтәрелә. Әдип бу әсәрен татар халкының Зөһрә кыз турындагы мәгълүм легендасына һәм үги кыз турындагы әкиятләргә нигезләнеп иҗат итә. Беренче карашка, Ф. Әмирхан легенданы әдәбиләштереп язган кебек тәэсир туа. Әмма, әсәрдә сюжетка мөнәсәбәттә язучының уй-фикерләре, тормыштагы аерым вакыйгаларга мөнәсәбәте дә урын алган. Язучының фикере ай һәм Зөһрә йолдыз турындагы эпизодларда ачыла. Хикәя «Әнә шул тулган айга карагыз әле! Ул шундый түгәрәк, шундый бөтен, шундый тулы һәм якты. Ләкин аның яктысында әллә нинди бер моң, бер уйчанлык, бер кайгы бар» дип башлана. Ай ни өчен моңлы соң? Автор айның һәрвакыт мондый булмавын да әйтеп уза: «Беләсезме, борын-борын заманнарда аның яктысы болай моңлы, болай уйчан булмаган. Кешеләрнең йөрәкләренә, җаннарына авырлык салмаган. Җиңел, уенчак һәм шат булган, моңландырмаган, сагындырмаган, тынычландырган, юаткан». Нәрсә үзгәргән соң? Ай бик карт икән, һәм гасырлар буе җир өстен, кешеләр дөньясын күзәткән, кешеләр тормышының, үги ана явызлыгының шаһите булган, көне-төне үги ана тарафыннан рәнҗетелгән Зөһрә кызны җәбердән коткарган. Әмма шул явызлыкны күргән ай, элекке кебек шат елкылдый алмый икән. Авторның ятимнәр турындагы төп фикере Зөһрә йолдыз турындагы эпизодта ачыла: «Йолдыз, яшен тизлеге белән атылып,

Зөһрә кызны айга илтеп тапшырган да, үзе күкнең иң күренә торган бер җиренә барып урнашкан. Үксез татар кызын айга илткән өчен, Ходай Тәгалә аның нурын арттырган, һәм фәрештәләр аңа «Зөһрә йолдызы» дип исем биргәннәр». Димәк, ятимнәрнең хәлен җиңеләйтү изге гамәлләрнең берсе булып чыга. Әмма фольклор әсәрләренә ияреп язылган бу хикәя «Ул үксез бала шул» хикәясендәге көчкә ия түгел. Ул дидактик характерда. Ачыктан-ачык дидактика, үгет-нәсыйхәт еш кына кешене уята, уйландыра алмый.

Һәр кешедә ярату һәм ратылуга ихтыяҗ бар һәм ул ихтыяҗ кешеләргә З. Фрейд дәлилләгәнчә, табигать тарафыннан туганда ук күчә һәм шәхеснең үз-үзенең тормышын, гомерен саклау инстикты – Эрос белән бәйле. Әлбәттә, тормышны белмәгән балада бу ихтыяҗ тагын да зуррак. Баланы ниндидер сәләтләргә ия булганы, ниндидер эш эшләгәне өчен генә түгел, бу дөньяда булуы, дөньяның иң зур кыйммәте – кеше булган өчен ярату кирәк. Ф. Әмирханның «Нәҗип» хикәясендә сүз шул турыда бара. Әлеге әсәрдә балаларның өлкәннәр тормышын аңлап бетермәве, яки, киресенчә, өлкәннәрнең балалар тормышын аңларга теләмәве аркасында килеп чыккан әхлак, этик-психологик проблемалар күтәрелә. Хикәядә Нәҗип исемле малайның күршедә яшәүче Мәрфуга апага булган яратуы аша бөтен уй-кичерешләре – үзен бөтен кешенең аны яратуларын теләве, абыйсыннан көнләшүе, күрше кызын яратуы, үпкәләүләре, шатлыклары тасвирлана. Хикәя Нәҗип исеменнән сөйләнә. Ф. Әмирхан малайның яшен күрсәтми, чөнки Нәҗип үзен инде зур егет дип кабул итә. Баланың шөгыльләре, уй-фикерләре аша гына аның биш яки иң күбе алты яшьләрдә булуы аңлашыла. Нәҗип әлегә мәдрәсәдә укымый, бары хосусый мөгаллим белән өйдә генә шөгыльләнә. Нәҗипнең абыйсы Гомәр курайда уйный. Шуның өчен аны бөтен кеше ярата: «Әгәр инде ул өйдә булса, карчыклар аны чакырып сөяләр, сөйләштерәләр, кызлар аны үзләренең уеннарында катыштыралар, аны кыстап курай уйнаталар иде». Нәҗип абыйсына булган бу мөнәсәбәткә бик кызыгып карый, үзенә дә өлкәннәрнең игътибарын яуларга омтыла. Малай абыйсына булган мәхәббәтнең, курай уйнаганы өчен генә булганын да аңлый. Ул күрше кызы, апасы янына керә торган Мәрфуга апаны ярата. Шунда ук автор малайның уйлары аша мәхәббәтнең икенче төрлесе булуын да әйтеп уза: «Мин аны күзләре зур булганга, тешләре бик тигез, ап-ак булганга һәм авызын матур итеп көлгәнгә сөя идем». Димәк, нәрсәдер эшләгән өчен түгел, бары булган өчен генә дә яратырга мөмкин. Бу эчкерсез бала мәхәббәте. Элеге вакыйганы тасвирлап, Ф. Әмирхан гаиләдәге иерархия бик үк дөрес төзелмәгән булуын да исбатлый кебек. Әлбәттә, бөтен татар гаиләләренә хас булганча, абый үз урынында, тик сабый гына читтәрәк. Ана да аны теләмәстән рәнҗетә. Шул рәвешле, бала бу гаиләдә үзенең урынын билгели алмый, кирәк-

сезлеген таный, мәхәббәткә лаек түгел, дип уйлый. Бу уйлар аны тирән экзистенциаль конфликтка этәрә.Бу конфликттан арыну өчен ул ниләр генә эшләми: койма башына да менә, Мәрфуга апасының сынын да ясый...

Ф. Әмирхан, баланың үз-үзен тотуындагы көлке мизгелләрне дә, баланың беркатлы, гади, эчкерсез булуын, аның психологиясен аңлап, шуңа күрә дә яратып, теләктәшлек белдереп иҗат итә, дөньяны бала күзләре белән күрә. Бала булып уйлый, шатлана, борчыла. Язучы өчен һәр бала дөньяга карашы, зәвыгы, эчке дөньясы формалашкан шәхес. Әмма бала олылар алдында көчсез, аларның мәхәббәтенә, яклавына һәм аңлавына, җылы мөгамәләсенә мохтаҗ, шул ук вакытта ул олылардан эчкерсезрәк. Күп нәрсәне онытырга, һәрвакыт гафу итәргә әзер.

Нәҗип олыларның мәхәббәтен яулау турында хыяллана. Аның бөтен гамәлләре шуңа юнәлтелгән. Мәсәлән, ул үзен көчле итеп күрсәтергә теләп, абыйсының кураен тартып ала. Бала бу гамәлен начарлык эшләү нияте белән кылмый. Аның максаты – бары үзенә игътибар яулау гына. «Бу эш, минем үземчә, бер егетлек шикелле булып, кунак кызларының, хосусан Мәрфуга апаның исен китерер, һәм аларга мине бер батыр егет итеп күрсәтер шикелле тоела иде». Әмма баланы аңлаучы табылмый. Хәтта әнисенә үзенең проблемасын сөйләгәннән соң да, бала аңлаучы да, яклаучы да таба алмый. Шуның өстенә әни кеше балада үзе турында ялгыш фикер тудырырга җирлек бирүче фикер әйтә: «Абыеңныкы кебек берәр һөнәрең булса, сине дә үзләре чакырып алырлар иде». Малай мәхәббәтне яулау өчен нәрсәдер эшләргә кирәген аңлый. Әмма алты-җиде яшьлек баланың дөньяны аңлавы үзенчәлеклерәк. Ул Мәрфуга апасының игътибарын үзенә җәлеп итәр өчен алга таба нәрсә эшлисен уйлый башлый. Мәрфуга апасын шаккаттырасы килеп, йорт түбәсенә менеп баскач та, баланы аңламыйлар. Аны абыйсы белән чагыштырып, Нәҗипкә аның абыйсыннан кайтыш икәнен исбатлау дәвам итә. Баланың һәр гамәле тәнкыйтьләнә, шул ук вакытта өлкәннәр аның белән сөйләшеп, бала өчен бик авыр тоелган мәсьәләләрне чишү юлларын да күрсәтми. Автор баланың йокларга яткач та уйланып ятуын, үзен гаепли башлавын, гаепне үзеннән эзләвен күрсәтә. Малай өлкәннәр тормышына яраклаша башлый. Аның гаепне үзеннән генә эзләве малайның өлкәннәр битарафлыгы алдында җиңелүен күрсәтә. Өлкәннәр өчен баланың бу борчулары вак мәсьәлә, игътибарга алынырга тиеш түгел.

Нәҗип ахыр чиктә үзенә игътибарны җәлеп итә алырлык шөгыль таба: инде кызлар, бигрәк тә эчкерсез сөйгән Мәрфуга апа, аны еш кына чигү өчен рәсем төшерергә чакыра. Бу эпизод аша да Ф.Әмирханның ни дәрәҗәдә бала психологиясен тирән белүен күрәбез. Нәҗип, беренче чиратта, үзенең бу гаиләдә генә түгел, ә җәмгыятьтә дә үз урынын таба, икенче яктан, сөйгән Мәрфуга апасы янында утыру, аңа үзенә күрә бер ләззәт бирә.

«...Мәрфуга апа минем төшергәннәремне карап тора, кайсыбер сызыклар матур чыгып куйса, ул зур күзләре белән миңа көлемсерәп, иркәләгән шикелле итеп карап ала иде. Чәчәк ясалып бетте; ләкин мин бу күңелле эшемнән тиз генә аерыласым килмәде.

– Мәрфуга апа, бу чәчәк ни өчен кирәк булды сиңа?

– Калфакка чигәргә. Инде ясалып бетте бит ул? Бик рәхмәт сиңа!

– Менә бу җиренә шушы чәчәкнең бөресен дә ясап куйсак, ничек булыр, Мәрфуга апа?» – дигән өзектән кечкенә Нәҗипнең инде бер яктан, эстетик зәвыгы барлыгы күренсә, икенче яктан, аның психологиясе ачыла: ул Мәрфуга апасы янында тагын да озаграк утыра ала һәм, сәләтен күрсәтеп, соклану хисләре уята, үзен инде кирәклеген танып, эчке конфликттан арына. Сәнгать – эстетик тәрбия, ул балада реаль чынбарлыкны әдәби образлар аша сурәтләп, балада дөньяга караш, эстетик зәвык тәрбияли.

Хикәянең өченче өлешендә Нәҗипнең эш-гамәлләре аша үзенә яхшы игътибар алырга өйрәнеп җитүен күрәбез. Өченче өлеш беренче ике өлештән күләменең кечкенә булуы белән аерыла. Бу бүлектә баланың уй-фикерләре, эчке халәтенә дә урын бирелми.

Хикәядә алгы планда Нәҗип образы, аның гамәлләре, уй-фикерләре. Әмма игътибарлы укучы шул ук вакытта икенче картинаны да күрә. Бу балага аңлашылып бетмәгән, еш кына аның борчылуларына сәбәп булган олылар тормышы. Димәк, берьюлы ике картина сурәтләнә. Әдип җәмгыятьнең һәм гаиләнең балага шәхес буларак формалашуда йогынтысын, ролен ача.

Күләме ягыннан зур булмаган бу хикәя үзе дә ике яклы. Беренче карашка, балалар өчен язылган дидактик характердагы әсәр. Икенче яктан, бала хөр фикерле, фикерен якларлык кыю шәхес булып формалашсын өчен аңа игътибар, мәхәббәт кирәклеге турында да. Баланың дөрес адымы, гамәлләре хуплanырга, һәм киресенчә булганда, ни өчен алай эшләргә ярамавы аңлатылырга, дөрес чишелеш күрсәтелергә тиеш. Башка бала белән чагыштыру, аның өчен гомере буена бара торган психологик яра булып кала да ала.

Балалар темасы Ф. Әмирханның башка хикәяләрендә дә күтәрелә. Ул бу әсәрләрендә төрле яктан балалар дөньясын ача. Аларның самимилегенә, эчкерсезлегенә соклана. Язучы иҗатында балалар психологиясе мәсьәләләре күтәрелә. Ф. Әмирхан иҗатын шушы яктан да өйрәнү кызыклы нәтиҗәләргә китерә.

**Әдәбият**

*Асмолов А.Г.* Психология личности: Учебник. М.: Изд-во МГУ, 1990. 367 с.

*Әмирхан Ф.* Әсәрләр: Дүрт томда. 1 том. Хикәяләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 480 б.

*Романин А.Н.* Основы психоанализа. Ростов на Дону.: Феникс, 2003. 315 с.

***Сәмитова Сәвия Гималтдин кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, социаль-гуманитар белем институтының философия һәм гуманитар фәннәр кафедрасы доценты*

УДК 398.8

*Р.Ф. Хәкимов*

## РЕКРУТ ҖЫРЛАРЫНДА СОЛДАТ ЯЗМЫШЫ

В статье изучаются татарские народные рекрутские песни в плане отражения в них судеб военных служивых.

**Ключевые слова:** татарские народные песни, рекрутские песни, служивые люди.

Татар фольклорындагы тарихи җырлар эчендә рекрутларга (никрутларга) багышланганнары шактый зур тематик төркем тәшкил итә. Алар, гадәттә, җыр җыентыкларында да аерым бүлек итеп урнаштырылалар. Әйтик, композитор А.С. Ключарев редакциясендә 1941 елда дөнья күргән «Татар халык көйләре»нең 1 томында «Рекрут, солдат җырлары» дигән исем астында 7 әсәр бирелгән [Ключарев]. Илбарис Надиров әзерләп бастырган «Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар» томында «Патша армиясе, рекрутлар, солдатлар, әсирләр моңы» бүлеге үзенең күләмле булуы белән үк игътибарны җәлеп итә. Ул 29 җырны эченә ала [Татар халык иҗаты..., б. 71–89]. Ләкин мәсьәләгә башкачарак караш та яшәгән булуы билгеле. И. Надиров язганча, элек бу җырлар, гадәттә, лирик җырлар жанрына кертеп йөртелгән. Солдат җырларында, чыннан да, лиризм көчле, беренче карашка аларның шактыен лирик җырлардан аерып карау мөмкин дә түгел кебек. Әмма, шул ук вакытта, солдат җырларының төп өлешендә хәрби-тарихи чынбарлык сулышы сизелә, алар үзәгендә гаскәри хезмәтнең бөтен кыенлыгын үз җилкәсендә татыган герой тора [Надиров, б. 13].

Рекрутлар төркеменә караган җырлар XVIII гасырда иҗат ителә башлаган (1705 елда Россиядә регуляр патша армиясе оешкач, татарларны да хәрби хезмәткә алу камәлгә кертелә) дип карала. Россия составында булган башка халыклар иҗатында да әлеге темага караган җырларны шактый очратырга мөмкин. Барысының да эчтәлегендә патша-түрәләргә нәфрәт белдерү, аларның хакимлегеннән тирән ризасызлык чагыла. Рус телен, офицерларның командаларын аңламаган башка милләт вәкилләренә бигрәк тә авыр булган. Кыйнау, төрлечә җәберләү шартларында, гаиләсеннән, туганнарыннан аерылып, егерме биш ел буе хезмәт итәргә, әлбәттә, берәү дә атлыгып тормаган, аннан ничек булса да котылырга тырышканнар. Хәтта үз-үзләрен имгәтү, гарипләндерүгә кадәр баручылар күп булган. Солдатка каралганда уздырылган медицина комиссиясеннән «яраксыз» дип чыгарсалар, яшьләр өчен шуннан да зур шатлык булмаган.

«XIX йөздә тарихи җырларның классик үрнәкләре барлыкка килсә, гасыр азагында һәм XX йөз башында жанрның иҗади үсеше дәвам итә. Солдатлар һәм рекрутлар тормышын тасвирлаган җырларның безгә мәгълүм булганнары нәкъ әнә шуны раслый» [Урманчеев, б. 153]. Әлеге әсәрләрдә без хезмәткә алыну хәсрәте, аерылышу, армиядәге авырлыклар сурәтләнешен күрәбез. «Рекрут, төрмә, каторга җырлары – мәхәббәт җырларына караганда, бөтенләй башка характерда», – дип басым ясап күрсәтә В.Я.Пропп [Пропп, с. 10]. Рекрут җырларын берничә төркемгә бүләргә мөмкин:

1) рекрутлыкка алынучылар җырлары;

2) хезмәткә алынучыларның якыннары тарафыннан чыгарылган җырлар;

3) армиядәге хезмәт турындагы җырлар.

Бу төркемгә караган җырларның максаты конкрет бер тарихи шәхесне геройны сурәтләү түгел, ә шул чорда халык башыннан үткән вакыйгаларны тасвирлау. Әсәрләрдәге образларның кичерешләре алар хәлендәге башкаларныкы белән уртак, бердәй булганга, җыр сүзләре күпләрнең рухына якын булып әверелә.

Солдат хезмәтенә китә торган егеткә туган йортын гына түгел, бәлки туган җиреннән, якыннарыннан-газизләреннән дә аерылырга туры килгән. Җырларда әйтелгәнчә, күпләр мондый аерылуны үлем белән тиң күргән. Хезмәткә алынучыларның берсе дә өйгә исән-сау кайтырбыз дип ышанмаган, чөнки, төрле сугышлар еш булып тору сәбәпле, күп кенә солдатлар, чынлап та, әйләнеп кайта алмаганнар.

Карлыгачлар кайтыр язлар җиткәч,
Мин кайталмам кебек бер киткәч.
Ачы икән алманы ашавы,
Авыр икән илләрне ташлавы.

«Әнекәем, монда килсәнә»

Җырларда әти-әнисенә үпкә белдергән юлларны очратырга мөмкин, чөнки чиновникларга ришвәт бирү хисабына рекрутларны хезмәттән алып калу очраклары да аз булмаган.

Быел җәйне урак урдым
Ике беләгем сызганып,
И әнкәем, ике беләгем сызганып;
Бәне эткәй солдат итте,
Бер эскертен и кызганып,
И әнкәем, бер эскертен и кызганып.

«Никрут йөкләнде муйныма»

Кайберәүләр солдатка алынудан үлемне хәерлерәк күргәннәр:

Әйдәгезче, дуслар, озатыгыз,
Шул Инсар тауларын менгәнче;
Җан бирүем җиңел булыр иде,
Прием ишегеннән кергәнче.

«Никрутлар җыры»

Инде әйтелгәнчә, үз-үзләрен хезмәткә яраклы итеп күрсәтәсе килмичә, сәламәтлекләренә зыян салучылар да булган, гади халыкны бигрәк тә гаделсезлек тойгысы изгән. Чөнки еш кына, бай балалары урынына саулыгы зәгыйфь фәкыйрьләрне җибәргәннәр.

Икенче төркемдәге җырлар солдат аналары тарафыннан иҗат ителгәннәр, олыгайган көннәрендә ярдәмче-таяныч булыр дип үстергән улыннан аерылу ана өчен зур фаҗига булган.

Кыр да капкаларын чыккан чакта,
Өзеп кенә каптым бер миләш;
Син дә бәбекәемнән аерылгач,
Кемнәр бирер миңа бер киңәш?

Күп кенә ата-ана егерме биш ел буена балаларын көтеп ала алмаганнар, озату мизгелләре аларның соңгы очрашулары булган.

Комиссиядә «хезмәткә яраклы» дип каралганнан соң, яшьләрнең озакка сузылган «никрут» тормышы башланган. Аларның туган җирен, туганнарын ташлап китү газапларына армиядәге түзеп булмаслык шартлар, офицерларның мыскыллаулары да килеп өстәлгән (бигрәк тә мөселман егетләренә).

Әфицәрләр юкка суктырдылар,
Басурман, дип кәләләр үзләре;
Мәңгелеккә «сагынмалык» калды
Аркамдагы шумпыл эзләре.

Әлбәттә никрутлар арасында мондый җәберләүләргә түзә алмыйча, көчле протест белдерүчеләр дә табылган. Андыйларның солдат срогы төрмәләрдә тәмамланган «Егерме ел солдат булып йөрдем» җыры нәкъ шундыйларның берсе.

Түзә алмадым, дуслар, бу хурлыкка,
Янаралның битенә төкердем;
Мине рисвай иткән әфицәрне
Аркасыннан чәнчеп үтердем...

...Ай-һай хурлык күрдем, ачлык
күрдем,
Этләр күрмәгәнне мин күрдем;
Егерме ел солдат булып йөрдем,
Яшь үмрем төрмәдә бетердем.

«Тарихи җырларда чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәт күбрәк трагик, драматик һәм героик планда чагылыш таба», – дип яза профессор М.Бакиров [Бакиров, б. 177].

Әлбәттә, «героик» дигәндә, беренче чиратта халыкка хас, халык күрсәткән батырлык күздә тотыла. Ләкин «Егерме ел солдат булып йөрдем» җырындагы солдатның ерткыч офицерга кул күтәрүе шулай ук батырлыкның (стихияле төстә булса да) бер чагылышы. Ләкин никрутларның трагедиясе аерым командирларга гына кайтып калмый. Монда төп сәбәп илдәге идарә системасында. Никрут җырларында шундый мотивлар торган саен ачыграк яңгыраш ала.

Алдыбызда аккан, әй, агым су,
Кармак салдым шунда балыкка;
Явыз патшаларның малы өчен
Тереләй салалар бит тамугка.
«Газиз башым»

Элекке солдат җырларына игътибар иткән һәрбер кеше безнең халыкның иске армиягә нинди мөнәсәбәттә булганлыгын бик ачык күрә ала. Солдат җырлары да, башка лирик җырлар кебек үк, халык тормышының иҗтимагый тарихын бик матур чагылдырган елъязмалар булып хезмәт итәләр [Татар халык иҗаты, б. 208].

**Әдәбият**

*Бакиров М.* Тарихи җырлар // Татар фольклоры: Югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2008. Б. 176–197.

*Ключарёв А.* Рекрут, солдат җырлары // Татар халык көйләре. Казан. Татар. кит. нәшр., 1941.

*Надиров И.* Татар халкының тарихи җырлары һәм лирик озын җырлары турында // Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. Б. 5–32.

*Пропп В.Я.* Фольклор и действительность. Избранные статьи. М., 1976.

Татар халык иҗаты: Тарихи һәм лирик җырлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.

*Урманчеев Ф.* Тарихи җырлар // Казан утлары. 1969. № 3. Б. 132–148.

*Ярми Х.* Татар халкының поэтик иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. 307 б.

***Хәкимов Рәдис Фәрит улы,***
*филология фәннәре кандидаты,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты*
..........................................

УДК 929

*И.К. Заһидуллин*

# «...ИСЕМЕН ЯХШЫЛЫК БЕЛӘН САГЫНДЫРЫРГА ҖИТӘРЛЕКТЕР»:
## Г. Баттал Габделвәли Яушев турында

Статья посвящена предпринимательской и благотворительной деятельности 1-й гильдии купца Габдульвалия Яушева, проживавшего в г. Троицке Оренбургской губернии, освещается начиная с деда его родословная и труды по открытию школ и русско-татарского учебного заведения для местной татарской общины.

**Ключевые слова:** Габделбари Баттал, Троицк, Габделвали Яушев, городское татарское общество, татарские купцы, мусульманская благотворительность, джадидисты, джадидские школы.

Габделбари Батталның «Троицкий байларыннан вә хәйрат ияләреннән (яхшылык итүчеләр)» башы астында «Габделвәли Яушев» исемле 1912 елда Оренбург шәһәрендәге «Вакыт» матбагасында Габделвәлинең уллары Мөхәммәтгали, мулла Мөхәммәт вә Габделгазиз Яушевлар хисабына дөнья күргән китабы, минемчә, беренче чиратта, укучыга идеал-үрнәк тәкъдим итү, шул үрнәк ярдәмендә изге эшләргә өндәү максатын куя. Идеал исә – замандашларында, шул чорның гадәти булмаган язмышлы кешеләрендә табыла.

Чагыштырып караганда, без – бүгенге тарихчылар – өйрәнү объекты итеп үткән заман вакыйгаларын алып, үз чорыбыз геройлары турында язарга да онытабыз сыман. Әйтик, Ризаэтдин Фәхретдиннең био-библиографик «Асар»ының зур өлешен аның замандашларына кагылышлы язмалар алып тора. Галим фидакарь затлар турындагы мөһим мәгълүматларны киләчәк буыннар өчен теркәп калдырган.

Күренекле химаяче, 1 нче гильдия сәүдәгәр, затлы нәсел вәкиле Габделвәли Яушев (1840–1906) турындагы материалны яшь тарихчы Габделбари Баттал (1880–1969), «Шура» журналы редакторы үтенече буенча Троицкий шәһәрендә аның гаилә әгъзалары белән аралашып туплап, Ризаэтдин Фәхретдингә тапшырган. Басылып чыккан энциклопедик форматтагы язма бу шәхеснең күпкырлы эшчәнлеген тулысынча ача алмаган, чөнки бу рәвештә язылган текст андый бурычны куймый да. Әмма Габделбари Баттал бу ноктада тукталып калмый: 1856 елда Гайса Яушев тарафыннан русча төзелгән нәсел шәҗәрәсеннән киң файдаланып, сәүдәгәр турында өстәмә мәгълүматларны Әхмәтхаҗи ахун Рахманколыйдан һәм Мөхәммәт хәзрәт Бикмәти ярдәмендә туплап, китап яза: бу фидакарь затка үзенең хөрмәтен һәм рәхмәтен белдерә.

Габделбари Баттал Троицкийда чит кеше булмый. Ул Мисырга укырга киткәнче биредә шәех Зәйнулла Рәсүлев-

нең «Рәсүлия» мәдрәсәсендә укый, шәһәрдәге милли вазгыять белән таныш була. Шагыйрь Акмулланың шигырьләрен туплап, 1903 елда Троицкийда әдип турында мәкалә дә бастыра. 1910–1913 елларда, Казанга күченгәнче, Баттал «Рәсүлия» мәдрәсәсендә гарәп теле, татар тарихы һәм әдәбияты дәресләрен алып бара [Кәримуллин, 1999, б. 6, 7, 8]. Биредә эшләгән вакытта, 1911 елда, Габделвәли Яушевка багышланган китабын басмага әзерли.

Китапта милләтнең үсеш потенциалы, кешенең ирекле һәм бәйсез булуы һөнәр һәм байлык белән бәйләп куела. Матди байлык һәм иганәчелек ресурслары булганда, автор теләсә нинди сәяси режим шартларында милли мәдәниятне саклап калырга, милләтнең алга баруын тәэмин итәргә мөмкин икәнлекне искәртә.

Совет хакимияте, илдә тоталитар режим урнаштырып, халыкларны ирекле үсешеннән мәхрүм итте. Дәүләтнең икътисадый нигезе хосуси милекне юк итү аша, ягъни абстракт «халык милке» – чынлыкта бер партия милке барлыкка китереп корылды. Иганәчеләр – буржуаз сыйныф вәкилләре – хезмәт ияләренең сыйнфый дошманы дип игълан ителде. Г. Батталның хезмәте хосусый милек институтын тергезеп һәм көчәйтеп, бай һәм урта катлам эшмәкәрләр катламын булдырып кына, урыслаштыруга каршы торып, милли проектларны тормышка ашырып булачак икәнлекне тагын бер кат раслый.

Атеистик җәмгыятьтән дөньяви җәмгыятькә күчеш чорында яңа катлам эшмәкәрләр иганәчелегенең төп юнәлеше мәчетләр төзү булды. Әмма дөньяви татар җәмгыятендә милли мәдәният күпкырлы, ул дини тәгълимат белән генә чикләнми. Дәвамчанлык өзелү, тарихи хәтер югалу һәм башка сәбәпләр әлегә кадәр иганәчәлекне сабантуй, җырбиюле, күңел ачуга корылган чараларга юнәлтте. Бу активлык киләчәктә милләт үсешен тәэмин итүче башка өлкәләргә дә, беренче чиратта, милли мәгариф һәм милли тәрбия институтларын тергезү һәм эшләтүгә дә хезмәт итәр дигән өмет бар.

Китап, шулай ук, XX гасыр башында татар җәмгыятендә үсеш ала башлаган гражданлык җәмгыятенең нигезләре турында сөйли. Ул елларда зур тизлек белән барган алгарыш шартларында һәр төбәктә, һәр кала һәм салада фидакарь затларның тырышлыгы матур нәтиҗәләргә китергән. Мондый шәхесләрне ике зур төркемгә бүләргә мөмкин. Бер яктан, шушы алгарышның идеологлары һәм гыйлем таратучылары булган муллалар һәм зыялылар, икенче яктан – европалашуны финанс ягыннан тәэмин итүче, шул ук мулла, зыялыларга хезмәт хакы бирүче һәм мәктәп-мәдрәсәләр төзүче, аларны тотучы сәүдәгәрләр, эшмәкәрләр. Тарихи чыганакларда, ул заман матбугаты битләрендә идеологлар һәм зыялылар, иҗат кешеләренең язмалары урын алу сәбәпле, бүген, әлеге вакыйгаларга бер гасырдан артык вакыт узгач күз ташлаганда, яңарыш хәрәкәтендә, бигрәк тә ул массачыл күренешкә әйләнгәнче,

нәкъ менә финансларның роле аеруча мөһим булганлыгы күләгәдә кала сыман. Чөнки дәүләткә түләнгән салымнар, хакимият кушуы буенча башкарылган йөкләмәләр татарларга, мөселманнарга дини яки мәдәни тормышларын алга җибәрү өчен акчалар булып әйләнеп кайтмаган. Мөселманнар дин тотуга, балаларына туган телдә дини белем бирергә рөхсәт өчен дә рус самодержавиясенә рәхмәтле булганнар. Дини менталитет сәдака бирүне, вакыф итүне теге дөньяда оҗмахка эләгү өчен туры юл дип аңлаткан. Яңа заман эшмәкәрләренә җәдит мәктәпләре ачкан, тормышны үзгәртә торган яңалыклар кертергә тырышкан өчен шәригать берни дә вәгъдә итмәгән. Киресенчә, кадимчеләр, еш кына, бу яңалыклар ислам диненә каршы дип сөйләп, бәддога укып торган. Мондый шартларда сүз фәкать шәхеснең җәмгыять өчен риясыз хезмәте турында бара. Гаделбари Баттал бу китабында татар милләтен алдынгы милләткә әйләндерү, ул заман татар эшмәкәрләренең һәм мөселман руханиларының иҗтимагый активлыгы һәм гражданлык позицияләре, гомумиләштереп әйткәндә, шәхеснең тарихтагы роле турында сөйли.

Халкыбызны мәдәни мирасыннан ераклаштыруда узган гасырда ике тапкыр имла алмаштыру гаять тискәре йогынты ясады. Шуңа күрә Казан федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханә хезмәткәрләре Шәрәфиева Рәисә Гамир кызы һәм Әл-Хамад Илфира Арслан кызы тарафыннан кириллицага күчерелгән һәм аңлатмалар белән тәэмин ителгән Гаделбари Баттал китабының тексты мирасыбызны киң җәмәгатьчелеккә кайтару юнәлешендә мөһим адым буларак бәяләнергә лаек.

Җәдитчелек, иҗтимагый күренеш буларак, калада формалашкан һәм үсеш алган. Шәһәр шартларында шәхси инициатива, тырышлык һәм үҗәтлек кебек сыйфатларга ия булганнар еш кына уңышка ирешкән. Шул ук вакытта руслар арасында яшәү татарларны рухи яктан ныграк берләштергән, башка этник төркем вәкилләренең тормышын күзәтү, аларның иҗтимагый яшәү модельләрен өйрәнү мөмкинлеге биргән.

Оренбург губернасы өяз шәһәре Троицкийның Меновой дворы XVIII гасырның азагында Урта Азия сәүдәгәрләре белән товар алмашу үзәге һәм Россиянең мөһим таможня пункты буларак танылган. Биредән кәрван юллары Мәкәрҗә, Эрбет, Минзәлә ярминкәләренә, Казанга, Екатеринбургка һ.б. шәһәрләргә сузылган. Троицкий татарлары 1845 елда беренче булып Чүгүчәккә сәүдә белән барганнар, ә Россиянең көнчыгыш Кытай белән сәүдә мөнәсәбәтләре 1851 елдан гына урнашкан [Венюков, 1868, с. 269]. Урта Азияне Россиягә кушач, 1868 елда биредә таможня пункты ябылган [Собрание узаконений, 1866, № 50].

1880 нче елларга кадәр Троицкий Меновой дворының сәүдә әйләнеше бик югары була. Шул сәбәпле, Троицкий Россиядәге иң төзек, шәп өяз шәһәрләренең берсенә әверелә, аның икътиса-

дында тире тетү һәм терлек маен эретү мануфактуралары мөһим роль уйный [Самородов, 1999, с. 93–101]. Каспий арты һәм Ташкент–Оренбург тимер юллары төзелгәч, XX гасыр башында Троицкий шәһәре Россия белән Урта Азия арасындагы сәүдә үзәге булудан туктый.

1897 елда Троицкийда 8430 мөселман яшәгәнлеге, аларның шәһәр халкының өчтән бер өлешен тәшкил иткәнлеге мәгълүм [Первая всеобщая перепись, 1904, с. 63–68]. Алар арасында татарлар 7283 кеше булып (86,3%), шуларның 264 ир-аты сәүдәгәр дип язылган [Хамитбаева, 2012, с. 134–138].

Татар шәһәр җәмгыятьләре моделендә Троицкий татар шәһәр җәмгыяте «татар җәмгыять-шәһәре»нә туры килә. Аның төп сыйфатлары түбәндәгедән гыйбарәт. Татарлар шәһәр җәмгыяте һәм шәһәр икътисадый тормышына йогынты ясыйлар, кварталларда, урам-урам булып тупланып, күрше община принцибы буенча төзелгән йортларда яшиләр, автоном тормыш алып баралар, социаль һәм мәдәни проблемаларны мөстәкыйль хәл итәләр, мөселман (кимендә 2–3 мәчет, мәхәллә, дини һәм милли белем бирү йортлары) һәм шәһәр инфраструктурасына (күчемсез милек, йортлар, кибетләр, ашханәләр, базар, башка җәмәгать биналары) ия булалар, икътисадый яктан нык җәмгыятьнең вәкилләре шәһәр үзидарәсе органнары эшендә катнашалар һ.б. «Татар җәмгыять-шәһәре»н булдыруда сәүдәгәрләрнең өлеше искиткеч зур була, аларның йортлары, кибетләре, сәнәгать биналары, алар төзеткән мәчет-мәдрәсәләр Троицкийның татар өлеше архитектура йөзен билгеләгәннәр, җәмгыять территориясенең киңәюен тәэмин иткәннәр.

Казан губернасы Иске Мәңгәр авылыннан Троицкийга бәхет эзләп күченеп килгән лашманчы Гайса Яушев беренчел капиталны, күпчелек татар эшмәкәрләре кебек үк, Бохарага баручы кәрваннарда хезмәтче, йөк бәйләүче булып ялланып эшләп туплаган. Аннары Гайса Меновой дворда һәм шәһәрдә кибетләр ачкан. Бохарадан күреп кайтып, мәчетләр төзүгә ярдәм иткән: үзе яшәгән 2 нче мәхәллә мәчетен берничә тапкыр ремонтларга, яңартырга булышкан, ул төзеткән 3 нче мәхәллә мәчете акрынлап шәһәрнең татарлар яшәгән үзәгенә әверелгән. Өлкән уллары, икенче буын сәүдәгәрләр Хәкимҗан (1825–1871) белән башка чыккан улы Әхмәтҗан XIX гасырның икенче чирегендә инде аталары маллары хисабына үзләре кәрван йөрткәннәр, 1853 елда Әхмәтҗан улы Габделвәлине дә Бохарага алып барган [Баттал, 1912, б. 9].

Габделбари Баттал Габделвәлинең сәүдә һәм җитештерү эшчәнлегенә зур игътибар итми, мондый максат куймый да. Шулай да Гайса Яушев нәселенең зураюын, ул өйләндереп, кыз биреп, кияүләр, кодалар белән Урта Азияне, Себер шәһәрләрен колачлаган сәүдәгәрләр һәм руханилар кланнарын үстерүләрен шәрехли. Туган-тумачалык, агай-энелек артыннан сәүдә элемтәләре ныгыганлыгын фаразларга мөмкин.

Халык хәтеренә кереп калырлык иганәчелек өчен шулкадәр малны Габделвәли Яушев нинди юллар белән туплаган соң?

Габделвәлинең этисе Әхмәтҗан (1818–1875) алыш-биреш операцияләрен Ташкент якларында җәелдерә, шәһәрнең 1 нче гильдия сәүдәгәре булып языла. Аның уллары, шулай ук Ташкентның 1 нче гильдия сәүдәгәрләре Габделвәли, Муллагали (1864–1926), Мөхәммәтсадыйк (1845–1899?) һәм Мөхәммәтшәриф (?-1906), 1887 елда берләшеп «Габделвәли Әхмәтҗан угылы Яушев вә борадәрләренең тиҗарәтханәсе» исемле сәүдә йортын нигезлиләр.

Яушевлар Оренбург далаларында һәм Урта Азиядә сәүдә иткән татар сәүдәгәрләре арасында, Каргалы бистәсеннән чыккан бертуган Хөсәеневләрдән кала, сәүдә әйләнеше күләме ягыннан икенче урында булган «сәүдә империясе» төзиләр. Бертуган Хөсәеневләр уртак капиталларын бүлгәннән соң, Яушевларның сәүдә йорты иң зур табыш алучы татар фирмасына әйләнә дип уйларга нигез бар.

Инде шушы табышны тәэмин иткән кибетләр челтәрен һәм сәнәгать биналарын санап үтик.

Сәүдә йортының баш конторасы Троицкийда булып, ике контора тагын Мәскәүдә һәм Варшавада ачыла. Контора бүлекләре Чиләбедә, Кочкарда (Оренбург губернасы), Кустанайда (Тургай өлкәсе), Ташкент һәм Таразда (Сырдәрья өлкәсе), Тукмакта (Семиречинск өлкәсе), шулай ук Казак даласында даими ярминкәләр була торган җиде төрак пунктында (Звериноголов, Карачел, Николаев, Тукман, Тургай, Усть-Уй, Чөмләк) һәм Кытай шәһәре Гөлҗәдә уңышлы эшли. Яушевлар халык көнкүрешенә йөз тоткан, һәрдаим кирәк булган йон, терлек мае, чи һәм иләнгән тире, чәй һәм шикәр кебек товарлар белән зур масштабта сәүдә иткәннәр. Төрле шәһәрләрдә ачылган 20 кибеттә мануфактура, галантерея, бакалея, ювелир эшләнмәләре, тимердән хуҗалык кирәк-яраклары, күн, ислемайлар, тәмәке, аяк киемнәре, галошлар, дарулар һ.б. товарлар сатылган. 1895 елда «Габделвәли Әхмәтҗан угылы Яушев вә борадәрләренең тиҗарәтханәсе»нең тукымалар белән сәүдәсе генә дә 3,6 млн сум тәшкил иткән [Денисов, 2011, с. 88–90].

Яушевлар кибетләрендә үзләре җитештергән товарларны да сатканнар. 1852–1859 елларда Гайса Троицкийда сабын кайнату һәм тире иләү мануфактуралары ачкан була. Атасыннан калган тире эшкәртү мануфактурасын Габделвәли зурайткан һәм киңәйткән. 1895 елда Яушевларның бу мануфактураларында 78 эшче 216 019 сумлык товар җитештергән: ат, кәҗә, сарык, тана тиреләрен иләгәннәр һәм сабын кайнатканнар (1908 елда бу күрсәткеч 104 эшче тырышлыгы белән 388143 сумга җиткән). Алар шулай ук Троицкийда сугым урыны, терлек мае эретү, сарык йонын юу предприятиеләре ачып, терлекчелек продукциясен беренчел эшкәртүне һәм сатуны оештырганнар.

Яушевлар игенчелек продукциясен дә эшкәртүне оештыр-

ганнар. Троицкийда 1881 елда пар машинасы белән хәрәкәткә китерелүче тегермән төзегәннәр, он һәм ярма җитештерүне һәм сатуны җайга салганнар. Аларның Ташкент янындагы плантацияләрендә үстерелгән мамык, чистартылып һәм прессланып, Россия шәһәрләренә озатылган [Денисов, 2011, с. 88, 92, 93].

Габделвәлинең белем алуы башка сәүдәгәр балаларыныкыннан аерылмаган. Ул үзе яшәгән 2 нче мәхәллә мәдрәсәсендә һәм Верхнеурал өязе Илче авылында Юлмөхәммәт һәм Гариф исемле хәлфәләрдә укыган.

Г. Баттал Габделвәлинең 1894 елда шәһәрнең 6 нчы мәчетен, аның янында мәдрәсә комплексын, янәшәдә вакыф итеп елына 100–120 сум табыш бирә торган кибет бинасын төзетүе хакында яза. 1901 елда бу мәчеткә тагын вакыф итеп шәһәрдәге барлык каралты-курасы белән 4 йорт урынын бүләк итә [Денисов, 2011, с. 67–69]. Безнең фикеребезчә, Габделвәлинең иганәчелеге турында язганда шунысын да истә тотарга кирәк: бертуган Яушевларның сәүдә йортын Габделвәли җитәкләгән, әмма Г. Баттал күрсәткән Троицкийда 6 нчы мәхәллә мәчете һәм уку-укыту комплексы, шулай ук Кустанайда таш мәчет, Троицкий өязе Звериноголовский һәм Борхан авылы мәчетләре һ.б. гыйбадәтханәләр төзүгә тотылган зур күләмле чыгымнар – һичшиксез, шушы сәүдә йортының, бертуган Яушевларның уртак капиталы булырга тиеш. Бу юнәлештәге эшчәнлекне бертуганнар абыйлары Габделвәли ихтыярына тапшырганнар. Габделвәли исә мәчет-мәдрәсә салдыру, уку һәм укытуга ярдәм итү кебек эшләрдә Әхмәтхаҗи ахун Рахманколый, дамелла Мөхәммәт Бикмәти һәм шәех Зәйнулла Рәсүли белән киңәш иткән итә [Баттал, 1912, б. 12].

Троицкийда җәдитчә укытуны нәкъ менә шушы шәхесләр кертә. Бишенче мәхәллә имамы һәм «Рәсүлия» мәдрәсәсе мөдире шәех Зәйнулла ике хәлфәсен Бакчасарай шәһәренә, Исмәгыйль Гаспринский янына, ысулы җәдит буенча укыту методикасын үзләштерергә җибәрә, шулай 1895 елда Троицкийда җәдиди ибтидаи (башлангыч) мәктәп эшли башлый [Фархшатов, 2009, с. 24]. Әхмәтхаҗи ахун Рахманколый, ысулы җәдидәне гамәлгә кую нияте белән хәлфәсе Мөхәммәтзакир Ваһаповны Истанбулга җибәргәндә, чыгымнарның күп өлешен Габделвәли каплый. Габделвәли Троицкийда гына түгел түгел, ә Троицкий һәм Чиләбе өязендәге авылларда да җәдиди ибтидаи мәктәпләр ачтырып, аларга матди ярдәм итә [Баттал, 1912, б. 12].

Ләкин башлангыч акрын юл яра. Беренче чиратта абруйлы дин башлыгыннан фатиха кирәк була. Габдерәшит Ибраһимов үзенең истәлекләрендә 1897 елда мөфти М. Солтановның, Троицкийга килгәч, Габделвәли Яушевның үтенеп соравына карамастан, ысулы җәдитчә укытуны яклап шәһәр муллалары алдында бер кәлимә сүз дә әйтми китүен теркәп калдырган [Ибраһим, 2013]. Биредә мөфти М. Солтановны яклап шуны әйтәсе килә: мөфти һәм казыйлар белән якыннан аралашкан сәүдәгәр Габ-

делгани Хөсәенев үзенең 1898 елның февраль ае башында яздырган бер хатында, җәдитчә укыту өлкәсендә Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыя белән кадимче муллалар арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләргә ишарәләп: «Туры әмернамә язарга куркалар. Мөфти дә яза алмый. Хат белән «иҗтиһад кылыгыз», дип, үгет юлы белән язгаладылар», дип белдерә. Шундый катлаулы шартларда, гражданлык батырлыгы күрсәтеп, мөфти М. Солтанов 1898 елның 25 августында шәһәр имамнарына аталган, имамнар мөселманнар арасында алдынгы фикер таратырга тырышырга тиеш дигән махсус нәсыйхәтнамә белән мөрәҗәгать итә [Заһидуллин, 2014, б. 134].

Русча ару сөйләшкән, ләкин укый-яза белмәгән Ташкентның 1 нче гильдия сәүдәгәре Габделвәли рус газеталарын укыттырып, дөнья хәлләре белән танышып баруны гадәткә керә. Ул мөселманнарның балаларына русча укытуны яклап чыга. Башка шәһәрләрдән, төбәкләрдән аермалы буларак, биредә 1877 елда мәдрәсә каршында ачылган рус сыйныфының уңышлы эшләп китүендә бу уку йортының шәрәфле карап торучысы (почетный блюститель) 1 нче гильдия сәүдәгәре Г. Яушевның роле зур. Ул мәгариф өлкәсендә хезмәтләре өчен 1898 елда Анна лентасына тагылган «Тырышлык өчен» медале белән бүләкләнә [ЦОУО, 1899, № 2, с. 60], Габделвәлигә Оренбург уку-укыту округы попечителенең дә рәхмәте ирештерелә.

Укырга теләүчеләр нык күбәю, укытырга урын җитмәү сәбәпле, 1997 елда Габделвәли ир туганнары белән бергә хакимият алдына уку йортын 2 сыйныфлык рус-татар училищесы итеп үзгәртү мәсьәләсен куя. 1898 елда теркәлү узган «Троицкий мөселман хәйрия җәмгыяте» уку бинасы өчен 7000 сумга флигеле һәм хуҗалык корылмалары булган, беренче каты кирпечтән, икенче каты агачтан төзелгән иркен йорт сатып ала, хәйрия җәмгыяте рәисе Габделвәли үз хисабына 4 мең сумга бинага төртке төзетә. «Троицкий мөселман хәйрия җәмгыяте» ислам дине нигезләрен укытачак мөгаллим тотуны һәм 12 ярлы гаиләдән булган малайларны укытуны, аларны тулай торак белән тәэмин итүне үз өстенә алачагын белдерә [Денисов, 2011, с. 102–103]. 1901 елда ачылган 5 еллык курслы ике сыйныфлы рус-татар училищесының шәрәфле карап торучысы Г.Яушев яңа уку йортын аякка бастыруга куйган хезмәтләре өчен 1903 елда Александр лентасына тагылган «Тырышлык өчен» алтын медаленә лаек була [ЦОУО, 1904, № 3, 73].

Русча укытуны яклау белән бергә, Яушев руслаштыру һәм милли изүгә каршы көрәштә дә катнашкан. Әхмәтхаҗи ахун Рахманколыйның «мөселман эшләре» буенча эшчәнлеген финанславы мәгълүм. Әйтик, 1904 елның 20 декабрендә ахун эчке эшләр министры исеменә мөселманнарның никах һәм аерылу мәсьәләләренә кагылышлы «Гражданлык уложениясе»нең яңартылган текстын эшләячәк комиссиягә үз тәкъдимнәрен җиткерә [РДТА, 821 фонд, 10 тасв., 25 эш, б. 256–257]. 1892–1893 ел-

ларда мөселман дини китапларын цензор тарафыннан төзәтү башлангач, татар җәмгыяте Әхмәтхаҗи ахун Рахманколыйны һәм Мулламөхәммәт Бикмәтине вәкилләр итеп Санкт-Петербургка җибәрә, алар исә, түрәләр белән сөйләшергә җиңел булсын дип, Уфадан юрист Әбүсогуд мирза Әхтәмевне чакыралар. Троицкий мөселманнары вәкилләре тәкъдиме белән башкалада кырымлы Ильяс мирза Бораганскийның шәхси нәшрияты Габделвәли Яушев хисабына 1000 данә «Мишкат әл мосабих» – хәдисләр җыентыгын-китабын бастырганнар [Баттал, 1912, б. 13–15]. Әхмәтхаҗи ахун Рахманколый 1905 елның 10–15 апрелендә Уфа шәһәрендә узган голәмәләр мәҗлесендә мөселманнарның дин эшләрен оештыру буенча яңа проект әзерләүдә дә катнаша. Шул ук елны мөфти М. Солтанов аны Россия кануннарында мөселманнарның хокукларын тигезләү өчен император кушуы буенча оештырылган махсус киңәшмәгә 13 руханиның берсе буларак тәкъдим дә итә [Загидуллин, 2014, с. 371, 415].

Сәүдәгәр Габделвәли Яушев зур хөрмәткә ия шәхес булган. 1895 елны ул мөфти Солтанов, Әхмәтхаҗи ахун Рахманколый белән, Николай II-нең тәхеткә утыруын котлар өчен, башкалага чакырыла, Кышкы Сарайда император тарафыннан кабул ителә һәм императрицага дип ун мең сумлык мех һәдия тапшыра.

Габдерәшит Ибраһимов 1904 елның октябрендә сәяхәте вакытында Троицкий шәһәренә килеп, Габделвәли Яушев һәм Әхмәтхаҗи ахун Рахманколый белән киңәшләшә. Минзәлә ярминкәсе вакытында, 1905 елның гыйнварында, татар җәмәгать эшлеклеләре мәҗлесен үткәрү уена килгәч, Габдерәшит Ибраһимов бу хакта 1904 елның 20 ноябрендә Габделвәли Яушевка хат яза [Сенюткина, 2007, с. 215–218]. Габделвәли Яушев Түбән Новгород шәһәрендәге ярминкә вакытында 1905 елның августында үткән Бөтенроссия мөселманнарының беренче съездында катнаша, ул милләткүләм яңа проектка иганәче буларак җәлеп ителә. [Яушевы, 2014, с. 354].

Кызганычка каршы, 67 яшьлек Габделвәли Яушевның 1906 елның 13 сентябрендә йөрәге тибүдән туктый. Вафатыннан соң, ир туганнары Мөхәммәтшәриф һәм Муллагали фирманың исемен «Борадәран Яушевлар тиҗарәтханәсе» дип үзгәртәләр [Баттал, 1912, б. 16], абыйлары капиталыннан балаларына мирас бүлеп бирәләр. Габделвәли Яушевның балалары арасыннан, бигрәк тә, Казан шәһәре сәүдәгәре Сөләйман Аитовка тормышка чыккан кызы Фатиханы фидакарь эшчәнлеге игътибарны җәлеп итә. Фатиха Аитова үзенә тигән мирас хисабына 1910 елда Казанда 4 сыйныфлы дөньяви кызлар мәктәбе оештыра, 1914 елда уку йортын татар кызлары гимназиясе итеп үзгәртә [Мәхмүтова, 2012, б. 262–392]. Шулай Габделвәли Яушевның иҗтимагый эшчәнлеге балаларында дәвам итә.

**Әдәбият**


*Баттал Г.* Габделвәли Яушев / наширләре: Габделвәли угыллары: Мөхәммәтгали, мулла Мөхәммәт вә Габделгазиз Яушевлардыр. Оренбург: «Вакыт» матбагасы, 1912. 17 б. («Троицки байларыннан вә хәйрат иярәреннән» сериясе).

*Венюков М.* По окраинам русской Азии и записки о них. СПб.: Тип. импер. Акад. наук, 1868. 535 с.

*Фархшатов М.Н.* Введение // «Дело» шейха Зайнуллы Расулева (1872–1917). Власть и суфизм в пореформенной Башкирии. Сборник документов / сост., автор предисл., введения, коммент., прим., указ. и глоссария М.Н. Фархшатов. Уфа: ИИЯЛ УНЦ РАН, 2009. С. 11–80.

*Денисов Д.Н.* Очерки по истории мусульманских общин Челябинского края (XVIII – начало XX в.). М.: Фонд «Марджани», 2011. 256 с.

*Заһидуллин И.К.* Мәхкамә-и шәргыя Ырынбургыя – XIX гасыр азагы мөселман җәмгыятенең реформалар үзәге // Tatarica. 2014. № 2 (3). Б. 130–139.

*Загидуллин И.К.* Татарское национальное движение в 1860–1905 гг. Казань: Татар. кн. изд-во, 2014.

*Ибраһим Г.* Бөгрәделек көндәлеге / кереш сүз, факсимиле һәм гарәп транскрипциясе Ә. Бостанов, татарчага тәрҗемәсе Д. Гыйльметдинов. Казан, 2013. 137 б.

*Кәримуллин Ә.Г.* «Ике бертуган Максудилар» авторы Г.Г. Баттал-Таймас турында // Баттал-Таймас Г.Г. Ике бертуган Максудилар = Два брата Максуди / төрекчәдән татарча һәм русча тәрҗемә, кереш сүз, библиография, шәрехләр Ә.Г. Кәримуллиныкы. Казан: Фән, 1999. Б. 5–12.

*Мәхмүтова А.Х.* Фатиха Аитова // Милләт аналары: тарихи документаль һәм биографик җыентык / төз.-авт. А.Х. Мәхмүтова. Казан: Җыен, 2012. Б. 262–392.

Первая всеобщая перепись населения Российской империи 1897 г. Т. XXVIII. Оренбургская губерния. СПб.: Изд-во Центрального статистического комитета МВД, 1904. 198 с.

РДТА, 821 нче фонд, 10 нчы тасв., 25 нче эш.

*Самородов Д.П.* Утверждение капитализма в торговле дореволюционной Башкирии: Вторая половина XIX – начало XX в. Стерлитамак: Стерлитамак. гос. пед. ин-т, 1999. 349 с.

*Сенюткина О.Н.* Тюркизм как историческое явление (на материалах истории Российской империи 1905–1916 гг.). Н. Новгород, 2007.

Собрание узаконений и распоряжений правительств, издаваемое при Правительствующем Сенате. 1866. № 50. С. 471.

*Хамитбаева Н. С.* Социально-сословный состав и общественное разделение труда в татарских общинах городов Поволжья и Приуралья в конце XIX в. // Научный Татрастан. 2012. № 3. С. 130–140.

ЦОУО. 1899. № 2. С. 60.

ЦОУО. 1904. № 3. С. 73.

Яушевы // Татарская энциклопедия. Т. 6. У–Я. Казань: Институт Татарской энциклопедии, 2014. С. 353–354.


**Кыскартылган сүзләр:**

РДТА – Россия дәүләт тарих архивы;

ЦОУО – Циркуляры Оренбургского учебного округа.


***Заһидуллин Илдус Котдус улы,***

*тарих фәннәре докторы, Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Яңа тарих бүлеге мөдире*

*Габделбари Баттал*

# ГАБДЕЛВӘЛИ ЯУШЕВ*

## Мөкаддимә[1] урынына

Троицки байларыннан вә хәйрат ияләреннән Габделвәли Яушевның тәрҗемәи хәлен «Асар»га дәрҗ итү[2], Ризаэддин хәзрәткә[3] матлуб[4] булганлыктан, шул тәрҗемәи хәл[5] өчен мәгълүмат җыйдырып, яки үзен тәртип иттереп җибәрүләре хосусында, хәзерге Яушевлар тиҗарәтханәсенең[6] патроны булган Муллагали әфәнде Яушевка хат язган; ләкин ни өчендер, бу хат җавапсыз калган. 1910 нчы елның җәендә мин Троицкига килгәч, Ризаэддин хәзрәтнең бу арзусын[7] Габделвәлинең угылларына сөйләдем. Алар, ошбу тәрҗемәи хәлне яздыруга карар биреп, бу хезмәтне миңа тапшырдылар. Мин моны, «Асар»га дәрҗ итәрлек рәвештә язып бетереп, инде җибәрдем дип торганда, «Асар» оригиналларының мосаддира[8] ителгәнен газеталарда укыдык.

Габделвәлинең бәгъзе балалары: «Аерым рисалә[9] итеп бастырсак ничек булыр икән?» – дидекләреннән, бу хосуста киңәш итеп, Ризаэддин хәзрәткә мәктүб яздым. Мәктүбемә каршы ошбу җавапны алдым: «Габделвәли тәрҗемәсен язып бетерүегез өчен шатландык. «Асар»ның ни вакыт кайтуы мәгълүм түгел, сәламәт кайтуы да шөбһәле. Кәгазьләре тегелмәгән, рәкымнар[10] куелмаган иде. Мөкаддимәсен язып тәмам итдекем соң: «Имде рәкымнарын иртә торгач куярым», – дия калдырып урыныма яттым, шул кичәдә мәгълүм афәт[11] килде. Иртә рәкымнарны тәртип итеп, сәгать 10 да үз хозурымда Бисмилла куйдырып, хәреф җыярга башлатмак хыялыннан идем, фәкать насыйп булмады. Холаса[12]: сезнең яздыгыңыз, иншалла, үзенә мөстәкыйль бер рисалә булырга ярар, булган нәрсә тик ятмасын, ихтимал, безнеке

---

* Баттал Г. Габделвәли Яушев. Наширләре: Габделвәли угыллары: Мөхәммәтгали, мулла Мөхәммәт вә Габделгазиз Яушевлардыр. Оренбург: «Вакыт» матбагасы, 1912. – 17 б. («Троицки байларыннан вә хәйрат ияләреннән» сериясе).

[1] мөкаддимә – кереш сүз.

[2] дәрҗ итү – теркәү, арага кертү.

[3] Фәхреддин (Фәхреддинев) Ризаэддин Фәхреддин улы (1859–1936), мәгърифәтче галим, тарихчы, дин белгече һәм җәмәгать эшлеклесе.

[4] матлуб – теләнгән, соралган нәрсә.

[5] тәрҗемәи хәл – биография.

[6] тиҗарәтханә – сәүдә йорты.

[7] арзусын – теләгеn.

[8] мосаддира – югары дәрәҗәле.

[9] рисалә – брошюра.

[10] рәкым – бит саны, номер.

[11] афәт – бәла-каза, бәхетсезлек.

[12] холаса – кыскасы.

кеби булмаса да, башка бер афәт килмәктән иминият юк. Шуның өчен басылуын муафыйк[1] күрер идем, ягъни бу көннән үзенә аерым рисалә ителеп басылсын. Кеше сүзеннән курыкмагыз, басылсын. Бүгенге кешеләр сүзләренә игътибар юк. Игътибар исә, киләчәктәгеләргәдер. Киләчәкләр рәхмәттән башка бер нәрсә дә әйтмәсләр».

Тәртип иткәнем ошбу тәрҗемәи хәлне хөрмәтле остаз Ризаэддин хәзрәткә җибәреп күрсәткән идем, ул лотфән[2] бәгъзе кимчелекләрен күрсәтеп аерым билгеләр куеп җибәрде. Аларны төзәттем. Дәхи рисалә шәкелендә[3] басылачак булгач, аерым-аерым сүз башлары ясарга вә бәгъзе нәрсәләр арттырырга туры килде. Габделвәли Яушев хакындагы мәгълүматның иң күп өлешен ахунд хәзрәт Рахманколый вә Мөхәммәт хәзрәт Бикматидән алдым. Ошбу мөхтәрәм өч затка чын күңелемнән тәшәккер[4] итәмен.

Ошбу рисаләгә сахибе[5] тәрҗемәнең рәсеме, имзасы, туган вә үлгән өйләренең рәсемнәре, аның киңәшчеләреннән ахунд Рахманколый вә шәех Зәйнулла Рәсүлинең рәсемнәре һәм Яушевлар салдырган Кустанай[6] мәчетенең рәсеме дәрҗ ителде.

*Г. Баттал[7].*

*Троицкий 1911 ел, 2 октябрь.*

I

**Габделвәли Яушев**

*Бабалары вә анларның ватаннары – Троицкида Гайсадан таралган Яушевлар.*

**Габделвәли бин Әхмәтҗан бин Гайса бин Йосыф бин Бикбау бин Мортаза бин Морад бин Габдулла бин Дустмөхәммәт бин Ягуш бин Яуш[8].**

Бу затның балалары Казан өязендә Иске Мәңгәр[9] авылында көн иткәннәр. Троицкига Гайса Йосыф угылы күчеп килгән. Бу шәһәрдә булган Яушевларның һәммәсе шушы Гайсадан таралганнар: моның Фатыйма

---

[1] муафыйк – туры килгән, урынлы.

[2] лотфән – ярдәм йөзеннән, хуш күреп.

[3] рисалә шәкелендә – брошюра формасында.

[4] тәшәккер – рәхмәт белдерү.

[5] сахиб – ия, хуҗа.

[6] Кустанай – Казакъстандагы шәһәр, 1893–1895 елларда Николаевск исемен йөрткән.

[7] Баттал Габделбари Габдулла улы (1880–1969), тарихчы, филолог, журналист, җәмәгать-сәясәт эшлеклесе.

[8] Троицкида Габдулла Хәкимҗан угылы Яушев кулындагы русча тәртип ителгән шәҗәрәдән (родословное князей Яушевых) күчерелде. Шәҗәрәнең астында язылган русча язуларның укырга мөмкин булган кадәресеннән бу шәҗәрәнең 1856 нче миладида Габделвәлинең бабасы Гайса тарафыннан төзелдереп, Казан шәһәрендәге әллә нинди мәхкәмәләрдә тасдыйк вә тәэкид иттерелгәнлеге аңгарыла. Бу язуларның байтагын, кәгазь вә чүпрәкләре белән бергә, тычканнар ашаган вә бөтен шәҗәрә майланып вә пычранып беткән. Габдулла әфәнде аны миңа әллә кайдан – кладовойдан эзләп табып бирде. (Автор искәрмәсе).

[8] Иске Мәңгәр авылы, Әтнә районында, район үзәгеннән 6 км көнчыгышрак, Ашытның сул кушылдыгы Симет елгасы бассейнында. Казан ханлыгы дәвереннән мәгълүм.

Габдерәфыйкъ кызы исемле хатынынннан: Әхмәтҗан, Мөхәммәтҗан, Хәкимҗан, Шакирҗан. Исмәгыйльҗан вә Зәкирҗан исемле угыллары; Гайшә, Зөһрә вә Гафифә атлы кызлары; Мәхбүбкамал исемле икенче бер хатынынннан Мөхәммәтлатыйф исемле бер угылы булган.

Мөхәммәтҗан бин Гайсаның Мөхәммәтгали, Мөхәммәтшаһ дигән ике угылы булган; болардан әүвәлгесенең хәяттә дүрт угылы вә бер кызы бар; Мөхәммәтшаһ бин Мөхәммәтҗан үзе дә хәяттә; балалары күп.

Хәкимҗан бин Гайсаның Габдулла вә Мөхәммәтвәли исемле ике угылы бар; Әшраф исемле кызы сахибе тәрҗемә Габделвәлинең тәхет никахында иде; Бәдәрсафа атлы кызы Троицкида Вәлишакир угылы нам кемсәгә бирелгән. Хәдичә исемле кызы элек, сахибе тәрҗемә Габделвәлинең Мәүдүдә исемле хатынынннан туган Габдерахман тәхет никахында булган; хәзердә Казанда Яңа Бистәдә имам Кәшшаф Тәрҗемани[1] тәхет никахында булып, бер хәяттәдер.

Шәкирҗан бин Гайсаның гакыйбе[2] юк. Бу – 1871 нче миладида ахунд Әхмәтхаҗи Рахманколый белән бәрабәр хаҗга барганда борадәре Хәкимҗан белән икесе бергә Мәдинә[3] белән Мәккә[4] арасында «Раян» дигән урында вафат вә шунда мәдфүн[5] булганнар.

Исмәгыйльҗан бин Гайсаның Маһибәдәр исемле бер кызы гына калган; әле хәяттәдер. Закирҗан бин Гайсаның гакыйбе юк.

Гайшә бинт Гайса вакыт илә Троицкида 2 нче мәхәлләдә имам булган Әхмәт[6] хәзрәтнең туганы Габделлатыйф Халит угылының тәхет никахында булган. Моның хәяттә бер кызы гына бар.

Зөһрә бинт Гайса Троицкида Габдерахман Габбас угылы дигән бер кемсәнең тәхет никахында булган. Моның хәяттә бер угылы ике кызы бар.

Гафифә бинт Гайса, Петропавелда ахунд булган Габделбарый Габбас угылы[7] Яушевка бирелгән. Аннан Габделваһап исемле угылы хәзер дә шул шәһәрдә имам вә ахундтыр.

---

[1] Тәрҗемани Кәшшаф (Тәрҗеманов Кәшшафетдин Кыяметдин улы) (1877–1943), дин һәм җәмәгать эшлеклесе, дин гыйлеме белгече. Репрессия чоры корбаны.

[2] гакыйбе – нәселенең дәвамы юк.

[3] Мәдинә, Согуд Гарәбстанында Мәккәдән 400 чакрым төньяктарак урнашкан шәһәр.

[4] Мәккә, Согуд Гарәбстанындагы шәһәр, Мөхәммәд пәйгамбәрнең ватаны. 7 нче гасырдан мөселманнарның изге шәһәре һәм хаҗ кылу урыны.

[5] мәдфүн – күмелгән, җирләнгән.

[6] Тәрҗемәи хәле «Асар»да язылгандыр.

[7] 2 нче кыйсем «Мөстәфадел-әхбар»ның 261–263 битләрендә шушы Габбас хәзрәтнең тәрҗемәи хәле язылган. Нәсебен: «Габбас бин Габдерәшит бин Әхмәт бин Шәкир бин Хәсән бин Котлыгмөхәммәт бин Ишмөхәммәт бин Дустмөхәммәт бин Багыш бин Яуш» дисә дә, русча язылмыш рәсми шәҗәрәдә ул «Яуш»ка менә бу рәвешчә илтеп терәлгән: «Габбас, Габдерәшит, Хуҗа, Котлыгъәхмәт, Хөсәен, Хәсән, Дустмөхәммәт, Багыш, Яуш». Кайсының дөреслеген Алла белсен. (Автор искәрмәсе.)

Мөхәммәтлатыйф бин Гайсаның хәяттә Муллаәхмәт, Мулламөхәммәт исемле угыллары; Мәгъмүрә исемле бер кызы бар.

Әхмәтҗан бин Гайсаның Габделвәли (сахибе тәрҗемә), Мөхәммәтсадыйк, Мөхәммәтшәриф һәм Муллагали исемле угыллары; Газизә, Маһирә вә Маһитаб атлы кызлары булган.

Мөхәммәтсадыйктан Шакир исемле бер угылы; Маһруй вә Мөстүрә исемле ике кыз калган. Шакир вафат булып өч угылы, бер кызы калган. Маһруй белән Мәстүрә икесе дә иргә барганнар вә хәяттәдерләр.

Мөхәммәтшәриф 1906 нчы миладида сахибе тәрҗемә белән бер елда вафат булып, Мөхәммәтлатыйф исемле угылы, Мөнәвәрә исемле кызы калды.

Муллагали хәяттә булып бүгенге «Торговый дом борадәран Яушевлар» фирмасының патроны (олыгысы)дыр.

Газизә – Вәлитаһир угылы Уразаев нам кемсә никахында булган. Ул үлгәч, туганы Маһирә дә аңа барган. Газизәдән туган Мөхәммәтҗан Уразаев Ташкент шәһәрендә бер хәят булып, борадәран Яушевлар хезмәтендәдер. Маһитаб, хәзердә 2 нче мәхәлләдә имам, мулла Мөхәммәтзариф угылы Бикматовның тәхет никахында булып бер хәяттәдер.

## II

*Гайсаның мал табуы, изгелекләре вә торган йорты – Әхмәтҗанның үз алдына эш күрә башлавы – Хәкимҗанның аңа вә сахибе тәрҗемәгә ярдәме – Әхмәтҗанның хаҗ кылуы вә вафаты – сахибе тәрҗемә эш башында.*

Сахибе тәрҗемәнең бабасы Гайса, Троицкидан Бохарага[1] чыгып китеп анда чын гайрәт вә һиммәт белән кәсепкә тотынган, кәрван булып ком диңгезләре аркылы төрле шәһәрләргә юнәлә торган дөяләргә артыла[2] (йөкләнә торган йөкләрне бәйләү хезмәтендә вә башка хезмәтләрдә булынган). Аның шул рәвешчә берничә ел кәсеп итеп сәрмая[3] ясагач, Троицкига кайтып сәүдәгә тотынган: Минаунида[4] вә шәһәр эчендә дөкян – кибетләр ачкан; акрын-акрын игътибарлы вә инабәтле[5] сәүдәгәрләр рәтенә тезелсә дә, артык байый алмаган, тик угылы Хәкимҗан җитешкәч кенә яхшы ук дәүләт иясе булып киткән вә бай исемен алган.

Гайса, дәүләт иясе булганнан соң мәчетләрне карарга бик әһәмият бирә торган булган: 2 нче мәхәлләдәге мәчетне берничә мәртәбә тәгъмир[6] иттергән вә 3 нче мәхәлләдәге мәчетне бөтенләй үз кесәсеннән салдырган.

---

[1] Бохара – Урта Азиядәге иң борынгы шәһәрләрнең берсе.
[2] артыла – төялә, йөкләнә.
[3] сәрмая – төп капитал, акча.
[4] Минауни – алыш-биреш урыны.
[5] инабәтле – ышанычлы, таянычлы.
[6] тәгъмир – төзәтү, яңарту.

Ул вакытта шәһәрнең ул як очы, хәзерге Һәдиятулла Дивәзиев йортыннан да югарырак булган. Бинаән галәйһи[1], бу мәчет салынган урын буш дала, өстәвенә сазлык, сулы бер күләвек булган. Гайса бу күләвекне балчык вә таш белән тутырттырып шул җиргә мәчет салган. Ул чакта ул тирәдә татарлар да бик аз булган. Ләкин соңыннан килгән татарларның иң күп өлеше шул тирәгә җыелганнар. Бу көндә татарның иң күп булган урыны шул тирә булып, «шәһәрнең татар кыйсеме» дип аталадыр.

Гайсаның тормышы 2 нче мәхәлләдә булган. Аның торган йорты хәзер моның угылы Латыйф балалары милкендәдер. Ак буявы вә гомумән стиле – искелек вә борынгылыктан хәбәр биреп торадыр.

Гайса, сахибе тәрҗемәнең атасы Әхмәтҗанны аерып чыгарган. Аерылып чыккач, Әхмәтҗан үз алдына сәүдәгә тотынса да, ни өчендер алга китә алмаган. Атасы белән бергә торган Хәкимҗан, Әхмәтҗанның бу хәлен күреп, аны кызганган, вә Гайса карттан аңа файда уртакка мал биреп, Бохарага җибәрүне үтенгән; Гайса күнгән. Әхмәтҗан бер баруда ук, Бохарадан алып килгәне мамыктан бик зур файда иткән дә, яхшы гына сәрмая (сумма) ясаган. Шуннан соң, 1853 нче елда, Бохарага угылы Габделвәлине дә алып барган; Ташкентка да баргалап йөргәннәр.

Шул эшендә Габделвәлинең уяулыгын вә күзе ачыклыгын Хәкимҗан күреп, аны үз култыгына алган вә аңа тагы да зуррак эшләргә катышырга юллар ачкан. Шул рәвешчә, Габделвәли сәүдә эшләренә катышып, җиддиять[2] белән эш күрә башлаганнан соң, Әхмәтҗан яхшы ук дәүләт иясе булып киткән. Ләкин соңыннан, ни өчендер, Әхмәтҗан «сынган», гайрәтле Габделвәли ата дәүләтен яңадан аякка бастырып, хәзерге Яушевлар байлыгына нигез салган.

Балалары эш башкара башлаганнан соң, Әхмәтҗан 1870 нче миладида ахунд Әхмәтхаҗи Рахманколый рәфәкатендә[3] хаҗга барып кайткан; 1875 нче ел февраль 5 ндә 57 яшендә вафат булган.

Әхмәтҗан вафат булгач, сәүдә эшләренең башында тагын да җиддиять белән Габделвәли йөри башлаган; борадәре Садыйк аңа ярдәмче булган; болар Шәриф вә Муллагали белән дүрт агай-эне бергә торганнар вә берлектә эш йөрткәннәр. Эшне дәхи[4] дә ныграк казыкка бәйләр өчен сахибе тәрҗемә үз фирмаларын «Торговый дом под фирмою Габделвәли Әхмәтҗанович Яушев с братьями» (Габделвәли Әхмәтҗан угылы Яушев вә борадәрләренең тиҗарәтханәсе) исемендә ясаган. Ләкин, соңыннан Садыйк болардан аерылып чыккан. Дәхи, Әхмәтҗанның хаҗга китмәстән элек сатып алган Болгари (күн)

---

[1] бинаән галәйһи – шуңа күрә.

[2] җиддиять – тырышып, көч куеп.

[3] рәфәкать – юлдашлык.

[4] дәхи – тагын.

заводын Габделвәли зурайткан вә киңәйткән. 1881 нче елда паровой тегермән торгызганнар.

III

*Сахибе тәрҗемәнең туган тарихы вә йорты – анасы вә бабасы – хатыннары вә балалары – укыган җире вә остазлары, гыйлеме, фикере вә сәүдәгәрлеге – киңәшчеләре (шәех Зәйнулла Рәсүли вә ахунд Рахманколый).*

Сахибе тәрҗемә Габделвәли 1840 нче ел март 12 сендә Троицкида 1 нче мәхәлләдә Су Буе урамында баҗиче (Урта Азиядән килгән малларга тамга сугып торучы) Һибәтулла Хәмзә угылы йортында туган. Бу йорт бу көндә ахунд Әхмәтхаҗи Рахманколый йортыннан ике йорт аша; Һибәтнең кызларының балалары Биктимеревләр кулындадыр. Ул вакыт беренче мәхәлләдә имам булган Зариф бин Габделҗәмил, метрика дәфтәренә сахибе тәрҗемәнең вилядәте[1] хакында болай дип язган: «Атасы лашманчы[2] Әхмәт; анасы Сәгыйдәбану».

Габделвәлинең анасы булган Сәгыйдәбану – Мәхмүд Габдеррәшит угылы Әбүбәкиров кызыдыр. Бу исә Казан өязендәге Сабабаш[3] авылыннандыр.

Сахибе тәрҗемәнең тәүге хатыны Троицкилы Мәүдүдә Хәсән кызыдыр. Моннан Габдерахман вә Хәкимҗан исемле угыллары, Фатиха вә Маһибәдәр атлы кызлары булган. Болардан Хәкимҗан 17–18 яшьләрендә вафат булган; Габдерахман соң көннәрендә Петропавел шәһәрендә торып, шунда үлгән. Моннан, Хәдичә Хәкимҗан кызыннан туган бер угыл калган. Маһибәдәр Троицкида иргә барып Закир исемле бер угыл калдырып вафат булган. Закир, инде өйләнгән, Ташкент шәһәрендә тора. Фатиха Казан сәүдәгәре Сөләйман Аитовка[4] никахланган иде. Бу көндә Фатиха ханым Аитова үзенең атаклы кызлар мәктәбе белән мәгъруфтыр[5]. Сахибе тәрҗемә, Мәүдүдәне 1883 нче ел декабрь 12 сендә талак кылган; ул хәзер Казанда, кызы Фатиха ханым янында торадыр.

Икенче хатыны – Норма[6] авылының Мөхәммәткамал кызы Гайшәдер. Моннан Мөхәммәтгали исемле бер угылы булып, Гайшә бу көндә шуның кулында торадыр.

Өченче хатыны – Әшраф Хәкимҗан бин Гайса кызыдыр. Моннан Мулламөхәммәт, Габделгазиз исемле угыллары, Хәдичә

---

[1] вилядәт – туу, дөньяга килү.

[2] Лашманчы – урман кисүче.

[3] Сабабаш авылы, Саба районында, район үзәгеннән 11 км көнчыгышрак, Мишә елгасының уң кушылдыгы Казкаш суы буенда. Казан ханлыгы дәверендә нигез салына.

[4] Аитов Сөләйман Мөхәммәтҗан улы (1862–1922) – сәүдәгәр, иганәче, Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте әгъзасы (1896).

[5] мәгъруф – танылган, билгеле булган.

[6] Ике Норма авылы билгеле: 1) Балтач районында, район үзәгеннән 4 км көнчыгышрак, Шушма елгасының уң кушылдыгы Норма суы буенда. Казан ханлыгы дәвереннән мәгълүм; 2) Мамадыш районында, район үзәгеннән 24 км көнбатышрак, Омар елгасының сул кушылдыгы Кирмән суы буенда. 17 йөзнең 2 нче яртысында нигез салына.

исемле кызы бардыр. Әшраф бу көндә ошбу угылларының кулында торадыр.

* * *

Габделвәли 2 нче мәхәлләдәге мәдрәсәдә Әхмәт хәзрәт Халид угылы заманында, Верхнеурал өязе Илче авылының Юлмөхәммәт вә Гариф исемле хәлфәләрдән укыган. Татарча укырга, язарга белә иде. Үзе «Дәляил әл-хәйрат шәрхе», «Кәрһ Давыд»ны, «Мөхәммәдия» һәм «Алты бармак» китапларын бик сөеп моталәга[1] итә торган булган. Сәүдәгә бирелеп киткәнлектән, укып гыйлем вә фикер даирәсен[2] киңәйтергә тырышканлыгы беленми. Остаз алдында укуы аз, моталәгасе юк дәрәҗәсендә булса да, ул башлы вә тәдбирле[3] кешеләр җөмләсеннән санала иде. Русча укырга да, язарга да белми; ләкин сәүдәгә тәгаллекълы[4] эшләрдә хаҗәт үтәрлек кадәр сөйләшә белә иде. «Тәрҗеман» газетасын[5] укыганлыгы беленмәсә дә, русча газеталарны укытып, сугыш, политика вә кызыклы вөкугатка даир[6] хәбәрләрне тыңлаштыргалый торган булган.

Исәп-хисапка шәп вә җитез; мәгънәсе илә «сәүдәгәр»; төрле яңа эшләр башларга җәсарәтле[7] булган.

Сахибе тәрҗемә, бәгъзебер үзенә мөшкелрәк күренгән хосусый эшләрендә һәм мәчет-мәдрәсә салдыру, уку вә укытуга ярдәм итү вә шуның кебек җәмәгать эшләрендә ахунд Әхмәтхаҗи Рахманколый[8], дамелла Мөхәммәт Бикмати вә шәех Зәйнулла Рәсүли[9] белән киңәш итә торган булган.

## IV

*Мәчетләр бина вә тәгъмир иттерүе – ысулы җәдидәнең таралуына хезмәтләре – «Мәшәкател мәсабих»[10] бастыруы – мөфти Солтанов[11] белән Петербургка баруы – Троицки халкы арасында тоткан мәукыйгы[12] – хәзерге борадәран Яушевлар фирмасы – сахибе тәрҗемәнең вафаты.*

---

[1] моталәга – уку, өйрәнү.

[2] даирә – кругозор.

[3] тәдбир – эшнең ахырын уйлап эшләү.

[4] сәүдәгә тәгаллекъ лы – сәүдәгә бәйләнешле.

[5] «Тәрҗеман» – сәяси, фәнни һәм әдәби газета. 1883–1918 елларда Бакчасарай шәһәрендә (Кырым) төрки-татар телендә нәшер ителә. Нашире һәм мөхәррире И. Гаспринский (1851–1914).

[6] вөкугатка даир – вакыйгаларга караган.

[7] җәсарәтле – батыр, кыю.

[8] Рахманкулов Әхмәдһади Габделзакир улы (1837–1921), шәех, ахун (1890 елдан), Троицкий 1 нче мәчетенең имам-хатыйбы.

[9] Рәсүли (Рәсүлев) Зәйнулла (Зәйнулла ишан) (1833–1917) – мөдәррис, ишан, Россиядә иң абруйлы мөселман руханиларының берсе.

[10] «Мәшәкател мәсабих» – русча тәрҗемә иткәндә «Трудности просвещения» исемле китап.

[11] Солтанов Мөхәммәдьяр Мөхәммәтшәриф улы (1836–1915) 1886–1915 елларда мөфти булып тора.

[12] Мәукыйгы – урыны.

Сахибе тәрҗемә үз халкыбызга мал белән изгелек иткән кешеләр җөмләсеннәндер. Ул Казан губернасында, Троицки вә әтрафында байтак яңа мәчетләр салдырган вә бәгъзе берәүләрен тәгъмир иттергән. Троицки өязе Звериноголовский вә Борхан авылы мәчетләре һәм олуг вә мәһабәт[1] Кустанай мәчете, башлыгы сахибе тәрҗемә булган Яушлар тиҗарәтханәсенең яңадан салдырган мәчетләрнең бәгъзеләредер.

Троицкида татар балаларына махсус русский класс ачарга рөхсәт чыгарту вә шул ук шәһәрдә мөселман җәмгыяте хәйриясе тәэсис итү[2] хакында бик зур хезмәт вә иҗтиһадлар[3] иткән вә бу ике файдалы мөәссәсә[4] мәйданга чыгарылган.

Сахибе тәрҗемәнең иң зур хезмәте – Троицки вә әтрафында ысулы җәдидә белән тәгълимнең таралуына мал белән ярдәм итүедер. Бу якларда моның интишарына[5] аның зур һиммәтләре[6] булган. Ысулы җәдидәнең мәйданга чыгуына вә халкыбыз арасында таралуына үзебездән берничә каләм ияләре, берничә мулла вә мөгаллим, вә берничә байларның хезмәт вә һиммәтләре сәбакать[7] иткәнлеге мәгълүмдер. Менә Габделвәли Яушев та шундый байларның берседер. Минем карашымда, аның бу хезмәте мәчетләр салдыру вә төзәттерүеннән әллә ничә кат мөһим вә олугтыр. Бездә мәчет салдыручы, мәчет төзәттерүче, хиҗаз фәкыйрьләренә[8] садакалар җибәрүче, «Сагълам» теләнчеләрен капка төбенә җыеп зәкят өләшүче вә бәдәл[9] хаҗ белән васыять итүче байлар бик күп булганнар. Боларның «изгелекләре» гел бертөрле булганлыктан, вә милләтебезнең хәяте вә бәкасы[10] өчен бер тиенлек ярдәм итәчәк эшләр булмаганлыктан, халкыбызда һичбер төрле яхшы әсәр күрсәтә алмаганнар гына түгел, бәлки кайберләре начар әсәрләр күрсәткәннәр. Милләтләрнең хәят вә бәкасында ибтидаи[11] мәктәпләрнең нинди мөһим урын ишгаль[12] итүләре, иске мәктәпләребезнең ни дәрәҗәдә черек вә әсассыз булулары, ысулы җәдидә аркасында ибтидаи мәктәпләребезнең күзгә күренерлек рәвештә юлга салынулары вә яңа һәм файдалы юньгә китүләре бәсыйрәт[13] ияләренә ачык мәгълүм булгач, Гәбделвәли байның ибтидаи мәктәпләрнең төзелүе юлында иткән хезмәт вә

---

1 мәһабәт – зур, шәп.
2 тәэсис итү – оештыру.
3 иҗтиһад – тырышлык.
4 мөәссәсә – оешма, җәмгыять.
5 интишар – таралу.
6 һиммәт – тырышлык.
7 сәбакать – беренчелек.
8 Хиҗаз фәкыйрьләре – мохтаҗлар.
9 бәдәл – алмаштырырга яраклы.
10 бәка – мәңгелек.
11 ибтидаи – башлангыч.
12 ишгаль – берәр төрле эш белән шөгыльләнү.
13 бәсыйрәт – аңлылык, алдан күрүчәнлек.

ярдәмнәрен ничек мөһим вә олуг санамаска кирәк?

Ысулы җәдидәнең гамәлгә куелуы вә таралуына мал белән хезмәт иткән кешеләр сафка тезелгән тәкъдирдә Әхмәт бай Хөсәеневнең имам урынын тотачагында шөбһә юк. Ләкин Габделвәли дә бу сафның мөһим күрекле бер урынын ишгаль итәчәгендә шөбһәләнергә ярамый. Ысулы җәдидәнең тарихын язучылар моны онытмасыннар!

Ысулы җәдидә мәктәпләренә Габделвәлинең кесәсеннән берничә меңнәр сарыф кылыну өстенә, ул вә ярдәмчеләре үз файдасын үзе белмәгән татарларга вә кирегә беткән бәгъзе муллаларга «яңача укытуны» кабул иттерү юлында да күп мәшәкать вә михнәтләр күргәннәр.

Ахунд Рахманколый хәзрәтләре башлап ысулы җәдидәне гамәлгә кую нияте белән үз хәлфәләреннән Мөхәммәтзакир Ваһаповны (бу көндә Җидесу вилаятендә Тукмак[1] шәһәрендә тора) ысулы тәгълим[2] күрер өчен Истанбулга[3] җибәргәндә аңа кирәк булган мәсарифның[4] зур бер өлешен Габделвәли биргән. Ул кайтып, берничә ысулы җәдидә мәктәбен ачып укыта башлагач, сахибе тәрҗемә беренче мәхәллә хозурындагы шул мәктәпнең мөгаллимнәренә айга 50 сум мәгаш[5] бирә башлаган. Троицкиның башка мәхәлләләрендә дә ысулы җәдидә мәктәпләре ачылып укытулар башланганнан соң, ул мәктәпләрнең мөгаллимнәренә дә мәгаш бирергә керешкән; хәтта Троицки вә Чиләбе өязендәге бәгъзебер авылларда да мәктәпләр ачтырып мәгашләр биргәләгән. Бу рәвешчә мәктәпләргә ярдәм итүе үзе үлгәнче дәвам иткән.

* * *

«Мәшәкател» бастыруы – 1892–93 нче елларда мөселманнарның дини китапларын бастыруны тыю хакында чиктән тыш инсафсызлыклар башлангач, Русия мөселманнары арасында күңелсезлек, хәфа вә хәфалану булдыгы мәгъруфтыр. Менә бу хәл, мөселманнарның күп торган шәһәрләрнең берсе булган Троицкида да күрелгән. Шушы эш хакында тиешле урыннарга мөрәҗәгать итәр өчен делегатлар сайлап пайтәхеткә[6] җибәрү фикерен сахибе тәрҗемә кузгаткан. Бәс, ахунд Әхмәтхаҗи Рахманколый белән Мулламөхәммәт Бикмати Троицки мөселманнарыннан вәкил сыйфаты илә чыгып киткәннәр, китешли Уфага кереп, Әбүсогуд мирза Әхтәмевне[7] алганнар да Петербургка юнәл-

[1] Тукмак шәһәре Җидесу (Семиречье) өлкәсендә, хәзерге вакытта Кыргызстан Республикасына керә.

[2] тәгълим – белем алу.

[3] Истанбул – Госманлы дәүләтенең башкаласы.

[4] мәсариф – тотылган акча, чыгым.

[5] мәгаш – эш хакы.

[6] пайтәхет – башкала.

[7] Әхтәмев Әбүсогуд Габделхаликъ улы (1843–1918 дән соң), хокук белгече, эре җирбиләүче, «Иттифакъ әл-мөслимин» партисен оештыручыларның берсе. 1 нче Дәүләт Думасы депутаты (1906). Бөтенроссия мөселманнарының беренче съездын оештыручыларның берсе.

гәннәр. Шул чорда пайтәхеткә башка шәһәр мөселманнарының вәкилләре дә килгәннәр икән. Ахунд Рахманколыйның сөйләвенә караганда: мөселманнарның шулай аһ-ваһ итеп йөргәннәре заманнарында Петербург ахундының теге вәкилләр белән шаярулары, назлану (каприз)лары, атлаган саен алтын шыңгырдавына колак салуы тарихыбызга язылганда хәлфәләребезне бер җәһәттән[1] көлдерерлек вә бер җәһәттән елатырлык хәлләрдер.

امور تضحك السفهاء منه و يبكي
من عواقبها اللبي[2]

Матбагачы Бораганский[3] ахунд Рахманколыйдан басар өчен китап сораган. Ахунд үз иптәше Мулламөхәммәт хәзрәт белән «Мәшәкател мосабих»ны тәкъдим иткәннәр. Хәлбуки аннан элек шул хәлендә бу китапны басарга рөхсәт бирелмәгән икән. Ләкин бу юлы, бер яктан, Бораганскийның ялварулары вә, бер яктан, Троицки вәкилләренең кулларыннан килгән тәдбирләрдә[4] кимчелек итмәүләре таш бәгырьләрне йомшаткан вә «Мәшәкател»не басарга рөхсәт бирелгән. Шушы «Мәшәкател», сахибе тәрҗемәнең хәраҗаты[5] белән басылган. 1000 нөсхә басканнар, 6000 сум акча тотылган. Китап бик нәфис вә мөкәммәл[6] рәвештә басылган ки, өстенә карап кинәнеп торырлыктыр.

Ошбу «Мәшәкател мосабих» нөсхәсенең[7] баш ягына «Рөхсәт литабигъ Санкт-Петербург фи маһ[8] сентябрь 13, сәнәт мәсихият[9] 1893; фи маһ рабигыл әүвәл 3, сәнәт хиҗрия 1311. Фи әл-матбагъ әл-Ильяс мирза Борагани әл-Кырыми фи Санкт-Петербург» дип басылган. Әмма соңгы битендә:

" فقد انطبع هذا الكتاب الشريف
بسعي.........
بلدة الترويسكي أحدهما سمي حبيب الله
على مابشر به روح الله على مانطق به القرآن
الحكيم [10] وثانيهما أيضا سمي حبيب الله على
ماجاء في مواضيع من تنزيل العزيز الرحيم
[11] وكان هذا الكتاب الشريف من السابيقين
في بلاد الهند مطبوعا ولم يكن في هذا الديار
مطبوعا . فشمر العزيزان المذكوران النبيل
باهتمامهما في طبعه وتمثيله في الدولة
الروسية فتيسر هذه المشكواة الشريف كاملا
مرغوبا مطبوعا في مطبعة الياس ميرزا

---

[1] Бер җәһәттән – бер яктан.

[2] Гарәп мәкале: «Шундый эшләр бардыр ки, аларның нәтиҗәләреннән ахмаклар көлер, ә зирәк акыл ияләре еглар», гадиләштергән варианты: «Ахмак көлгән нәрсәдән акыллы елар».

[3] Ильяс мирза Бораганский (1852–1920 еллар азагы), нашир, китап басу остасы, педагог. 1894–1910 елларда Санкт-Петербургта хосусый татар матбагасы тота.

[4] тәдбирләр – тиешле чаралар.

[5] хәраҗат – чыгымнар.

[6] мөкәммәл – тулы, бөтен.

[7] нөсхә – экземпляр.

[8] маһ – ай.

[9] сәнәт мәсихият – хрестиан календаре буенча.

[10] Әхмәтхаҗи ахундны ирадә итә. (Автор искәрмәсе.)

[11] Мөхәммәд хәзрәт Бикматины касд итә. (Автор искәрмәсе.)

البورغاني القريمي في سانكت بيتربورغ سنة
1895 بالميلادية وسنة 1313 بالهجرية [1]

дип басылган; вә шул ук соңгы битендә ахунд хәзрәт Рахманколыйның әйтүенә күрә, цензордан махсус рөхсәт алып, штемпель белән: «Габделвәли Әхмәтҗан угылы Яушевның хәраҗаты белән» гыйбарәте беркетелгән.

1895 нче ел мөфти Солтанов, ахунд Рахманколый белән бергә сахибе тәрҗемә, падишаһыбыз Николай Александр угылының[2] тәхеткә утыруын котлар өчен Петербургка барган вә шушы ике юлдаш белән бәрабәр Кышкы Дворецта патша хозурына кабул ителгән вә аның исеменнән императрицага 10000 (ун мең) сумлык мех һәдия[3] тәкъдим ителгән.

* * *

Габделвәли, Троицкида кирәк татарлар, кирәк урыслар арасында бик мөһим урын тоткан. Шәһәрнең мөһим эш вә мәсьәләләре хакында аның киңәшеннән башка эш кылынмаган. Татарлар, кирәк сәүдә хосусларында, кирәк башка мөһим вә гомуми эшләрдә аңа мөрәҗәгать итеп, киңәшә вә гакыл сорый торган булганнар; аның рәэ[4] вә сүзләре бик мәкъбүл[5] вә могтәбәр[6] тотылган. Хәтта Троицкиның әтрафындагы кешеләр дә аның мәслихәт вә гакылыннан файдаланганнар.

Сахибе тәрҗемәгә садакате вә сәүдә эшләрендәге сәбат[7] вә гайрәте һәм кайбер мал вә мөтәгалләренең мөкәммәл[8] вә шәплеге өчен хөкүмәт тарафыннан берничә медальләр ингам[9] ителгән иде.

Ул үлгән көненә кадәр сәүдә эшләрен «Габделвәли Әхмәтҗан угылы Яушев вә борадәрләренең тиҗарәтханәсе» фирмасы астында карендәшләре Мөхәммәтшәриф вә Муллагали Яушевлар белән бергә йөрткән. Ул үлгәч, 4–5 айдан соң фирманың исемен «Торговый дом братьев Яушевых» («Борадәран Яушевлар тиҗарәтханәсе») исеменә алмаштырганнар. Эшләре көннән-көн зурайган, сәүдә мәйданнары киңәйгән. Бу тиҗарәтханәнең хәзерге әгъзалары Мул-

[1] Ошбу Изге Китап басылды Троицкидагы ике кямил галимнең, ике мөдәрриснең тырышлыгы белән. Аларның берсе Хәбибулла, Аллаһның рухы аны шатландырсын Коръән Кәримдә ул хакта әйтелгәнчә, икенчесе шулай ук Хәбибулла әл-Газиз әр-Рәхимнең Тәнзиленнән килгәнчә. Бу Изге Китап Һиндстанда аннан элек басылган ике китаптандыр һәм дә ул бу илдә һич басылмаган иде. Ошбу искә алынган шәрәфле икәү аны бастырырга һәм Русия илендә аны тәкъдир кылырга ашыктылар һәм дә ошбу әл-Мишкят әш-Шәриф җиңел кылынды кямил вә тиешле сурәттә басылып Илйас-мирза әл-бургани әл-Кәрими матбагасында Санкт-Петербургта 1895 елда миладича һәм 1313 елда һиҗри белән.

[2] Романов Николай Александрович (1868–1918) Россия империясенең падишаһы.

[3] һәдия – бүләк.

[4] рәэ – фикере, карашы.

[5] мәкъбүл – кабул ителгән.

[6] могтәбәр – игътибарлы, хөрмәтле.

[7] сәбат – фикердә, эштә нык торучанлык.

[8] мөкәммәл – тәмамланган, тулылаштырылган.

[9] ингам – сыйлау, яхшылык итү.

лагали Әхмәтҗан угылы Яушев (фирманың патроны), Габделвәлинең ике угылы: Мулламөхәммәт вә Габделгазиз һәм Мөхәммәтшәриф угылы Латыйф Яушевлардыр. Бу фирма хәзер дә ма вараэ Уралдагы[1] фирмаларның иң дәүләтле, могтәбәр, төпле вә ышанычлыларыннан саналадыр. Сәүдәләре һаман көчәя вә табышлары арта барадыр. Дин вә милләт өчен изгелекләре дә юк түгел. Габделвәлинең балалары истикамәтле[2] вә үз эшләрен башкаручы кешеләрдер.

* * *

Сахибе тәрҗемә Габделвәли Яушев 1906 нчы миладида сентябрьнең 13 ндә иртә белән сәгать дүрттә вафат булган. Яше 67 эчендә иде.

Мәрхүм үлгәндә гомум милләт файдасы өчен зур васыятьләр итәргә муаффәкъ була алмаган[3]. Ләкин үзенең хәятендә иткән изгелекләре дә исемен яхшылык белән сагындырырга җитәрлектер. Аллаһу Тәгалә үзенең ризасына мәзъһәр итсен[4]!

**Искәрмәләрне әзерләүдә кулланылган әдәбият**


*Азаматов Д.Д.* Из истории мусульманской благотворительности. Вакуфы на территории европейской части России и Сибири в конце XIX – начале XX вв. Уфа, 2000. С. 52.

*Гизатуллин Р.Н.* Яушевы // Энциклопедия Челябинской области. Челябинск, 2008. С. 588–589.

*Денисов Д.Н, Старостин А.Н., Гизатуллин Р.Н.* Яушевы // 3.Ислам на Урале. Энциклопедический словарь. Москва; Нижний Новгород, 2009. С. 415–418.

*Мустафина Д.* Служилые мурзы Яушевы в XVI–XVII вв. // Гасырлар авазы (Эхо веков). 2004. № 1. С. 32.

Яушевлар // Татар энциклопедия сүзлеге. Казан, 2002. Б. 815.


*Текстны гарәп имласыннан кирилл алфавитына күчерделәр,*
*сүзлекне һәм аңлатмалары әзерләделәр:*
*Казан Федераль университетының Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни*
*китапханә хезмәткәрләре:* ***Шәрәфиева Рәисә Гамир кызы***
*һәм* ***Әл-Хамад Илфира Арслан кызы.***
*Гарәпчәдән тәрҗемәне эшләргә ярдәм иттеләр:*
*тарих фәннәре кандидаты* ***Хәйретдинов Айдар Гарәфетдин улы***
*һәм* ***Гәрәева Нурия Габделәхәт кызы.***

[1] Ма вараэ Уралдагы – Уралның аръягы.

[2] истикамәт – турылык, дөрес юнәлеш.

[3] Муаффәкъ була алмаган – булдыра алмаган.

[4] Мәзъһәр итсен – булдырсын.

УДК 821.512.145:821.512.162

*К.М. Миңнуллин*

# ТӨРКИ ӘДӘБИЯТЛАР БАГЛАНЫШЛАРЫ
## (Тукай һәм Сабир иҗатлары мисалында)

В статье рассматривается творчество поэтов Габдуллы Тукая и Сабира в контексте взаимодействия тюркских (татарской и азербайджанской) литератур.

**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, татарская литература начала XX века, Сабир, азербайджанская литература.

Совет дәвере үтеп 1980 еллар ахырыннан илдә демократик үзгәртеп кору башлангач, милли үзаң үсеше, төрки халыкларның милли тәңгәллекләрен кабат торгызу омтылышы, бер яктан, әдәбиятларның милли үзенчәлекләрен мөмкин кадәр тирәнрәк өйрәнү, икенче яктан, аның гомумкешелек, гомумтөрки мәдәниятенең аерылгысыз өлеше булуын тою кирәклеге мәсьәләсен алдыбызга куйды. Бу быел 130 еллык юбилее билгеләп үтелгән бөек шагыйребез Габдулла Тукай мирасын өйрәнү мисалында да ачык сизелә. Әдәбият турындагы фән Тукай иҗатындагы милли үзенчәлекләрне өйрәнүгә никадәр тирәнрәк үтеп керсә, аның әсәрләрендәге гомумтөрки тамырлар шулкадәр ныграк ачыла бара. Шагыйрь иҗатын гомумтөрки әдәбиятлар яссылыгында карарга омтылышның көчәя баруы да шуның белән аңлатыла.

Совет чорында әдәбиятлар арасындагы багланышлар, шул исәптән төрки телле әдәбиятларның үзара мөнәсәбәтләре дә, бер генә яклы аңлатылып килende. Ул рус сүз сәнгатенең башка халыклар әдәбиятына йогынтысы яки алдарак иҗат ителгән әдәби әсәрләрнең соңрак чорларда иҗат мәйданына килгән язучыларга тәэсире итеп каралды.

Әмма әдәбият фәненең үсеше, төрле сәбәпләр нәтиҗәсендә озак вакытлар дәвамында киңкатлам укучылар игътибарыннан читтә кала килгән рухи мирасыбызның кабат кайтарылуы төрки телле әдәбиятларда үзенчәлекле сәнгать күренешләренең, әдәбиятларның үзара тәэсире нәтиҗәсендә генә түгел, ә социомәдәни, милли бергәлекләрнең рухи үсеше буларак яшәвен торган саен ныграк дәлилли. Г. Тукай һәм Сабир иҗатлары мисалында XX гасыр башы татар һәм азәрбайҗан әдәбиятларын чагыштыру да шундый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә.

Һичшиксез, бу чорда Казандагы һәм Бакудагы иҗтимагый-сәяси шартлар бик тә охшаш була: XIX гасырдагы мәгърифәтчелек хәрәкәте, 1905 елгы инкыйлаб дулкынында күз алдына китермәслек мәдәни югарылыкка ирешү әдәбият мәйданында тормышларын да, иҗат-

ларын да үз халыкларын милли яңарышка алып чыгуны максат иткән Г. Тукай, С. Рәмиев, Н. Нариманов, Г. Сабир кебек бер төркем фикер ияләрен тудыра. Әлеге иҗтимагый-мәдәни хәрәкәтнең үзәгендә кайнаган башка бик күп зыялыларыбызның исемнәрен дә атап үтәргә мөмкин. Алар укыту, тәрбия бирү, гаилә мөнәсәбәтләре, хатын-кыз һ.б. мәсьәләләргә караган иске тәртипләр һәм карашларны юк итү өчен хәлиткеч көрәш алып баралар. Милләтәшләренең яшәешен үзгәртү өчен көрәш аларның эшчәнлеген генә түгел, ә иҗатларының юнәлешен, идея эчтәлеген дә билгели. Милли яңарыш хәрәкәтенә хезмәт итү татар һәм азәрбайҗан шагыйрләре һәм язучылары алдындагы беренче бурыч булып тора. Шул бурычны үтәргә омтылыш иске, катып калган мөселман тормышына, аерым дин әһелләренең реакцион карашларына, социаль һәм милли изүгә каршы ачыктан-ачык көрәшкә башлангыч биргән сатирик журналлар тууга сәбәп була. «Мелла Насретдин», «Зәнбур» («Шөпшә»), «Уклар», «Карчыга», «Яшен» һәм башка журналлар менә шундыйлардан.

«Мелла Насретдин» журналы азәрбайҗан халкының төп милли трибунасы булып, алдынгы җәмәгатьчелекнең, шул исәптән татарларның да, тиз арада игътибарын үзенә җәлеп итә [Касумов, с. 4]. Журнал җирле материаллар белән генә чикләнмичә, бөтен Россия империясендәге вакыйгалар турында хәбәрләр бастыра, Кавказда, Урта Азиядә, Казахстанда, Идел буенда, Төркиядә, Иранда аеруча танылуга ирешә [Качарли, с. 7]. Журналның күп кенә номерларында, Казан хәбәрчеләре җибәргән, татарлар тормышы турында кыска күзәтүләр, сатирик язмалар, татар кадимчеләренә карикатуралар урнаштырыла. Моннан тыш, Идел һәм Урал буе татарлары азәрбайҗанның «Ени хагигат» («Яңа хакыйкать»), «Иршад» («Юл күрсәтүче»), «Таза хәят» («Яңа тормыш») «Каспий», газеталарын, «Деблетан» («Мәктәп») журналын һ.б. алып укыйлар [Нафигов, Циунчук, с. 75]. Шулай ук «мәнфәгати» дуслык та урнаша: «Әл-ислах» «Мелла Насретдин» язмаларына сылтама белән Босния һәм Герцеговина, Төркиядә һәм Иранда барган вакыйгаларны яктырта яки анда басылганнарны кыскача сөйләп чыга. «Урал» газетасы редакциясе инде 1907 елларда ук үзенең битләрендә Казаннан җибәрелгән шигырьләрне бастырган «Текамюль» газетасы редакциясе белән тыгыз бәйләнештә була һ.б. [Нафигов, с. 103–107].

«Мелла Насретдин» журналын укучылар арасында, аны беренче саныннан ук яздырып алучы, Г. Тукай да була. Әле Җаек шәһәрендә вакытта төшкән бер рәсемендә үк без аның кулына «Мелла Насретдин» журналы тотканлыгын күрәбез.

Ул даими рәвештә бу журнал тирәсенә тупланган азәрбайҗан әдипләре, бигрәк тә, «Сабир» (сабыр) тәхәллүсе белән танылган ялкынлы шагыйрь Галиәкбәр Таһирзадә (1862–1911), шулай ук журналның мөхәррире Җәлил Мәмәдкулизадә иҗатлары белән

кызыксына [Гумматова, с. 155–156]. Г. Тукай үзе дә 1906 елда Җаекта «Уклар» дип исемләнгән татар телендәге беренче сатирик журналны чыгаруда актив катнаша.

Тукай һәм Сабир әдәбиятка мәгърифәтчелек реализмы вәкилләре буларак аяк басалар һәм 1905 елгы инкыйлаби күтәрелеш аларның иҗатын үстерә. Тарихи шартлар яшь шагыйрьләрне тиз арада илне яклап иң куярлык иргә әверелдерә, иҗатларында да кискен күтәрелеш сизелә. Ике шагыйрь дә гыйлемлелек, белем ярдәмендә җәмгыятьтәге шартларны үзгәртеп корып булачагына ышаналар. Азәрбайҗан шагыйренең замандашы Сәет Хөсәен: «Сүз остасы, шагыйрь Сабир үзенең бурычын халыкка хезмәт итүдә, аны уяту өчен көрәштә күрде» [кара: Алмасова], – дип яза.

Шул ук вакытта милли яңарыш хәрәкәтенең җитди йогынтысын кичергән Тукай һәм Сабир иҗатындагы реализм XIX гасырдагы мәгърифәтчелек реализмыннан нык кына аерылып тора. Алардагы мәгрифәтчелек карашлары «халык массаларының иске яшәеш формаларына каршы көрәшергә тиешлеген тану» [Абдуллин, Амирханов, с. 50] белән тыгыз бәйләнгән. Тиздән алар иҗатында тормышны реалистик сурәтләү арта барып, мәгърифәтчелек идеаллары миллилеккә урын бирәләр, иске феодаль һәм урта гасырлардан килгән гадәтләрне тәнкыйтьләү яшәп килгән тәртипләргә кискен каршы чыгу белән кушыла. Бу Тукай һәм Сабир иҗатындагы иҗади методларның да үзгәрешен тудыра: 1906 елның икенче яртысыннан мәгърифәтчелек реализмы әкеренләп тәнкыйди реализмга юнәлеш тота. Азәрбайҗан әдәбияты белгече Я. Кариев: «Сабирның журналга килүе белән (“Мелла Насретдин”. – *К.М.*) тәнкыйди реализм үзәне тулыша. Ярның аерым урыннарында яңа төр реализмның “чикләре” күренә» [Караев, с. 265], – дип яза. Ике шагыйрьнең дә реализмы ачыктан-ачык социаль характерга ия.

Билгеле, һәр ике шагыйрьнең дә үз юлы, үзенең поэтик жанры бар. Сатира Сабир иҗатының иң төп җанры булып тора. Әмма алар сайлаган бу юлны бары шигърияттәге язмыш дип кенә дә атап булмый. XX гасыр башында Россиядә, аның үзәктән читтә булган өлкәләрендә, өлешчә Бакуда да, халыкның ризасызлыгы әлегә кадәр күрелмәгән чиккә җитә. Сәяси вакыйгалар йогынтысы, бигрәк тә Бакудагы декабрь стачкасы тәэсирендә азәрбайҗан авыллары кузгала. Шулар Сабирны сатирик әсәрләр язарга рухландыра, аның шигърияте иреккә, мәгърифәтле булырга өнди, хатын-кыз азатлыгын яклап чыга [Алмасова].

Башка халыклардан артта калган, кара наданлыкта, фанатизмда яшәүче милләт образы Сабир шигырьләренең күпчелегендә чагылыш таба. А. Гаджиев фикеренчә, аның мондый әсәрләре «Йокыга талган патшалык» сатирик шигырьләр циклын тудыра. «Бу М.Ф. Ахундовта да, Н. Вәзировта да, Н. Наримановта да булмады. Йоклаган милләт

образы “Мелла Насретдин” журналында барлыкка килде, аның төп поэтик иҗатчысы Сабир булды» [Гаджиев, с. 161], – дип яза ул. Еллар үтү белән, татар әдәбиятындагы кебек үк, бу образ азәрбайҗан әдәбиятының да яңарыш хәрәкәте шигаре булып әверелә. Әмма тарихи-мәдәни хәрәкәт, мохит уртаклыгы, ике халыкның матбугат органнары арасындагы тыгыз бәйләнешләренә карамастан, бу образның татар һәм азәрбайҗан әдәбиятларында барлыкка килүе тышкы тәэсир нәтиҗәсендә түгел, ә һәр ике әдәбиятта да нәкъ катлаулы эчке үзгәрешләр нәтиҗәсе буларак туганлыгы дәлилләнә. Сабир иҗатында беренче булып бу образ «Минем ни эшем бар?» (28.04.1906) шигырендә урын ала. Шагыйрь ирония белән:

Тсс! Не шуми! Пусть люди спят.
Я не желаю,
Чтоб спящих подняли, глаза им
раскрывая [Стихи Сабира], –

дип яза.

Лирик герой үзе яшәгән чордагы азәрбайҗан җәмгыятенең хәләтен йокы хәләте дип бәяләп, «Минем туган халкымны әйдә таласыннар – анда минем ни эшем бар?» – дигән гыйбарәне берничә тапкыр кабатлый. Бу гыйбарәне ике мәгънәдә – матди байлыкларны һәм рухи көчне югалту буларак аңларга мөмкин. «Йоклап ятучы җәмгыять» үзенең асыл кыйммәтләрен ничек юк итүләрен аңламый да кала.

«Киләчәк өчен хезмәт ит» (25.08.1906) шигырендә йокы хәләте эшлексезлек, кәеф-сафа корып яшәү, наданлык, хокуксызлык буларак аңлашыла. Лирик герой үз халкына мөрәҗәгать итеп кат-кат сорый:

Народ мой, будешь в крепкий сон
ты погружен – доколе?
Постельных радостей искать,
считать ворон – доколе?
На эту спячку, праздность, лень ты
обречен – доколе?
Ислам в невежестве погряз, мир
ослеплен – доколе?
Терпеть убогость, темноту, и плач,
и стон – доколе?
Народ забит и угнетен, бесправен
он – доколе? [Стихи Сабира]

Күргәнебезчә, шигырь драматик һәм трагик яңгыраш алган. Йокы азәрбайҗан җәмгыяте яшәешенең барлык өлкәләрендә дә артта калганлыгын тәнкыйтьли. Шул ук идея 1906 елның 11 августында язылган исемсез шигырендә дә ачык сизелә:

Темнота кругом, дитя, ляг, усни
ты, не проснись,
Сон неведенья от глаз не гони ты,
не проснись!
Бай-бай, малыш, бай-бай,
Так всё проспишь, бай-бай!

(…) Ах, открыв глаза, вокруг лишь
беду увидишь ты,
У народа скорбь одну и нужду
увидишь ты,
Горя, зла, страданий, мук череду
увидишь ты.
Под подушку – головой! В эти дни
ты не проснись!
Бай-бай, малыш, бай-бай,
Так всё проспишь, бай-бай!

Шул рәвешчә, Сабир иҗатындагы йокы һәм йокыга талган патшалык образлары чынбарлыкка ироник бәя бирү өчен

кулланыла, әлеге образлар катнашкан барлык текстларда да диярлек үз халкын «уятырга теләге булмаган» милләттәшләрен тәнкыйтьләү, көлкегә калдыру сизелә. Метафоралаштыру алымы структура тудырырга ярдәм итсә, ирония «үз-үзеңне фаш итү» нәтиҗәсендә барлыкка килә.

Шул ук образ башка статуста Г. Тукай иҗатында да (шулай ук С. Рәмиев, М. Гафури, Н. Думави иҗатларында да) калкып чыга. Монда инде ирония генә түгел, үтергеч сатирага өстенлек бирелә, мәгънә тудыру алымы да – символлаштыру. 1906 елның 17 апрелендә Г. Тукайның «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» мәкаләсе басыла. Ул анда башка халыклар үсешкә омтылганда аңын югалтып, сабый йокысына талган милләт сурәтен тудыра. Милләткә аның үз халәтен чагылдырган әдәбият, вакытлы матбугат, музыка, берләшү идеяләре («иттифак сулары») аңына килергә ярдәм итәр дип ышана. Сатира турыдан-туры бәяләү һәм детальләштерү ярдәмендә туа.

Г. Тукай С. Рәмиевнең «Уку» шигыренә охшатып язылган «Йокы» (1908 ) шигырендә:

Безне адәм иткән йокы,
Адәмне алга илткән йокы,
Илтеп күккә җиткән йокы, –
Йокы, йокы, йокы –
[Тукай, б. 264],

дип белдерә.

Әлеге шигырьгә бирелгән шәрехләүдә: «Йокы шундый яхшы эш булса, татарлар күптән алга киткән булырлар иде», – дип искәртә. Бу сүзләр Сабир иҗаты белән аваздаш. Әмма С. Рәмиев шигыре белән интертекстуаль бәйләнеш Тукайга ике төшенчәне – йокы һәм уку төшенчәләрен капма-каршы куярга мөмкинлек бирә, икенчесе аша беренчесе детальләштерелә, нәтиҗәдә образ символик мәгнәгә ия була.

Бер елга алдарак язылып, Тукай тарафыннан «татар маршы» дип аталган «Тартар кошы сайрый» шигыре «татарның йокыдан уянуы»на мөнәсәбәтле шатлык, өмет хисләре белән сугарылган:

Уйкудан тиз тора татар;
Тора! Тора! Тора татар;
Баш күтәргән бар татар!
[Тукай, б. 156]

Тиздән татар шигъриятендә (Н. Думави «Йоклыйлар» (1906), «Караңгылык каплап тора татарны» (1906), С. Рәмиев «Бел телен, эзлә юлын» (1906), «Таң вакыты» (1908), З. Бурнашева «Туар әле кояшлы көн» һ.б.), публицистикасында, хәтта лиро-эпик жанрда да (Ф. Әмирханның «Шәрык йоклый» нәсере) йокы образы ныгып китә. Һәр текстта йокы образын символлаштыру чагылыш таба. Шулай итеп татар әдәбиятында йокы образы әйдәп баручы лейтмотивка әверелә Аның аша иҗтимагый-сәяси тормышка битарафлык, караңгы яшәештән канәгать булып алгарышка омтылмый көн күрү тәнкыйть ителә. Татар язучылары җәмгыятьне уяныргa, алдынгы илләрдән, халыклардан үрнәк алырга чакыралар. «Уяныргa», димәк, алгарыш, азатлык юлына аяк басарга, ул – яңарышка хәрәкәт символы. Әлеге мисаллар ярдәмендә

генә дә XX гасыр башында төрки халыклар әдәбиятында бер-берсенә бәйсез рәвештә милли яңарыш символына әверелгән көрәнешләр, ишарә образлар һәм мотивларның үзара керешкәнлеген күрәбез. Бу милли бергәлекләрдә социомәдәни процесслар гына түгел, милли әдәбиятларның үсеш юлы да охшаш булганлыгы ачык аңлашыла. Мондый нәтиҗә тагын бер кат төрки халыкларның әдәбиятлары арасындагы багланышларны өйрәнүгә яңача якын килү мәсьәләсен хәл итү кирәклеген күрсәтә.

**Әдәбият**

*Абдуллин Я.Г., Амирханов Р.К.* Развитие общественно-политических взглядов Тукая // Габдулла Тукай. Материалы научной конференции и юбилейных торжеств, посвященных 80-летию со дня рождения поэта. Казань: Татар. кн. изд-во, 1979.

*Алмасова Э.* «Призван я быть поэтом. Стих – честный голос мой» // Азербайджанские известия. 2012. 19 мая.

*Гаджиев А.* Азербайджанский реализм. Баку: Язычы, 1983.

*Гумматова Х.* Габдулла Тукай и «Молла Насреддин» // Габдулла Тукай и тюркский мир: материалы международной конференции, посвященной 130-летию со дня рождения Г. Тукая. Казань: ИЯЛИ, 2016. С. 155–156.

*Караев Я.* Этапы азербайджанского реализма. Баку: Язычы, 1983.

*Касумов М.Х.* Боевой революционно-сатирический журнал «Молла Насреддин» и его общественно-политическое направление (1906–1931 гг.). Баку: Изд-во АН АзССР, 1966.

*Качарли Ф.К.* Революционно-демократическая мысль в Азербайджане и Нариман Нариманов. Баку: Изд-во АН АзССР, 1966.

*Нафигов Р., Циунчук А.* В борьбе против царизма и буржуазного национализма / Из истории революционно демократических и марксистских кружков в Поволжье. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1983. С. 75.

*Нафигов Р.* Тайны революционного подполья. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1981. С. 103–107.

Стихи Сабира // portal21.ru›news/we_recommend.php…: карау вакыты: 07.04.2016 г.

*Тукай Габдулла.* Әсәрләр. Академик басма. Алты томда. Т. 1: Шигъри әсәрләр (1904–1908). Казань: Татар. кит. нәшр, 2011.

***Миңнуллин Ким Мөгаллим улы,***
*филология фәннәре докторы, профессор,*
*Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы,*
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры*

УДК 821.512.145

*Юлай Шамилоглу*

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ҮЗАҢЫ: чит илдән бер караш

В статье рассматривается творчество Габдуллы Тукая в плане отражения в нем становления и развития татарской национальной идентичности.

**Ключевые слова:** Габдулла Тукай, татарская литература начала XX века, татарская национальная идентичность.

## Кереш

Габдулла Тукай (1886–1913) – татар халкының бөек даһие, исән чагында ук танылган һәм вафат булгач та татарлар гына түгел, ә бөтен төрки дөньядагы язучылар тарафыннан остаз саналган. Үткән заманнарның бер генә шәхесе дә аның кебек хөрмәт күрмәгәндер, мөгаен. Шул сәбәптән һәм тууына 130 ел тулу уңаеннан Габдулла Тукайның татар үзаңы өчен әһәмияте турында тюрколог һәм тарихчы күзлегеннән генә түгел, ә Нью-Йоркта туып үскән һәм белем алган Казан татары буларак, татар диаспорасы перспективасыннан, кайбер күзәтүләремне сезгә тәкъдим итәргә булдым[1]. Тукай үзе әйтеп калдырганча, без аны шулай «яд итәбез» – искә төшерәбез.

## 1. Милли күтәрелеш фонында Тукай

Габдулла Тукай – татар үзаңы оеша башлаган чорда яшәгән һәм шушы хәрәкәткә җитди йогынты ясаган шәхес. Яңа заманга кадәр кешеләр үз-үзләрен дине, туган һәм яшәгән урыны яисә кабиләсенә карап таныганнар. Татар халкының килеп чыгуы турындагы хәзерге фәнни концепцияне мин Шиһабетдин Мәрҗанинең (1818–1889) хезмәтләре, аның алга таба шушы юнәлештә эзләнүләргә маяк булган һәм татарларның (яисә башка төрки халыкларның) беренче милли тарихын тәкъдим иткән әсәре «Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» белән бәйлим[2]. Башкача әйткәндә, элек татарлар үзләрен мөселман дип санаганнар. XVIII гасырның ахырында болгарчылык идеологиясе күтәрелә башлаган. Бу да хәзерге замандагы милли үзаң белән түгел, ә мөселманлык белән бәйле булган. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында Шиһабетдин Мәрҗани нигезләгән милли үзаң тәгълиматы популярлаша башлый[3]. Бу хәрәкәткә Исмәгыйль Гаспралының Рәсәй империясендәге һәм аннан тышта яшәүче төрки мөселманнар өчен уртак тел һәм үзаң булдыруга һәм мөселманнар арасында бердәмлек оештыруга юнәлтелгән эшләре рух бирә (Рәсәй империясендә бу фикерләрне мәсхәрәле рәвештә «панисламизм» һәм «пантюр-

кизм» дип атадылар). XX гасырның башында пантюркизм идеологиясенең күтәрелүенә Госманлы төрек теленең һәм мәдәниятенең активлашуы да, Исмәгыйль Гаспралының Урта Идел буенда Госманлы төрек телендәге язмаларының да йогынтысы булгандыр. Моннан тыш, XX гасыр башында «төрек» һәм «татар» үзаңы бер-берсе белән көрәшү хәленә килде[4]. Бу көрәшнең тел, идеология һәм үзаң яссылыгында чагылышларын без Тукай әсәрләрендә дә күрә алабыз.

## 2. Тукай кулланган «*милләт*» төшенчәсе нәрсә аңлата иде?

1453 елда «Яулап алучы» Солтан Мәхмәт II тарафыннан Константинополь алынганнан соң (төрек телендә «Фәтех»), кайбер мөселман булмаган этно-конфессиональ төркемнәр милләт буларак үзбилгеләнә. XIX гасырга кадәр милләт төшенчәсенең эчтәлеге үзгәрешсез кала, әмма билгеле бер вакытта «милләт», «милли», «милләтчелек» һ.б. сүзләр бүгенге мәгънәләрендә кулланыла башлый. Бу урында мин уртак исемгә, уртак тарихка ия, психологик бердәмлек хисе уянган һәм мөкатдәс туган җир туфрагына бәйле этнонимны күздә тотам. Минем фикеремчә, бу төшенчәләрне татарларга Шиһабетдин Мәрҗани кертә һәм аның Ризаэтдин Фәхретдин кебек шәкертләре камилләштерә.

Тукайның милләтне аңлавы нәрсәдән гыйбарәт иде: Яңа заманга кадәр булган дини мәгънәдәме (ягъни күп кенә галимнәр тарафыннан кулланылган «мөселман милләте»ме), әллә хәзерге милли җәмгыять мәгънәсендәме? Бу сорауга минем төгәл җавабым юк.

Тукайның «Милләтә» исемле шигырендә (1906) [т. 1, б. 114] милләткә мәхәббәт дигәндә милләт исеме астында кемнәр күздә тотыла? Биредә дини җәмгыять, этник җәмгыять яисә хәзерге аңлаешта милләт турында сүз баруны дәлилләрлек билгеләр юк. Мисал өчен, шигырьнең әлеге сүзне кулланган кайбер юлларына күз салыйк:

*Җөмлә фикрем кичә-көндез сезгә гаид, милләтем;*
*Сыйххәтеңдер сыйххәтем һәм гыйлләтеңдер гыйлләтем,*

*Сән мөкаддәс, мөхтәрәм гыйндемдә варлык нәрсәдән;*
*Сатмазым бу кяинатә милләтем, миллиятем..*
*[...]*
*Ләфзы «милли»и сәвәр кальбем бәнем, билмәм, нәдән?*
*Әйлә «милли», милләтем, бәхшәйлә мәмнүниятем.*

*Һәр хыялдан татлыдыр милләт хыялы, ля мөхаль;*
*Бу хыялятдән кәлүр, гәр кәлсә мәҗнүниятем.*
*[...]*
*Бер заман яд әйләсә билилтифат милләт бәни, —*
*Иштә будыр максадым, мәэмүл вә мәсгудиятем.*

*Әйләдем гарзы мәхәббәт бән сәңа, и милләтем;*
*Дуст күрерсең сән бәни дә – вар буңа әмниятем.*

Бу шигырьдә халыкка карата булган хисләр, дәрт һәм мәхәббәт турында сүз бара, әмма халык милләт белән тәңгәлләштерелми. Монда башка, әйтик, «*татар*» атамасына яки туган җиргә сылтамалар да юк. Аларның булмавы, бәлки, милли үзаңның формалашып кына килүе, башка «үзаңнар» арасыннан арынып чыга башлавы турында сөйлиләр дә.

Бу чорга караган тагын ике шигырьгә тукталыйк. «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр» (1907) [т. 1, б. 130–135] шигыренең 16 нчы һәм 17 нче юлларындагы «*милләт*» һәм «*татар*» сүзләрен Тукай тигезләштерергә тырыша кебек тоела, ләкин, гомумән, «*татар*» сүзенә еш мөрәҗәгать итми. «Туган җиремә» (1907) [т. 1, б. 183] шигырендә туган төбәге Казан артына мәдхия укый. Әмма туган җир табигатен романтик тасвирлау «татар халкының туган җире» төшенчәсенә тәңгәл түгел. «Милләтчеләр» (1907) [т. 1, б. 299–300] шигырендә шагыйрь татар халкы, аның фаҗигале язмышы турында яза. Тексттагы үзләрен «*милләтчеләр*» дип атаучы кешеләр – эшсез мәдрәсә шәкертләре. Минемчә, монда кулланылган «*милләт*» сүзе татар милләте төшенчәсенә түгел, бәлки «*өммәт*» төшенчәсенә якынрак булып чыга.

### 3. Тукай һәм ислам

Тукайның күп кенә шигырьләре теге яки бу күләмдә дини мәсьәләләргә кагыла. «Туган тел» (1909) [т. 2, б. 65] шигырендә доганы кадерләсә дә, еш кына исламның төрле яшәү формаларына дошмани мөнәсәбәте күзгә ташлана. «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр» (1907) [т. 1, б. 130–135, 6 нчы юл] шигырендә шәкертләрнең әхлактан ваз кичүләре Иблистән дә артыграк дип бәяләнә. «Бер шәехнең мөнәҗәте» (1908) [т. 1, б. 206] шигырендә суфи шәехләре, Аллаһка зикер әйтү урынына, «казы, кузы, яшь кенә кыз, каз, кымыз» дияләр, дип мәсхәрәли. «Ишан кәрамәте» (1906) [т. 3, б. 156] шигырендә туймас тамаклар образы да шундыйлардан. «Ишан» (1909) [т. 2, б. 19] шигырендә *ишан* (нәкшбәндия шәехе төшенчәсе) «*хайван*»дыр, ә «Муллалар» (1909) [т. 2, б. 19] шигырендә исә *муллалар* «*хайваннар*»дыр. «Ысулы кадимче» (1908) [т. 1, б. 241–244] шигырендә кадими шәкертләргә һөҗүм итә. Ә «Хиссияте миллия» (1906) [т. 3, б. 185–188] шигырендә Бохарадан кайтучы шәкертләрне ишәкләр дип атый[5]. Җәдитчеләр дә аның тәнкыйть угыннан котыла алмый, «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» (1908) [т. 1, б. 260–278, II, б. 265] әсәрендә аларны беравыздан *кяфер* дип бәяли. Ислам дине институтларына тискәре мөнәсәбәттә булуына карамастан, «Шиһаб хәзрәт» (1913) [т. 2, б. 259–260] шигырендә татарлар арасында мәгърифәткә беренче адым ясаучы *милләт* өчен кадерле дин галиме һәм тарихчы Шиһабетдин Мәрҗанигә соклануын һәм ихтирамын белдерә. Бу шигырдә Тукайның, «Милләтче» (1909) [т. 4, б. 102–103] шигырендәге кебек үк, *милләтне* татар белән бертигез күрүен фаразлый алабыз.

## 4. Төрки дөньяда Тукай

Тукайның төрки дөнья белән мөнәсәбәтләре дә шактый катлаулы булган. Аның күп кенә әсәрләрендә Госманлы Төркиясенә уңай сылтамалар табарга мөмкин («Мин шушылар илә милләтче» (1908) [т. 4, б. 76], һ.б.). Шуңа да карамастан, «Хиссияте миллия» (1906) [т. 3, б. 185–188] язмасында Истанбулдан кайтучы шәкертләр шпион дип атала. Тукайны бөек мөселман, төрки җәдитче модернист һәм педагог Исмәгыйль Гаспралыга симпатия белдерүчеләрдән дип санарга ярамый, аның әйтүе буенча, Бакчасарайда Гаспралы нәшер иткән «Тәрҗеман» газетасының «татарларга бернинди дә катнашы юк», ул «татарлар уянырга тиеш булганда, аларны ныграк йоклаткан». «Тәрҗеман»ның татарларга галәкасы» (1906) [т. 3, б. 235–236] шигыре – моңа мисал. Тукайны «төрекче» түгел, ә «татарчы» дип атарга кирәк булса да, вафатыннан соң ул бөтен төрки дөньяда мактауларга лаек булды.

## 5. Тукай һәм татар теле

Тукайның башлангыч чор иҗаты теленә Госманлы төрекчәсенең көчле йогынты ясаганлыгы билгеле[6]. Бер үк вакытта «Хиссияте миллия»дә (1906) [т. 3, б. 185–188] шагыйрьнең безнең *милләт* үз Пушкиннарын, Лев Толстойларын һәм Лермонтовларын булдырырга тиеш дигән фикере яңгырый. Тукайның татар әдәби теле үсүгә керткән өлеше бик зур, һәм бу да аны татар халкының йөрәгенә якын булган «татар халкының Пушкины» дәрәҗәсенә күтәрде. 1860 еллардан башлап Каюм Насыйри (1825–1902) тарафыннан әдәби чыгтай төркичәсе нигезендә әдәби татар телен оештыру өчен беренче тырышлыклар күрсәтелә. Әмма алар эстетик һәм эмоциональ яктан Тукайның хезмәтләре белән тиңләшә алмый.

Тукайның әдәби татар телен оештыруга керткән хезмәтен ике юнәлештә карарга мөмкин. Беренчесе, әлбәттә, аның үз әсәрләре. Икенчесе исә татар әдәбиятыннан хрестоматия булдыру омтылышы («Мөкаддимә» (1910) [т. 4, б. 139–144] текстын карагыз[7]). «Яңа кыйраәт» исемле, әдәби әсәрләрдән тупланган хрестоматия турында Тукай түбәндәгеләрне язып калдырган: «Мин һәр никадәр балаларның рухларына азык бирү вә аны тәрбия итүне беренче максуд итеп тотсам да, икенче тарафтан, әдәбиятның мәктәпкә керүе аркасында, аңар гомум милләт тарафыннан әһәмият бирелмәсме вә шул саядә әдәбият Русия мөселманнары арасында тиешле кадәр таралып китмәсме дигән өмидем дә бар иде».

Соңрак, бөтен татар әдәбиятына таянып, шәкертләргә киңрәк мәгълүмат бирү максаты белән «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» китабын тәкъдим итә. Аны Рәсәй империясенең башка җирләрендәге мөселман авторларның бу чорга караган хезмәтләре белән чагыштырырга мөмкин. Алар арасында Мөнәввәр Кариның «Әдәбийа әүвәл» (1910) һәм Садретдин Айнинең «Нәмунәиә әдәбияти таҗик» (Мәскәү, 1926) хезмәтләре[8] бар.

Тукай «безнең туган телебезгә» һәм әдәбиятыбызга [т. 4,

б. 143] мәхәббәт уяту өчен «Туган тел»не (1909) [т. 2, б. 65] «Яңа кыйраәт»кә (һәм «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре»нең баш битенә) урнаштырдык дип яза. Татар халкының йөрәгенә үтеп керерлек итеп татарча язу кабилияте Тукайның ин зур казанышы булуы ачык. Фредерих әйтүе буенча, Тукай гади татар телендә иҗат иткән беренче язучы түгел, ләкин Җ. Вәлидигә сылтама ясап, ул болай ди: «Тукай – татарча иң матур сүзләрне сөйләгән кеше»[9]. Габдулла Тукайның тиз арада татар халкының яраткан шагыйренә әйләнү сере дә шунда ята.

### 6. Телнең милләтчелектәге роле

Татарларда әдәби телне камилләштерү мәсьәләсен элегрәк Европада булган вакыйгалар фонында карарга кирәк. Бу юнәлештәге хезмәтләргә И. Гаспринскийның төрки халыкларның телләрен үзара якынайту тәгълиматы яисә Тукай очрагындагы әдәби татар теленең аерым күтәрелүе дә керә.

Иоганн Готфрид Гердерның «Телнең килеп чыгуы турында»гы трактаты нәшер ителгәннән соң (1772), алманнар үз телләрендә сөйләшүләре белән горурлана башлыйлар һәм XIX гасыр дәвамында аларда ватанпәрвәрлек хисләре арта[10]. Бу күренеш Европаның башка илләрендә дә күзәтелә, күп кенә халыкларның милли идеологиясенең нигез компонентына әверелә. Бу процессларда башлангыч һәм урта белем бирүнең әһәмиятен, җәдитчеләр мәктәпләре очрагындагы кебек, тулысынча бәяләргә кирәк. Тукайның телгә һәм әдәбиятка горурлык һәм мәхәббәт уяту өчен дереслекләр әзерләве дә бу схемага туры килә. XIX гасырда Европада милли хисләрнең артуы белән милли телне килештерү һәм аңа ярдәм итү йөзеннән һәрбер илдә тел җәмгыятьләре корылды. Рәсәйдә боларга охшаш махсус институтлар булдырылмады, Рәсәй империясендә яшәүче мөселман төркиләрнең дә мондый академияләр төзү кебек мөмкинлекләре булмады. Шушы сәбәптән бу эш Тукай кебек аерым шәхесләр җилкәсенә төште.

* * *

26 апрельдә бөтен дөньядагы татар җәмгыятьләре Габдулла Тукайның туган көнен билгеләп үтәргә җыена. Ата-аналар балаларына татарларның милли гимнына әверелгән Тукайның «Туган тел» шигыре сүзләрен өйрәтә. Алар бу җырны үзләренең клубларында җыелганда да, Казанда Бөтендөнья татар конгрессында да җырлыйлардыр. Балалар Тукай шигырьләрен исләрендә тоталар, ә кече яшьтәгеләр исә ата-аналары өйрәткән кыска гына «Гали белән Кәҗә» шигырен (1910) [т. 2, б. 104] укый алалар:

*Безнең Гали бигрәк тату Кәҗә белән,*
*Менә Кәҗә карап тора тәрәзәдән.*

*Гали аны чирәм белән кунак итә,*
*Кәҗә рәхмәт укый – сакалын селкетә.*

Үзләре ата-ана булгач та, алар үз балаларына да шуларны өйрәтәчәк. Менә бу – Тукайның милли үзаң тәрбияләүгә юнәлтелгән чын мирасы.

## Искәрмәләр

[1] Бу кыска гына мәкаләнең максаты Габдулла Тукай турында язылган әдәбиятка күзәтү ясау түгел, Татарстанда язылган хезмәтләрнең күпчелеге белән танышу мөмкинлегем дә юк. Әмма Тукайның һәм аның мирасының дөнья историографиясендә урынын барлаганда, укучыларны Михаэль Фредерихның «Ghabdulla Tuqay (1886–1913). Einhochgelobter Poet im Dienst von tatarischer Nation und swjetischem Sozialismus, Turcological 36» (Wiesbaden: Harrassowitz Verlag, 1998) исемле хезмәтен укырга чакырам. Минем мәкаләдә күтәрелгән милләт, дин, тел һәм башка күп мәсьәләләр турындагы күзәтүләрне төрле яктан шәрехләү өчен дә аңа мөрәҗәгать итү кирәк. Тукай әсәрләрен «Габдулла Тукай. Әсәрләр. Биш томда» (Казан, 1985–1986) китапларыннан алдым. Оригиналь текстларның кайсы томда һәм биттә булуы турындагы сылтамалар мәкаләдә күрсәтелгән.

[2] [Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар], 1–2 кис. (Kazan, 1885–1900). Бу әсәрнең 1897–1900 елларда нәшер ителгән икенче басмасына мөрәҗәгать итү мөмкинлегем булды. Минем «The Formation of a Tatar Historical Consciousness: Şihabäddin Märcani and the Image of the Golden Horde», Central Asian Survey 9:2 (1990, 39–49 б.); һәм «İctihad or Millät? Reflections on Bukhara, Kazan, and the Legacy of Russian Orientalism», Reform Movements and Revolutions in Turkistan: 1900-1924. Studies in Honour of Osman Khoja / Türkistan'da Yenilik Hareketleri ve İhtilaller: 1900–1924. Osman Hoca Anısına İncelemeler, ed. Timur Kocaoğlu (Haarlem: SOTA, 2001, 347–368 б.) исемле мәкаләләремне карагыз.

[3] Минем «We Are Not Tatars! The Invention of a Bulğar Identity», Néptörténet – Nyelvtörténet. A 70 éves Róna-Tas And rásköszöntése, ed. László Károly and Éva Nagy Kincses (Szeged, 2001, 137–153 б.); һәм «Мы не татары! Изобретение булгарского самосознания», Источники и исследования по истории татарского народа: Материалы к учебным курсам в честь юбилея академика АН РТ М.А. Усманова, под ред. Д.М. Усмановой – Д.А. Мустафиной (Казань: Казанский государственный университет, 2006, 360–379 б.) исемле мәкаләләремне карагыз.

[4] Минем «Tatar or a Turk? Competing Identities in the Muslim Turkic World during Late 19th and Early 20th Centuries)», The Turkic Speaking World. 2,000 Years of Art and Culture from Inner Asia to the Balkans, ed. Ergün Çağatay–Doğan Kuban (New York: Prestel, 2006, 232–243 б.) исемле мәкаләмне карагыз.

[5] Минем «İctihad or Millät? Reflections on Bukhara, Kazan, and the Legacy of Russian Orientalism» (351 б.) исемле хезмәтемнән цитата.

[6] Тукай теленең килешүе турында фикер алышу өчен Friederich, *Ghabdulla Tuqay*, 128–136 б. карагыз.

[7] Кызганычка каршы, бу әсәрне куллану мөмкинчелегем булмады.

[8] Adeeb Khalid, The Politics of Muslim Cultural Reform. Jadidism in Central Asia, Comparative Studies on Muslim Societies 27 (Berkeley, 1998, 169 ff.)

[9] Friederich, Ghabdulla Tuqay, 133.

[10] Johann G. Herder. ed.-trans. Marcia Bunge, Against Pure Reason: Writings on Religion, Language, and History(Minneapolis: Augsburg Fortress, 1993); and John Myhill, Language, Religion and National Identity in Europe and the Middle East: A Historical Study, Discourse Approaches to Politics, Society and Culture (Amsterdam: John Benjamins, 2006).

***Юлай Шамилоглу,***
*Висконсин-Мэдисон университеты*

*(Инглизчәдән татарчага Б.Р. Ногманов тәрҗемә итте.)*

УДК 929

***Г.Ф. Гайнуллина, В.Р. Гафарова***

## ГАЛИМ, ОСТАЗ, ШӘХЕС
*(филология фәннәре докторы, профессор Фәһимә Миргали кызы Хисамова портретына штрихлар)*

В статье излагается научная и педагогическая деятельность видного татарского ученого, методиста Фагимы Миргалиевны Хисамовой, освещаются основные направления её научной деятельности.

**Ключевые слова:** татарское языкознание, тюркология, морфология, история языка, историческая грамматика, графика.

Ә. Еники үзенең бер мәкаләсендә болай дип яза: «Мин борынгы зыялыларны күреп калган кеше. Аларның бөтен нәрсәләрендә – үз-үзләрен тотуларында булсын, сөйләшүләрендә булсын, ниндидер бер мәдәнилек сизелеп тора иде. Бик чиста, пөхтә киенәләр. Зыялы кешенең тышкы кыяфәте генә түгел, күңеле дә матур булырга тиеш бит әле». Зыялылыклары белән аерылып торган, үзләренә күпләрне җәлеп иткән шәхесләр, килешерсез, бүгенге көндә дә юк түгел. Сүзебез бүгенге сирәк зыялыларның берсе, исеме җисеменә туры килгән Фәһимә Миргали кызы Хисамова хакында.

Фәһимә Миргалиевна – кабатланмас, эрудит шәхес. Андый шәхес белән таныш булу – үзе бер бәхет. Хәтердә Фәһимә апа белән беренче очрашуым яңара. 2000 елның көзе. Җитәкчем белән очрашырга дип, Алабугадан Әлмәт муниципаль институтына (ул анда студентларга төрки тел белеменә кереш фәнен укытырга килгән иде) юл алдым. Беләсезме, очрашу бөтенләй мин уйламаганча килеп чыкты. Сүзен кыска тота торган һәм үтә дә таләпчән булып күз алдына килгән профессор бөтенләй башкача булып чыкты! Ике сәгатькә сузылган күрешүдә тема да ачыкланды, эшнең төзелеше дә билгеләнде, хәтта тормыш нечкәлекләре турында да сөйләшергә вакыт калган. Ул вакытта Фәһимә апа грамматиканың үзе кебек ифрат та төзек җөмләләре, каядыр яшерелгән таләпчәнлеге белән дә үзенә җәлеп итте. Фәһимә Миргалиевна безгә – укучыларына төпле киңәш, дөрес юнәлеш биреп, гыйльми иҗат ирегенә дә урын калдыра, ләкин шул ук вакытта эшнең нәтиҗәле, системалы булуын да таләп итә белә.

Фәһимә Миргалиевна Хисамова – беренче чиратта, татар тел белеме фәнендә үз урынын тапкан күренекле галим. 1971 елда Д.Г. Тумашева җитәкчелегендә «Хәзерге татар әдәби телендә сыйфат фигыль» дигән темага язылган кандидатлык диссертациясен уңышлы яклый. 1995 елда исә «Функционирование и развитие старотатарской деловой письменности XVI – I половины XIX вв.» дип аталган док-

торлык диссертациясе дә югары бәяләнә, бераздан «Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – начало XIX вв.) (2012) монографиясе дә дөнья күрә. Күпсанлы архивларда гарәп графикасындагы кулъязмаларны табып, укып, аларның күчермәләрен алып тикшеренүләр үткәрү нәтиҗәсендә Ф. Хисамова беренчеләрдән булып татар теле рус дәүләтендә дипоматия теле буларак 2–3 гасыр куланылышта була дигән нәтиҗәгә килә [Хисамова, 2012, 399].

Фәһимә Миргалиевна Хисамова – татар филологиясендә беренче фән докторы, Казан университетының иң беренче хатын-кыз деканы, татар хатын-кызларыннан иң беренче булып академик дәрәҗәсенә ирешкән күренекле тюрколог Диләрә Гариф кызы Тумашеваның шәкерте, остазының лаеклы дәвамчысы. Фәһимә Миргалиевна фәнни-тикшеренү эшләренә юнәлеш биргән, морфология фәненә кызыксыну уяткан, грамматик категорияләрнең хасиятен төшендергән фәнни җитәкчесен ихтирам белән искә ала [Хисамова, 2001, с. 52].

2011 елда журналистларга биргән бер интервьюсында Фәһимә Хисамова: «Безнең бурыч – телебез бик борынгыдан алып бүгенге көнгә кадәр нинди үзгәрешләр кичергәнлеген барлап, тарихи грамматиканы эшләү» – дигән иде [Хисамова, 2011]. Әйтергә кирәк, галимә бу юнәлештә дә үзеннән саллы өлеш кертте. Күптән түгел ул, «Татар теленең тарихи грамматикасы. Фонетика. Морфология» фундаменталь хезмәтен төгәлләп, басмага тапшырды.

Галимәбезнең фәнни тикшеренү өлкәләренең, хәтта борчыган өлкәләренең берсе – татар теленең графикасы һәм орфографиясе. Латин язуының зарурлыгын фәнни дәлилләп, «Татар теле: латин әлифбасына кайтуның фәнни нигезләре» (2004) хезмәтен татар һәм рус телләрендә бастырып чыгарды.

Фәһимә Миргалиевна татар телендә чыга торган газета-журнал битләрендә, радио-телевидение сөйләмендә, Интернетта тел кимчелекләренең, һәртөрле хаталарның күп булуына игътибар итә. Шул нисбәттән телебезнең грамматик төзелеше өлкәсендәге кимчелекләрне, сөйләм нормасын бозу очракларын искәртеп, редакция хезмәткәрләре, язучылар алдында чыгышлар ясый, мәкаләләр бастыра: «Телебез төзек һәм матур булсын» (1985), «Көндәлек матбугатта тел культурасы» (2005), «Вакытлы матбугатта тел культурасы мәсьәләләре» (2005), «Ана теле һәм милли матбугат» (2014) һ.б.

Фәһимә Миргалиевнаның мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәп укучылары, тәрбиячеләре, укытучылары өчен төзелгән методик хезмәтләре дә фәнни-педагогик җәмәгатьчелек арасында лаеклы урынын тапты. «Татар теле өйрәнә нәниләр. Балалар бакчалары тәрбиячеләренә кулланма»сы (автордашы Р.А. Борһанова) (2005) тәрбиячеләр өчен әле дә өстәл китабы ролен үти.

Фәһимә Миргали кызы төрле тип белем бирү учреждениеләрендә укучылар өчен туган

тел дәреслекләре төзүдә дә катнаша. Моннан тыш «Казан утлары» журналында 1989–1990 елларда аның «Татар теле дәресләре» дигән мәкаләләр циклы да басыла һәм даими укучысын таба.

Фәһимә Миргали кызы Хисамованың хезмәт юлы Казан дәүләт университеты белән бәйле, күп еллар татар теле кафедрасында эшли, аның мөдире булып тора. Биредә ул татар теле морфологиясе, тел тарихы, тарихи грамматика, фонетика буенча лекцияләр укый, иске татар теле, язма истәлекләрнең текстологиясе һәм тел үзенчәлекләре фәннәре буенча гамәли дәресләр, махсус курслар алып бара. Галимәнең бу юнәлештәге эшчәнлеге төрле программалар, вуз дәреслекләре, методик кулланмалары төзү белән үрелеп бара. Ф.М. Хисамова – «Татар теле морфологиясеннән күнегүләр җыентыгы» (1973), «Хәзерге татар теле. Морфология (студентлар өчен методик әсбап) (1981), «Хәзерге татар теле фонетикасы. Студентлар өчен лекцияләр һәм методик күрсәтмәләр» (1981) авторы, күп сандагы программаларның редакторы да була.

2006 елда Фәһимә Миргалиевнаның татар теле морфологиясе өлкәсендәге күп еллык эзләнүләренең нәтиҗәсе буларак «Татар теле морфологиясе» дәреслеге дөнья күрде. Әлеге хезмәт турында М.З. Зәкиев болай дип яза: «Бу татар теленең морфологик системасын логик эзлеклелектә ачып бирә торган беренче дәреслек булачак» [Зәкиев, б. 6]. Хезмәттә морфология, аның өйрәнү объекты, морфемика, сүз ясалышы, сүз төркемнәре һәм аларның грамматик категорияләре турында фәнни яктан төгәл мәгълүмат бирелә. Дәреслектә һәр грамматик күренеш җентекле анализлана, теге яки бу төшенчә белән бәйле бәхәсле фикерләр, карашлар төрлелеге китерелә, автор аларга үз мөнәсәбәтен җиткерә. Хезмәттә белемнәрне тикшерү өчен сораулар һәм морфологик анализ үрнәкләре дә бирелә. Шул рәвешле, биредә Фәһимә Миргали кызының фәнни һәм педагогик тәҗрибәсе кушылып, югары дәрәҗәдә эшләнгән хезмәт барлыкка килә. 2015 елда дәреслек яңадан бастырыла.

Тынгысыз галимә телнең үткәне турында гына түгел, киләчәге турында да уйлана. Халыкара тюркологик конференцияләрнең берсендә ул: «Билгеле инде, телнең төзелешен, үзенчәлеген өйрәнү тукталып тормаячак. Моңа кадәр без күбрәк телнең тышкы ягын – структур юнәлешен өйрәндек. Менә хәзер эчтәлек ягы алга чыга: телнең нәкъ үзенең, һәр милли телнең хосусиятен чагылдыра торган һәр кушымчаның, һәр сүз кисәгенең үз мәгънәсе бар һәм аларның сөйләмдә урнашуы тәртибе һәр телдә үзенчәлекле. Хәзер телне өйрәнүдә менә шушы функциональ-тематик юнәлешкә күчү бик әһәмиятле», – дип, тел белеменең киләчәктә үсеш-үзгәреш юлларын, юнәлешләрен дә билгели.

Ф. Хисамованың бөтен хезмәт юлы, фәнни эшчәнлеге студентларга белем бирү белән тыгыз бәйләнгән. Аның һәр дәресе – үзе бер ачыш. Лектор, студентларның игътибарын җә-

леп итеп, әллә нинди катлаулы материални да кызыклы, үтемле итеп җиткерә, конкрет мисаллар белән дәлилли. Сөйләгәннәре хәтергә уелып кала. Фәһимә Миргалиевнаның хезмәттәшләре һәм шәкертләре килешер, ул үзенең лекцияләрендә дә логик эзлеклеләккә зур игътибар бирә, укучыларын да шуңа өйрәтә иде. Бу сыйфаты аның югарыда аталган хезмәтләрендә дә чагылыш таба.

Фәһимә апа – татар халкы, татар милләте, татар теле өчен җан атып йөргән милләтпәрвәр затларның берсе. «Азатлык» радиосына биргән бер әңгәмәсендә ул: «Татар теле беренче чиратта ул шәхеснең үзенә кирәк. Шул тел аша балаларыбыз рухи һәм җан байлыгы ала, ул шуның аша күңелен баета, туган теле аша уйлый. Татарча белеп үскән бала рухы бай була», – ди. Фәһимә апа белән Нурмөхәммәт абыйның өч баласы да, Дәрвишләр бистәсенә йөреп, татар мәктәбендә белем ала.

Фәһимә Миргали кызы Хисамова җитәкчелегендә күпсанлы кандидатлык диссертацияләре яклaнды. Хәзерге вакытта төрле уку йортларында, фәнни-тикшеренү учреждениеләрендә хезмәт куючы шәкертләре Р.Т. Йөзмөхәммәтов (2002), Г.Ф. Гарипова (2003), Р.Ш. Хөрмәтуллина (2004), Ф.М. Мөхәммәтшин (2007), В.Р. Фәхретдинова (2007), Л.Р. Садыйкова (2010), М.Р. Сәйхунов (2010), Л.А. Хисамоваларның (2010) эзләнүләре татар теле һәм гомумән төрки тел белеменең төрле мәсьәләләрен өйрәнүгә лаеклы өлеш керттеләр.

Фәһимә Миргалиевна – тормышта да олы җанлы, киң күңелле, шәфкатьле, башкаларның эчке халәтен бик тә нечкә тоемлый торган сизгер җанлы, шул ук вакытта гаҗәеп гади кеше. Укучыларына ул һәрвакыт хөрмәт белән карый, хәлләрен сораша, тормышлары, укулары һәм эшләре белән кызыксына. Урынлы киңәшләрен биреп, шәкертләрен тирән фикер йөртергә өйрәтә.

Безгә – Фәһимә апаның шәкертләренә – тыйнак фатирларында булырга туры килгәне бар. Аларның өенә килеп керүгә, ниндидер яктылык бөркелә. Фәһимә апа белән Нурмөхәммәт абый җылы һәм ягымлы каршы алалар. Стена тулы картиналар, шәмаилләр, китап киштәләре күзгә ташлана. Мәһабәт гәүдәле Нурмөхәммәт абый үзенең баритон тавышы белән сихри бер дөньяга алып кереп китә: туган ягы, туган туфрагы, әти-әниләре турында сөйли. Сизмәстән генә әдәбият дөньясына, аннары төрле тарихи, фәлсәфи, дөньяви мәсьәләләргә «чумганыңны» сизми дә каласың. Җор телле Нурмөхәммәт абый шул арада комплиментлар да әйтеп куярга өлгерә: «Кызлар, сезгә бәхет килешә-ә-ә», – ди. Бу вакытта татар хатын-кызларына хас булган тыйнаклык белән Фәһимә апа, тормыш иптәшенең сүзен бүлдермичә, ахыргача тыңлап тора, аннары, безнең соравыбыз буенча, уллары ясаган рәсемнәрне күрсәтеп, аларны ясау тарихын сөйли башлый. Аның һәр сүзендә улларына карата мәхәббәт, алар белән горурлану сизелә.

Фәһимә Миргалиевна әле дә эзләнүдә. Ул әле дә телнең үткәне, хәзергесе, киләчәге өчен җан

атып яши. Аның һәр сүзендә, һәр хәрәкәтендә үз эшенә чын күңелдән бирелгәнлек, яңалыкка омтылыш сизелә.

Хөрмәтле остазыбыз Фәһимә Миргалиевна! Сезне гомер бәйрәмегез – юбилеегыз белән котлыйбыз. Без, укучыларыгыз, Сезгә биргән белемнәрегез, киңәшләрегез өчен рәхмәтле. Тормыш юлыгыз үзегез теләгәнчә матур һәм көйле барсын!

**Әдәбият**

*Зәкиев М.З.* Кафедраның бишенче мөдире // И газиз туган телем! Казан: Казан ун-ты нәшр., 2006. Б. 6.

Фәһимә Хисамова: «Хәзер телне өйрәнүдә функциональ-тематик юнәлешкәкүчүбикәһәмиятле//http://tatar-inform.tatar/news/tatarstan/2011/10/20/70212/

*Хисамова Ф.М.* Татарский язык в восточной дипломатии России (XVI – начало XIX вв.) / отв. ред. Э.Р. Тенишев. Казань: Мастер Лайн, 1999. 408 с.

*Хисамова Ф.М.* Диляра Тумашева // Казань (на русском языке). 2001. №12. С. 52–53 .

***Гайнуллина Гөлназ Фоат кызы,***
*Казан (Идел буе) федераль университеты*
*E-mail: ggf@inbox.ru*

***Гафарова Вилүзә Роберт кызы,***
*Казан (Идел буе) федераль университеты*
*E-mail: 79046639045@yandex.ru*

*«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе хезмәткәрләре һәм журнал укучылары исеменнән без дә Фәһимә Миргалиевнаны күркәм гомер бәйрәме белән ихлас күңелдән котлыйбыз, аңа сәламәтлек, уңышлар, гаилә иминлеге теләп калабыз!*

УДК 792.03

*А.Р. Салихова*

## ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ ҮСЕШ ЭТАПЛАРЫ

В статье рассматриваются основные этапы развития татарского театра.

**Ключевые слова:** татарский театр, история татарского театра, этапы развития.

Татарстанның театр җәмәгатьчелеге Казанда татар телендә рәсми рәвештә беренче театр күрсәтелүнең 110 еллыгын билгеләп үтә. 1906 елның 22 декабре татар театрының туган көне булып санала, аның барлыкка килүе тарихи милли үсеш барышы белән бәйле.

Капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсеше Россия дәүләтенең сәяси, икътисади, рухи сфераларында сизелерлек үзгәрешләр китереп чыгара. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында илнең иҗтимагый тормышы үзенчәлекле динамик үсеш ала һәм ул империядәге төрки халыкларның гадәти көнкүрешенә дә тәэсир итми калмый. Милли капитал арта һәм ныгый, икътисади һәм мәдәни өлкәләрдә татарларның башка халыклар белән элемтәсе көчәя. Яңа, алдынгы фикерле идеология формалаша, милли җәмәгатьчелек институтлары барлыкка килә: сәяси партияләр оеша, матбугат эшчәнлеге киңәя; әдәбият, мәдәният һәм сәнгатьнең дөньяви формалары үсеш ала.

Милли сәхнә иҗатының тууы татар драматугиясе барлыкка килү белән дә бәйле. Беренче татар пьесалары XIX гасырның соңгы чирегендә иҗат ителә. Мәсәлән, 1887 елда Г. Ильясиның «Бәхетсез кыз», 1888 елда Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» пьесалары дөнья күрә. «Чистай комедиясе» (1895) һәм Г. Камалның беренче редакциядәге «Бәхетсез егет» (1898) әсәрләре дә драматургия үсешенең башлангыч чорына карый. Шул ук вакытларда тәрҗемә ителгән (нигездә рус һәм төрек телләреннән) пьесалар да күренә башлый.

Беренче татар спектакльләре байларның шәхси йортларында һәвәскәр түгәрәкләргә йөрүчеләр, шулай ук заманының «Мөхәммәдия» (Казан), «Госмания» һәм «Галия» (Уфа) кебек алдынгы мәдрәсәләрендә укучылар тарафыннан куела. Ә инде 1907 ел башында Оренбургта Россиядә беренче булып мөселман драма актерлары труппасы оеша, аны Ильяс Кудашев-Ашказарский җитәкли. Соңыннан зур танылу яулаган артистлардан Вәли Мортазин-Иманский, Әхмәт Кулалаев, Бари Болгарский һ.б. да иҗади эшчәнлекләрен шушы труппада башлап җибәрәләр. 1907 елның җәендә труппа Идел буе шәһәрләренә беренче гастролен оештыра, анда аларга беренче ха-

тын-кыз актриса Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, аннан Габдулла Кариев кушыла. Репертуарда Ф. Халидинең «Морат Сәлимов», А. Чеховның «Предложение», А. Островскийның «В чужом пиру похмелье» һ.б. әсәрләр була.

Труппа җитәкчесе И. Кудашев-Ашказарский үзе энергияле һәм югары актерлык сәләтенә ия булуына карамастан, аның оештыру һәм киң фикерләү мөмкинлекләре чикле була. Тиздән ул труппаны калдырып, мөстәкыйль иҗат эшчәнлеге башлап җибәрә. Коллектив белән җитәкчелек итүгә яшь, талантлы һәм җаны-тәне белән сәнгатькә бирелгән Габдулла Кариев алына. Г. Кариев киңкырлы шәхес буларак татар сәхнә сәнгатенә шулхәтле көчле йогынты ясый ки, татар милли актерлык мәктәбен әле хәзер дә «Кариевныкы» дип атыйлар. Ул эшен художество җитәкчесе буларак та, режиссер, театр педагогы сыйфатында да алып бара. Шуның белән бергә, труппа эшчәнлеге коллегиаль характерда оештырыла. Коллективның һәр әгъзасы билгеле бер мәсьәләләр өлкәсе өчен җавап бирергә тиеш була: Кариев үзе, мәсәлән, гомуми җитәкчелек, Мортазин белән Гыйззәтуллина – режиссура, Кулалаев – афишаларны язу һәм элү, Хәйретдинов рольләрнең сүзләрен күчереп алу һәм суфлерлык эшен алып баралар. Эшнең мондый бүленеше коллективта дуслык хөкем сөрүе, үзара ярдәмләшү һәм тигез хокуклы партнерлык турында сөйли.

1908 елның язында татар актерлары Тифлистә гастрольдә булалар һәм алар анда Азәрбайҗан актерлары белән берләшәләр. Бергәләп эшләү өчен репертуарга азәрбайҗан һәм татар драматургларының әсәрләре алына (Н. Наримановның «Надир шаһ», Н. Вәзир-задәнең «Фәхретдин кайгысы» трагедияләре, Г. Камалның «Бәхетсез егет» драмасы һ.б.) Ике милләт вәкилләреннән оешкан труппаның эшчәнлеге, аларның һәркайсының иҗади диапазонын да киңәйтә. Татар артистлары, үзләренең азәрбайҗанлы дуслары өчен бик үк таныш булмаган, көнкүрешне яктырткан, психологик реализм белән сугарылган әсәрләр сәхнәләштерәләр, ә үзләре көчле дәртлелек, югары хисләр һәм батырлык пафосы белән сугарылган сәнгать белән якыннан танышалар, күтәренке рухлы романтик манерада уйнау алымнарын үзләштерәләр. Моннан тыш, бергәләп эшләү ике милли труппаның да репертуарларын баета. Шул чордан башлап, Н. Нариманов, М. Ахунов һәм башка азәрбайҗан драматургларының әсәрләре татар театры сәхнәсендә ныклы урын ала.

1908 елгы гастрольләрдән соң бу ике труппа аерылалар. Шуннан башлап, татар труппасы «Сәйяр» («Сәяхәтче») исемен ала. Чыннан да, үз бинасы булмаган коллективка гострольләр белән күп йөрергә туры килә. Идел буе, Кырым, Кавказ, Урта Азия, Казакстан, Себер – бу төбәкләрнең кайсына гына барып чыксалар да, актерлар үзләренең рәхмәтле тамашачылары белән очрашалар. Ә бит сукбай хәлендәге труппа өчен яшәү шартлары

җиңел булмый, һәм ул аларның иҗади омтылышларын да чикли. Үз биналары булмау, атна саен сәхнәгә яңа пьеса чыгару, бина арендалау, газетада белдерүләр бастыру, афишалар эшләтү зур чыгымнар таләп итә. Матди хәлнең тотрыксызлыгы, әлбәттә инде, беренче татар артистларының эшен катлауландыра. Инкыйлабка кадәрге театр тормышын өйрәнеп тикшеренүчеләр ул чорны милли театр сәнгате үсешенең иң катлаулы этабы дип бәялиләр [Мәхмүтов, Илялова, Гыйззәт]. Шуңа да карамастан, театр заманына күрә бик нәтиҗәле эшли. Репертуары жанры һәм стиле буенча төрледән-төрле әсәрләр белән баетыла. Мәсәлән: көнкүреш комедиясе һәм водевильләр; драма һәм көчле трагедияләр; рус, азәрбайҗан, төрек авторларының пьесалары; татар язучылары И. Богданов, Г. Камал, Г. Исхакыйның яңа, көн кадагындагы әсәрләре сәхнәләштерелә. Татар актерларының тормышчан һәм иҗади тәҗрибәләре әнә шулай туплана осталыклары камилләшә, белем дәрәҗәләре киңәя.

1911 елның декабереннән башлап, «Сәйяр» труппасы Көнчыгыш клубның штат расписаниесенә кертелә [Татарча театр]. Ягъни бу – кышкы сезонда иҗади коллективтагы һәркемгә даими рәвештә хезмәт хакы түләнә башлауны, труппа өчен аерым бина бирелүне аңлата.

Шушы вакытта труппага рәссам итеп С. Яхшыбаев алына, ул декорацияләр өчен җавап бирергә тиеш була. Болар барысы да милли театр сәнгате үсешенең икенче этабы башлануны белдерә, ул 1917 елга – иҗади үсеш активлыгы этабына хәтле дәвам итә.

1912 елда Уфада С. Гыйззәтуллина-Волжская җитәкчелегендә икенче профессиональ труппа – «Нур» эшли башлый. Ә 1915 елда Оренбургта В. Мортазин-Иманский тарафыннан «Ширкәт» труппасы оештырыла.

Милли башкарма мәктәп үзенчәлекләре турында әйткәндә, шуны искәртеп үтәргә кирәк: татар актерлары махсус белем алмаган хәлдә дә үз эшләренең пионерлары булдылар һәм профессияләренең нигезен практикада, көндәлек эш процессында үзләштерделәр. Башка труппалар, аерым алганда Казандагы һәм башка шәһәрләрдәге рус театрлары спектакльләреннән үрнәк алдылар, аларның ярдәменә таяндылар. Охшарга тырышу, күчерү алымыннан еш файдаландылар, тормышта сәхнә персонажының реаль прототибын тапсалар, аның һәр кыланышын тулысы белән сәхнәгә күчерделәр. Бу хакта З. Солтанов, Г. Болгарская һәм башка артистларыбызның истәлекләреннән укый алабыз. Иҗади процесска болай якын килү беркатлылык һәм примитив кебек тоелса да, ул сәхнә тормышын башлап җибәрүчеләр өчен зур табыш була, һәм сәхнә реализмы үсешенең билгеле бер баскычын били.

Инкыйлабка кадәрге татар театры төрле кешеләрдән тупланса да, аларның һәркайсы көчле, индивидуаль шәхес була, һәм бу сыйфатлары, берсүзсез, иҗатларында да чагылыш таба. Гомумән алганда, 1917 елгы инкыйлабка кадәр үк татар театры

көчле, талантлы, үзешчән актерлар плеядасын хасил итә, алар өйрәнчекләрчә охшарга тырышудан – мөстәкыйльлеккә һәм тулы канлы иҗатка, образларны бик сай гәүдәләндерүдән – психологик тирәнлеккә, дөреслекне детальләп конкретлаштырудан шигъри һәм социаль гомумиләштерүгә юл салучылар.

Бу юлда стиле, жанры һәм юнәлешләре буенча бай, күп төрле репертуарның да өлеше аз булмый. Бик күп санда рус, төрек, Көнбатыш Европа драмалары татарчага тәрҗемә ителеп сәхнәләштерелә. Милли драматурглар пьесалары нигезендә куелган һәр постановка шатлык белән көтеп алынган вакыйга була. Г. Исхакый, Г. Камал, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, И. Богданов, Ф. Сәйфи-Казанлы кебек татар драматургларының әсәрләре аеруча зур популярлык казана.

Февраль инкыйлабыннан алып 20 нче еллар башына кадәрге вакыт аралыгында татар театры аеруча нәтиҗәле эшли. Цензура бетерелүдән файдаланып, күптән көтелгән ирек белән канатланган театр элек рөхсәт ителмәгән, кискен темаларны күтәргән әсәрләрне сәхнәгә чыгара башлый. Милли драматургиянең «пролетариат драмасы» дигән яңа жанры үсеш ала. Бер үк сәхнәдә Г. Исхакый, Г. Камал, Ф. Борнаш, К. Тинчурин, Г. Коләхмәтов, Ш. Усманов, М. Фәйзи, Һ. Такташ, Г. Рәхим кебек үзләренең сәяси карашлары һәм иҗади ориентацияләре белән бер-берсеннән бөтенләй аерылып торган язучыларның хезмәтләре сәхнәләштерелә. Бу озын булмаган вакыт эчендә (1917–1923 еллар) татар сәхнәсендә плюрализм хөкем сөрә, дип авыз тутырып әйтә алабыз.

Сәхнә сәнгатенең тасвири чаралары да сизелерлек байый. Бу чорда милли эчтәлекле, романтик рухтагы музыкаль драмаларның сәхнәгә күтәрелүе аерым игътибарга лаек. Мәсәлән: Ф. Борнашның «Таһир – Зөһрә»се (1918), Г. Рәхимнең «Бүз егет»е (1921), К. Әмиринең «Йосыф – Зөләйха» һәм «Ләйлә белән Мәҗнүн» әсәрләре (1922, 1923), Ә. Сәгыйдинең «Сак-Сог»ы (1923) һ.б. Бу постановкаларның кыйммәте шунда, аларның нигезенә чын мәгънәсендә милли халык иҗаты үрнәкләре салынган. Аларны гасырлар тирәнлегеннән килгән Көнчыгыш лирик һәм эпик поэзиясенең традицияләре белән кушып, татарлар өчен әле яңа булган театр формалары тудыру омтылышы да көчәя.

Бер үк вакытта дөнья һәм рус классикасы, аерым алганда трагедия һәм батырлык драмалары кебек, инкыйлаб заманына аваздаш жанрлар белән кызыксыну арта. 1920–1922 елларда Беренче татар дәүләт күрсәтмә труппасы тарафыннан Ф. Шиллерның «Разбойники», В. Шекспирның «Гамлет» һәм «Отелло», Г. Гейненың «Альмансур», Н. Гогольнең «Ревизор», М. Горькийның «На дне» һәм «Мещане» әсәрләре кебек киң танылган пьесалар сәхнәләштерелә. Коллективның җитәкчесе һәм әйдәүче артист Мөхтәр Мутинның иҗади үзенчәлеге бу спектакльләргә бунтарьлык рухы, романтик

күтәренкелек һәм азатлык пафосы өсти.

Октябрьдән соңгы беренче елларда халык массасының һәркайда театр сәнгате белән кызыксынуы көчәя. Бу хакта Б. Гыйззәт болай яза: «Победному шествию Октября сопутствовало создание новых татарских театров в Казани, Самаре, Челябинске, Ташкенте, Бухаре, Хиве, Перми, Семипалатинске, а также крестьянских театров, таких, например, как “Сабанче” в Мамадыше» [Гиззат, с. 338]. Бу елларда үзешчәннәр театрлары киң үсеш ала. Казанда гына да кырыклап профессиональ, ярымпрофессиональ һәм үзешчән коллективлар эшли [Арсланов, с. 97].

Яңа социалистик татар театры идеологиясен иң яхшы чагылдыручы актер, режиссер, драматург Кәрим Тинчурин була. Аның композитор Салих Сәйдәшев белән бергәләп сәхнәгә чыгарган «Зәңгәр шәл», «Сүнгән йолдызлар», «Казан сөлгесе» музыкаль драмалары тамашачылар тарафыннан алкышлап кабул ителә. Монда режиссерның сәхнә формалары өлкәсендәге эзләнүләре дә зур роль уйный. К. Тинчурин спектакльләренә композицияне тыйнакландыру, хәрәкәтләргә бай дәртле ритм, актерларның хискә бирелеп уйнавы, музыкаль бизәлеш, шигъри яңгыраш, биюләр, төрле трюклар хас. Шул ук вакытта ул көнкүреш чынбарлыгындагыча традицион «реализм» формаларын да саклый, режиссер фәкать шул юл белән генә тамашачы күңеленә үтеп керергә мөмкин икәнен аңлап эш итә.

Башка фикерләр дә була. «Суллар сәнгате» тарафдарлары Ә. Мәҗитов, Ф. Саллави, Ф. Бакир һ.б. «искергән» театр алымнарының әһәмиятен тулысынча кире кагалар, алар аны, яңа революцион чынбарлыкны яктыртырга, пролетариат мәнфәгатләренә хезмәт итәргә сәләтле түгел, дип бәялиләр. 1924 елның 24 февралендә «Сулф» иҗади берләшмәсе һәм Ә. Мәҗит җитәкчелегендә «Сулф» драма мастерское оеша. Сул театр эшлеклеләре яңа, тәэсирлерәк театр формалар эзләүне максат итеп куялар, көчле метафорик шартлылыкны, конструктивизмны, иҗатта кыю экспериментларны пропагандалыйлар. Аларның энтузиазмы озакка җитмәсә дә, гадәти булмаган тәҗрибәләре, һичсүзсез, татар театрының сәнгати чаралары палитрасын баета, аның алга таба үсешенә билгеле бер дәрәҗәдә эстетик йогынты ясый.

20 нче елларның икенче яртысында татар театрына махсус театр белеменә ия режисерларның беренче буыны килә. Г. Девишев, Р. Ишморатов, С. Сульва-Вәлиев үз иҗатларында реалистик театрның заман тарафыннан сыналган традицияләрен һәм сәхнә формасы өлкәсендәге табышларны уңышлы кулланалар, сәхнәне техник яктан җиһазландыру чаралары арта (аерым алганда, әйләнә торган сәхнә түгәрәге куелып, актив кулланыла башлый). Спекатаклънең сәхнә бизәлешендә дә сизелерлек үзгәрешләр була: озак еллар рәссам булып эшләгән П. Беньков урынына белеме буенча архитектор булган П. Сперанский билгеләнә. Шун-

нан соң яссылыкка нигезләнгән декорацияләрне сәхнә киңлегендәге архитектур яктан күләмле күренешләр алыштыра. Труппа да яңара: М. Мутин, З. Солтанов, Б. Тарханов, Г. Болгарская, Н. Арапова кебек инкыйлабка кадәрге театр мәктәбе узган, танылган, тәҗрибәле осталар янәшәсендә сәхнәдә яшь, һәрьяктан талантлы артистлардан С. Булатов, М. Вәлишин, С. Айдаров, Г. Кайбицкая, Р. Кушловская, Г. Камскаялар уйный башлый. Репертуар да яңа заман рухындагы әсәрләргә байый. Татар драматурглары революцион идеологияне мавыктыргыч лирик, психологик яктан отылышлы формаларга төреп бирергә өйрәнәләр. Моны сәхнәдә куелган түбәндәге спектакльләрдән күрергә була: А. Таҗетдинов-Рахманкуловның «Килмешәк» һәм «Сафура», Г. Кутуйның «Балдыз», Р. Яхинның «Урман кызы», Г. Минскийның «Мансуровлар гаиләсе», М. Зәетовның «Ханбикә», Ш. Ганиевның «Сүнмәс йолдызлар», Һ. Такташның «Иртәнге матурлык», А. Хәмиднең «Һинд кызы», Ф. Борнашның «Хөсәен мирза» һәм «Адашкан кыз». Сәхнәдә куелган тәрҗемә әсәрләр дә (Р. Лотарның «Шут на троне», Әбү Сәгыйтьнең «Дала кызы», А. Деннери һәм Кермонның «Две сиротки», Б. Лавреневның «Разлом», Д. Фурмановның «Мятеж» һ.б.) зур уңыш белән бара.

30 нчы елларда театр эшчәнлеге өстеннән партия һәм хөкүмәт органнарының контроле көчәя. 1932 елның апрелендә әдәбиятта пролетар төркемнәрне бетерү турында указ чыга. 1934 елда Совет язучыларының беренче съездында әдәбиятта һәм сәнгатьтә социалистик реализм методы бердәнбер дөрес ысул буларак кабул ителә, әмма тора-бара ул башкача фикер йөртүчеләргә каршы көрәштә иң аяусыз коралга әверелә. 1936 елның гыйнварыннан форма һәм стильгә киң масштаблы һөҗүм башлана, нормативлыкка каткый чикләүләр кертелә. Шулай итеп, театр сәнгатенең алгарышка омтылышына киртә куела, яңа формалар эзләү һәм экспериментлар чикләнә.

Мондый сәясәт татар театры өчен зур югалтуларга китерә. Режиссер-новатор Г. Девишев Казаннан китәргә мәҗбүр була, шартлы театр һәм иҗади экспериментлар тарафдары С. Сульва-Вәлиев сәхнә эшчәнлегеннән читләштерелә. «Кыскарту» сәбәбе белән К. Тинчурин, Ш. Шамильский, С. Булатов, Х. Колмәмәт, Г. Уральский һ.б. театрда эшләүдән азат ителә. 1937 елда башланган репрессияләр милли сәнгатьне бөтенләй көчсезләндерә. Яшь театр эшлеклеләре С. Булатов, Г. Исмәгыйльев, Х. Уразиков, Ш. Сарымсаков, К. Тумашева һ.б.ларга сәхнә эшен әнә шундый авыр һәм кысынкылык шартларында башлап җибәрергә туры килә.

Бөек Ватан сугышы театр тормышына тагын бер авыр сынау өсти. Матди чикләнү, кадрларны кыскарту, бинасыз калу (театр бинасы завод карамагына бирелә) – болар театрга килгән кыенлыкларның бер өлеше генә. Театрның репертуар мәсьәләсе кискенләшә, чөнки аның тама-

шачыны җәлеп итәрлек булуы белән бергә заман рухына җавап бирә алу зарурлыгы да калкып чыга. Сәхнәгә дошманның чын йөзен ача торган, совет солдатларының кыюлыгын һәм батырлыгын, тыл хезмәтчәннәренең сабырлыгын һәм фидакярлыгын гәүдәләндергән патриотик рухтагы әсәрләр күтәрелә. Мәсәлән: Ф. Вольфның «Профессор Мамлок», К. Симоновның «Парень нашего города», «Русские люди», Т. Гыйззәтнең «Таймасовлар», Н. Исәнбәтнең «Мәрьям», Р. Ишморатның «Кайту», Ә. Камалның «Буран», М. Әмирнең «Миңлекамал» әсәрләре. Театрның тарихи үткәннәр белән дә кызыксынуы арта. Н. Исәнбәтнең «Идегәй», Ә. Фәйзинең «Тукай», Б. Горбатовның «Юность отцов» спектакльләре агитацион миссия үтиләр: үз көченә ышанычны, социаль һәм идея ягыннан дошманнан өстен булуны, алда җиңү яуланачагына өметне ныгыталар. Милли классик комедияләрне тамашачылар аеруча яратып кабул итәләр. Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә», Г. Камалның «Банкрот», Х. Хакимзадә Ниязиның «Мәйсәрәнең шуклыгы», Лопе де Веганың «Собака на сене» кебек көлкеле постановкалары публиканы оптимизм белән сугаралар, сугыш чоры көнкүрешендәге авырлыкларны онытып торырга ярдәм итәләр. В. Бебутов белән К. Тумашева бергәләп сәхнәгә куйган «Король Лир» (В. Шекспир) трагедиясе театр тормышында зур мәдәни вакыйга буларак кабул ителә.

Сугыштан соңгы еллар да татар театры өчен җиңел булмый. Илдә театр белән кызыксыну гомумән бик нык кими. Социаль һәм икътисади сәбәпләрдән (ачлык, җимереклек, халык хуҗалыгын торгызу процессындагы авыр хезмәт) тыш, сәнгать белән коры административ ысуллар ярдәмендә идарә итәргә омтылган партия җитәкчелегенең кырыслыгы һәм урынсыз таләпләре дә театр тормышына үз эзен сала. ВКП(б) Үзәк Комитетының «Драма театрлары репертуары турында», «“Звезда” һәм “Ленинград” журналары турында», «В. Мураделиның “Великая дружба” операсы турында» дигән карарлары гаять тискәре нәтиҗәләргә китерә. Әдәбиятта һәм театр сәнгатендә урнашкан «конфликтсызлык теориясе, чынбарлыкны артык матурлап күрсәтергә омтылу әсәрләрдән тормыш хакыйкатен, кешеләрне борчый торган көнүзәк проблемаларны куып чыгара. Иҗат иреге дә кискен тыюга дучар ителә. Н. Хрущев җепшеклеге беркадәр иркенлек, саф һава дулкыны алып килә. Татар театрында да җиңелчә лирик комедияләр һәм драмалар куела башлый. Хәй Вахитның сентиментал характердагы әсәрләре буенча Рифкать Бикчәнтәев сәхнәләштергән постановкалар аңа хәтле куелып килгән «идеологик тикшерү узган», «хак», «җитди» спектакльләрдән бик нык аерылып торалар. Аларга да тәнкыйть көчле була, шулай да алар зур уңыш яулый. Тоталитар режим таләпләреннән бераз арына төшкәч, театр, революцион казанышлар белән түгел, ә кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрне, мәхәббәт газаплары, әхлакый

проблемаларны якын иткән тамашачыга йөз белән борыла.

Тамашачы мәхәббәтен яулау юнәлешен Марсель Сәлимҗанов та тотып ала. Гомумән, 60 нчы еллар буыны театрның яңа этабын башлап җибәрә. Аренага яшь, иҗади интеллигенциянең актерлар, режиссерлар, композиторлар, язучыларны берләштергән тулы бер плеядасы күтәрелә. Т. Миңнуллин, Ш. Хөсәенев, Р. Батулла кебек драматурглар, җитештерүне һәм патриотик хисләрне яктыртуда төп игътибарны психологизмга һәм әхлак мәсьәләләренә юнәлтеп, әсәрләрен җанландырып җибәрләр. Әлбәттә, аларның һәркайсының үзәген коммунистик идеология тәшкил итәргә тиеш була, әмма авторларның һәркайсы үз әсәрен я фәлсәфи, я юмор яки мелодраматик күренешләр ярдәмендә баетып, иҗади индивидуальлеген раслый. Театр яңадан популярлык казана, спектакльләр җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уята, бәхәсләр темасына әйләнә.

М. Горбачев башлап җибәргән үзгәртеп кору процессы җәмгыятьнең рухи яңарышына этәргеч була. Демократик үзгәрешләр татарларда да үз чагылышын таба. 90 нчы еллар башындагы иҗтимагый борылышлар республикабыз театр тормышында да эзсез калмый: коллективка яңа буын яшь режиссерлар, драматурглар, актерлар, музыкантлар, рәссамнар килә. Театр афишаларында Ф. Бикчәнтәев, Р. Заһидуллин, Р. Әюпов, И. Гыйләҗев, З. Хәким, Г. Каюмов һ.б. исемнәр пәйда була. М. Щепкин исемендәге театр студиясен тәмамлаган бер төркем яшьләр, 60 нчы еллардагы щепкинчы элгәрләре кебек, Г. Камал театрына килеп кушылалар. Шул ук вакытта татар сәхнәсенең танылган осталары яңа шартларда «икенче сулыш» алдылар. Т. Миңнуллин, Ф. Бүләков, И. Юзиев, М. Сәлимҗанов, Н. Исәнбәт иҗатларында яңа темалар күтәрелә башлады.

Борынгы чыганаклар белән кызыксыну омтылышы репрессияләнгән язучылар (Ә. Рахманкулов, Г. Исхакый) әсәрләренә әйләнеп кайту белән генә тәмамланмый, ә яңа пьесалар проблематикасында да чагылыш таба. Әйтик, М. Гыйләҗевнең «Бичура», Т. Миңнуллинның «Шәҗәрә», «Илгизәр+Вера», Ю. Сафиуллинның «Идегәй», З. Хәкимнең «Күрәзәче» пьесалары. Иҗади һәм милли күтәрелеш Г. Камал театры өчен генә хас күренеш түгел. К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында да җанлы, үзенчәлекле, оригиналь әсәрләр сәхнәләштерелде. Мәсәлән: Н. Гыйматдинованың «Сихерче», Н. Фәттахның «Идел суы ага торыр...» һ.б.

Болардан тыш, дөнья һәм рус классик әсәрләре буенча да тамашачы күңеленә үтеп керердәй спектакльләр куелды. Г. Камал театрында, мәсәлән, В. Шекспирның «Ромео һәм Джулетта», Ибсенның «Өрәкләр», («Привидения»), Лабишның «Станция Шамбоде», Лопе де Веганың «Биюче» («Учитель танцев»), Э. де Филиппоның «Шимбә, якшәмбе, дүшәмбе» («Суббота, воскресенье, понедельник»), Ф. Шиллерның «Юлбасарлар» («Разбойники»),

А. Островскийның «Светит да не греет» күрсәтелде. К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры тамашачылар өчен Г. Лорканың «Кровавая свадьба», П. Бомаршеның «Женитьба Фигаро», Мольерның «Господин Пурсоньяк», Грекованың «Вдовий пароход» әсәрләрен сәхнәләштерде. Болар әле тулы исемлек түгел. Әйтеп үтелгән спектакльләрнең куелыш үзенчәлеге шунда, алар төгәл һәм ачык стилистик чишелешкә ия, тасвири чараларга бай, башкарылу манералары оригиналь, яңа гадәти булмаган образлылык көчле.

Шунысы да мөһим, республикада да, аның чикләреннән тыш та күп кенә татар театры коллективлары оешты. Мәсәлән: Казанда, Яр Чаллыда, Түбән Камада, Уфада, Туймазыда, Оренбургта…. Элек колхоз-совхоз театры буларак эшләп киткән Әлмәт, Минзәлә театрларының да статусы һәм сәнгати дәрәҗәсе нык кына күтәрелде. Республикада югары театраль белем алу мөмкинлеге барлыкка килде. Үзебезнең Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясендә актерлык-режиссерлык факультетын тәмамлаган белгечләр театрларда, радио һәм телевидениедә эшлиләр. Республикакүләм һәм Халыкара театр фестивальләре уздыру традициягә әйләнде. Чит илләрдә гастрольләрдә булу да хәзер сирәк күренеш түгел. Һәм, ниһаять, спектакльләр кую өчен башка шәһәрләрдән һәм, хәтта, чит илләрдән режиссерлар чакыру мөмкинлеге туды.

Хәзерге вакытта татар театры үз эшен яңа шартларны исәпкә алып оештыра. Ул киләчәккә оптимизм белән карый. Без бүген Илгиз Зәйниев, Дамир Сәмирханов, Резидә Гарипова, Рамил Гәрәев, Альберт Гаффаров, Лилия Әхмәтова кебек яшь режиссерларның исемнәрен зур горурлык белән атыйбыз. Аларның иҗади үсеше өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Һәр ел саен Яшь татар режиссурасы фестивале «Ремесло», ике елга бер мәртәбә театр белеме бирүне киңәйтү максаты белән «Нәүрүз» форумы уздырыла. Шуны да истә тоту мөһим: киңкырлы иҗади үсешкә ия бүгенге буын – калыплашкан традицияләргә генә түгел, ә дөнья күләмендәге заманча сәнгать үрнәкләрендә тәрбияләнгән сәхнә осталары. Алар иҗат процессында төрле формаларны сынап карыйлар, яңа алымнар эзлиләр, гадәти булмаган, кабатланмаган чишелешләр табалар.

Хәзер инде татар театры милли чикләнгәнлек кысаларында эшләми. Чит илләргә гастрольләргә чыгу, халыкара фестивальләрдә катнашу, спектакльләр кую өчен рус һәм чит ил режиссерларын, рәссамнарын, балетмейстерларын чакырып китерү – болар барысы татар театрының сәнгати чаралары диапазонын киңәйтә. Репертуар да баеганнан-байый бара: сәхнәгә, рус һәм чит ил драматургиясе генә түгел, прозаик әсәрләр постановкалары да күтәрелә. Мәсәлән: Орхан Памук, Эрих Мария Ремарк, Кобо Абэ романнары буенча. Әлмәт татар дәүләт драма театрында вербатим – реаль кешеләр тарафыннан сөйләнгән чын тормыш тарихын гәүдәләндергән

«Язылмаган язмышлар» спектакле күрсәтелде.

Бер үк вакытта тамашачыны җәлеп итү һәм тәрбияләү буенча да эш алып барыла. Социаль челтәрләрдә махсус сәхифәләр бар, төрледән-төрле реклама акцияләре уздырыла – болар яшьләрне тартуга юнәлдерелгән чаралар. Аларның һәркайсы үз нәтиҗәсен бирә. Ә бу өлкәдә иң мөһиме – яшьләрне кызыксындыра торган, заманча, актуаль темаларны күтәргән спектакльләр үзләре. Шулай ук яшь тамашачыларның игътибарын тартырлык, дулкынландырырлык, зур тәэсир калдырырлык үтемле һәм тасвири сәнгать чаралары да бик мөһим. Татар театры үзенең барлык тарихы дәверендә үз тамашачылары өчен якын һәм кадерле булды. Киләчәктә дә бу традиция сүнмәсен һәм сүрелмәсен иде.

**Әдәбият**


*Арсланов М.Г.* Татарское режиссерское искусство (1906–1941). Казань, 1992. С. 97.

*Гиззат Б.* Татарский театр // История советского драматического театра. М.: Наука, 1966. 338.

*Мәхмүтов Х., Илялова И., Гыйззәт В.* Октябрьгә кадәрге татар театры. Казан, 1988.

Татарча театр // Йолдыз. 1911. 1 ноябрь.



***Салихова Айгөл Рөстәм кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

УДК 792.09

***А. Воронин***

# М.Н. ЕРМОЛОВА ИСЕМЕНДӘГЕ МӘСКӘҮ ТЕАТРЫ СӘХНӘСЕНДӘ ДИАС ВӘЛИЕВ ҺӘМ АЛЕКСАНДР ВАМПИЛОВ ДЕБЮТЫ

В статье предпринята попытка сопоставления пьес Д. Валеева и А. Вампилова. Диас Назихович Валеев (1938–2010) в Советском Союзе был самым известным драматургом из Казани. Начиная с 1972 г. его пьесы шли в Москве, Ташкенте и других городах страны. Наибольший успех выпал на долю драмы «Дарю тебе жизнь», которую впервые поставили в Московском драматическом театре имени М.Н. Ермоловой к 50-летию образования СССР. Московский дебют Диаса Валеева совпал с дебютом другого драматурга, Александра Вампилова.

**Ключевые слова:** Диас Валеев, Александр Вампилов, драматургия Татарстана, Московский драматический театр им. М.Н. Ермоловой.

Вәлиев Диас Назыйх улы (1938–2010) Советлар Союзы вакытында Казанның иң күренекле драматургы санала. 1972 елдан башлап, аның пьесалары Мәскәүдә, Ташкентта һәм тагын илнең иллеләп шәһәре сәхнәләрендә куела. Иң югары уңыш яулаган драмасы беренче мәртәбә СССР төзелүнең 50 еллыгы уңае белән М.Н. Ермолова исемендәге Мәскәү драма театрында сәхнәләштерелә, соңрак авторга бу хезмәте өчен ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе (1976) бирелә. Вәлиев өч тапкыр милли драматургия өлкәсендәге Бөтенроссия һәм Бөтенсоюз конкурслары лауреаты була. Диас Вәлиевнең Мәскәү дебюты аның коллегасы драматург Александр Вампилов дебюты белән бер вакытка туры килә. А. Вампилов белән аның туган җире Иркутскида бик хаклы горурланалар, җирле яшь тамашачылар театры Александр Вампилов исемен йөртә, шунда ук аның музее да оештырылган... Иң мөһиме, Вампилов пьесаларын күп театрлар кабат-кабат сәхнәләштерәләр. Ә татар драматургын бөтенләй диярлек оныттылар... Бу һич кенә дә урынлы түгел. Әлеге ике драматург пьесаларын янәшә куеп, аларга кыскача тукталып үтик.

1

Диас Вәлиев белән Александр Вампилов драматургиясен әдәби чагыштыру идеясенең бу ике авторның тәүге пьесаларындагы башлангыч репликалар белән танышкач ук бәхәссезлеге ачыклана. Әйтик, Диас Вәлиевнең «Сквозь поражение» драмасы кичен ике төп геройның тукталышта, көтмәгәндә очрашулары белән башлана.

«С а л и х. Куда вам надо идти сейчас? Туда? Давайте лучше бродить сегодня там, где никогда не бываем. Сейчас восемь часов. Когда стрелка дойдет до двенадцати – разойдемся. Где бы ни были. На любом перекрестке.

Дина. Странно… Это прием у вас такой?»

Диас Валиев геройлары кышын трамвай тукталышында очрашса, Вампиловныкылар җәй көне автобус тукталышында, Таня афиша укып торганда очрашалар.

«Колесов. Девушка, куда вы едете, если не секрет?.. (У афиши). В кино?.. Нет? Ну, значит, на концерт… Тоже нет?.. Куда же вы собрались? Неужели в театр?.. Все ясно. Куда – вы этого сами еще не знаете. А раз так, то идемте со мной.

Таня. Пригласите кого-нибудь другого… И вообще у меня нет времени с вами разговаривать.

Колесов. Это неправда… Вы сколько раз прочли афиши? Скажите честно.

Таня (не сразу). Три. Ну и что?

Колесов. Видите, вам скучно.

Таня (пожала плечами). Просто я смотрю, куда завтра пойти.

Колесов. А сегодня? Куда вы хотите? На танцы? На концерт? На массовое гуляние?

Таня. Все это завтра. Почитайте. А в парке – через неделю.

Колесов. Чепуха! Мы откроем все это сегодня… На первый случай я приглашаю вас на свадьбу».

Танышып китү өчен яхшы башлангыч – Вампилов герое һич белмәгән кызны шунда ук туйга чакыра. Диас Вәлиев исә яшь парны бөтенләй еракка – Җир шары тирәли йөрергә җибәрә, җитмәсә, сәгать телләре һаман саен артка күчерелә тора. 60 нчы еллар модасы нигезендә гадәти булмаган мөнәсәбәт һәм сәер гадәтләр белән кызны гаҗәпләндерү таләп ителә. Вампиловта туй күренеше комедиягә әйләнә, ә Салихның туган көне (Вәлиевта) драмага әверелә. Шушы эпизодтан соң, «Сквозь порожение», «Прощание в июне» әсәренә түгел, «Утиная охота»га (Вампилов) аваздашлана.

Вампилов – Вәлиев янәшәлеге әсәрләрнең төп геройлары Салих белән Зилов образларында күбрәк чагыла, аларны ватан драматургиясендә барлыкка килә башлаган «торгынлык чоры геройлары» үрнәге дип санарга була. Утыз яшен тутырган, хатын-кыз мәсьәләсендә һәм гомумән тормышта өметен җуйган егетләр уңышсызлыкларында, башкаларны, таркалып баручы системаны түгел, ә үзләрен гаепliләр. Бу юнәлештә Вампилов белән Вәлиев, асылда, башлап юл салучылар. Драматургиядә моңа охшаш геройларны Вампиловтан соң, 70 нче еллар ахырында килеп туган «яңа дулкын» авторлары – Виктор Славин («Взрослая дочь молодого человека»дагы Бэмс һәм «Серсо»дагы Петушок. Анатолий Васильев постановкаларында бу образларны Альберт Филозов гәүдәләндерә), Александр Галин («Восточная труба»), Людмила Петрушевская («Уроки музыки»дагы Коля Козлов) һәм Мәскәүнең Алексей Арбузов студиясенә караган башка авторлар иҗат итә.

Салихның да, Зиловның да әтиләре белән мөнәсәбәтләре катлаулы. Локман Самматов заводлар төзи, ә аның уллары, тәрби-

ягә алган этиләренең исеменнән файдаланып, җылы урыннарга урнашалар. Виктор Зиловның да этисе югары урындагы җитәкче булган, бу аның улының «папашка – персональный пенсионер» дип ычкындырган сүзеннән аңлашыла. Әмма Виктор, инженер белеменә ия булса да, Техник мәгълүматлар үзәгендә генә эшли, һәм, эти номенклатура кысаларында калган булса, югарырак урнаша алган булыр идем, дип уйлый.

«Сквозь поражение» һәм «Утиная охота» драмаларындагы сюжет янәшәлеге ресторанда барган сәхнә күренешләре вакытында үзенең кульминацион ноктасына җитә. Вампиловның Виктор Зиловы эчеп исерә һәм анда чакырылганнарның чын йөзен ачарга омтыла, нәтиҗәдә официант Дима аның чыраена берне кундыра. Ә иртән аның торган җиренә «Безвременно сгоревшему на работе Виктору Зилову» дип язылган венок китереп куялар («...Пошутили сволочи») Салих Самматов ресторанда көтмәгәндә-уйламаганда Динаны очрата, ул аны инде күп еллар күрмәгән була. Дина үз ирен көтеп утыра... Ә ире, килгәч, чактан гына Салихның йөзенә сукмый кала. Анда эчеп исергән Салих икенче көнне иртән официантка ятагында уяна («...Все мужики – сволочи»).

2

Диас Вәлиевның «Суд совести» («Охота умножению») пьессасы, Аяз Гыйләҗев тарафыннан татарчага тәрҗемә ителеп, «Намус хөкеме» дигән исем белән Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрында сәхнәләштерелгән. Ә «Дарю тебе жизнь» әсәрен В.И. Качалов исемендәге Казан зур драма театры сәхнәләштерергә алына (спектакльнең премьерасы, автор үзе тәкъдим иткәнчә, «Продолжение» исеме белән 1972 елда була).

Александр Вампилов, Мәскәү театры премьераларына кадәр, туган җирендә – Иркутск яшь тамашачылар театрында (әйтеп үтелгәнчә, ул театр хәзер Вампилов исемен йөртә) куелган спектакльләренең («Старший сын») репетицияләрендә катнаша. К.С. Станиславский исемендәге Мәскәү драма театрында бу ике авторның әсәрләрен баш режиссер Владимир Андреев сәхнәләштерергә уйлый. Әмма театрларның репертуар планнары югары органнар тарафыннан раслана (ә андагы кайберәүләргә Вампилов комедияләре бөтенләй ошамый).

Ермоловалылар шул вакытта, пресса аша, баш режиссерның яшь татар драматургы Диас Вәлиев әсәрен («пьеса о Камазе») сәхнәләштетергә җыенуы турында хәбәр итәләр. Премьера СССР төзелүгә 50 ел тулу уңае белән әзерләнә. Ә Вампиловның «Старший сын» комедиясен режиссер Геннадий Косюков сәхнәгә чыгарырга репетицияләр алып бара. Әмма беренче итеп Вәлиев пьесасы куелачагы аңлашыла.

Икенче яктан, баш режиссерны да аңларга була. Партия җитәкчелеге җитештерү тармаклары эшчәнлеген яктырткан пьесаларның сәхнәләштерелүен таләп итә, ә аңа КАМАЗ төзелеше башлану белән рухланып

язылган «Дарю тебе жизнь» һәрьяклап туры килә. Вампилов пьесалары исә «вак темалар» категориясе белән бара. Брежнев заманында мондый бәяләмә бик түбән санала.

Бу факт, театр тарихчыларын гына түгел, башкаларны да кызыксындырырга мөмкин: Вампилов һәм Вәлиев дебютлары Мәскәүнең бер үк сәхнәсендә бер үк диярлек вакытта бара. Моңа ирешү өчен Александр Вампиловның кыска гына бөтен гомере китә. Диас Вәлиевка башкала уңышына ирешү, үзенең туган ягы Казанда танылуга караганда, җиңелрәк була (аның бу әйтеп үтелгән пьесасы анда берничә атнага соңрак куела).

3

Александр Вампилов белән Диас Вәлиевны М.Н. Ермолова исемендәге Мәскәү театрының әдәби бүлек мөдире Елена Леонидовна Якушкина таныштыра. Зирәк фикерле, зыялы, киң эрудицияле Вампилов Вәлиевта уңай тәэсир калдыра. Гомеренең соңгы көннәре якынлашып килгәндә Диас Вәлиев Вампиловның Ермолова театрының әдәби бүлегендә машинкада басылган кульъязмасы белән танышуы, аның «Старший сын» пьесасының аеруча уңышлы булуы турында исенә төшереп, сөйләп утырды. Әмма элегрәк миңа Диас Назыйх улыннан бу авторның «Утина охота» әсәренә, гомумән аның башка геройларына карата тәнкыйди фикерләр, аларның «бик сай, соры, күңелсез» булуы хакында да ишетергә туры килгән иде. Диас Вәлиевка Вампилов драматургиясендә характерларның масштаблылыгы, дәртлелек җитми.

Александр Вампилов А.М. Горький исемендәге Әдәбият институтында Югары әдәби курсларда (Виктор Сергеевич Розов һәм Инна Люциановна Вишневскаяның иҗади семинарларында) белем ала.

Күрәсең, аның әдәбият институты хакында сөйләүләре Диаска да үз белемен күтәрүне дәвам итәргә кирәклеген искәртә. Биш елдан соң ул М. Горький исем. Әдәбият институты каршындагы Югары әдәби курсларны тәмамлый.

Вәлиев беренче пьесасын язганда, Вампилов инде үзенең барлык пьесаларын да иҗат итеп өлгергән була (бу аның С. Якушкина белән язышкан хатларыннан аңлашыла. «Новый мир», № 9, 1987 ел). Ул әле аларның һәркайсын берничәшәр кат эшли. Шуңа күрә аның башлап язган «Прощание в июне» комедиясе стилистика ягыннан соңгы «Прошлым летом в Чулимске» драмасыннан бер ягы белән дә аерылмый. Ә инде аның «Утиная охота» пьессасындагы тематик яңгыраш һәм драматик чагылыш аның барлык әсәрләрендә дә урын ала, һәм бу сыйфатлар Александр Вампиловның барысы биш пьесадан торган драматургиясен гаҗәеп бөтенлекле һәм җитлеккән хезмәтләр сафына күтәрә. Бәлки шуңа да Якушкина Сашаны «старший сын» дип кабул итә, ә Диасны ул, «младший сын» дип, хәтта ныграк та ярата.

Елена Леонидовна Вампилов пьессалары өстендә авторның

үзе белән бергәләп күп эшли. Якушкинаның төзәтергә һәм редакцияләргә осталыгын Диас Вәлиев тиздән үзе әсәрләре аша да аңлый. Башта алар «Сквозь поражение» өстендә эшлиләр, аннан «Охота к умножению»не эшкәртәләр. Иң нык төзәтелгәне «Дарю тебе жизнь» була.

4

Вампилов белән Вәлиев иҗади омтылышлары белән генә түгел, тышкы яктан да охшашлар: икесе дә бөдрәләнеп торган кара чәчле, кара һәм монголларга хас кысыграк күзле. Мәскәүлеләр өчен алар игезәк туганнар булып тоелырга да мөмкин, җитмәсә, яшьләре дә бер чама (Вампилов Вәлиевтан 9 ай да 10 көнгә генә зуррак). Икесе дә урта буйлы, артык таза да түгел.

Югары әдәби курсларда укып йөрүләре дә Вампилов белән Вәлиев биографиясендәге бердәнбер охшашлык кына түгел. Алар икесе дә провинциядә туганнар.

Иркутск өлкәсенең Вампилов туган Кутулик (бурятчага «чокыр» дип тәрҗемә ителә) соңрак район үзәгенә әйләнә. Диас Вәлиев туган Казанбаш (беренче өлеше «казан»; русчасы – котел, котловина. Бу сүзне дә «чокыр», сөзәк чокыр дип тәрҗемә итәргә була) авылы Татарстанның Арча районында.

Икесе дә балачактан ук әдәбиятка тартылалар. Кутулик мәктәбе директоры Валентин Никитич Вампилов (ялган донос буенча) кулга алынганчы югары сыйныфларда рус теле һәм әдәбияты укыта, һәм өченче улына исемне дә Пушкин хөрмәтенә Александр дип куша («рус поэзиясе кояшы»ның үлгән көнен 1937 елда зурлап билгеләп узалар). Әтиләрен атып үтергәннән соң да (ул 1957 елда гына реабилитацияләнә) аларның өйләрендә китаплар күп була. Әниләре үзе математик булса да балаларын рус классикасына кечкенәдән тарта.

Диас Вәлиевка килгәндә, аның әнисе күренекле татар язучысы Гадел Кутуйның бертуганы була. Ә әтисе – партия хезмәткәре – улы туганда шулай ук репрессияләнгән була. Саша да, Диас та яшерен рәвештә әтиләрен көтәләр, кешеләрнең үзләренә кырын каравын авыр кичерәләр... Вампиловка да, Вәлиевка да мәктәптән соң университетка керүдә (гаепсез әтиләрнең гаепсез балаларына каршылыклар булмый. Шуны да әйтергә кирәк: Себердәге Иркутскиның даны һич кенә дә Идел буе Казаныныкыннан ким булмый. Егетләрнең икесенең дә яшьлеге Хрущев «җепшеклеге» чорына туры килә, университет яшьләре яңа омтылышлар, яңа исемнәр белән рухланып гөр килә. Булачак драматурглар университет тормышының үзәгендә кайный. Икесе дә анда уку елларында хикәяләр яза башлый һәм үз шәһәрләрендәге иң җанлы әдәби берләшмәләргә йөри.

Минемчә, Александр Вампилов дусларыннан аеруча уңа. Иркутскиның әдәби түгәрәкләренә ул елларда Валентин Распутин, Вячеслав Шугаев, Марк Сергеев кебек алда зур танылу яулаячак язучылар йөри. Алар соңыннан да күп еллар бер-берсе белән араларын өзмиләр, бергә Байкалда

булалар, анда җәй көннәрендә аерым өй алып, әдәби коммуна оештыралар, язалар, аны бер-берсенә укыйлар, иҗатлары хакында фикер алышалар.

Дөрес, Диас Вәлиев та яхшы төркемгә эләгә – анда шагыйрьләр Юрий Макаров, Вил Мостафин, Николай Беляев була. Бу шагыйрьләр Иркутскидагы кебек «көчле төркем» буларак танылада алмагандыр, чөнки алар, себерлеләр кебек, бердәм, бер-берсенә ярдәм итәргә омтылып тормыйлар. Хәер, провинция шәһәрләрендәге язучылар даирәсенә һәрчак аерымлану хас (хәзер ул бөтенләй чиктән тыш дәрәҗәдә). Мөгаен, башлап язучыларның үзара дуслык шартларында иҗат итүе, бер-берсен күтәрергә тырышуы аерылып торган әдәби төркемнең башкалада түгел, ә әллә кайдагы Иркутск шәһәрендә оешуы ярты гасырга бер була торган очрактыр. Алар, араларындагы иң зур танылу алачак Валентин Распутин кебек, «авыл гыйбадлары» булмый, аларны әдәби омтылыш, Әдәбиятның үзенә мәхәббәте берләштерә.

Вампилов белән Вәлиевның әдәбиятка юлы журналистикадан башлана. Һәм шунысы да характерлы – алар икесе дә яшьләр газетасында эшлиләр. Хәзер генә ул һәр шәһәрдә дистәләгән исемдәге газета һәм журналлар чыгарыла, ә совет чорында һәр нәрсә лимитлаштырылган иде. Әйтик, өлкә (Иркутск) һәм республика (Татарстан, Казан) үзәкләрендә бер партия һәм бер – комсомол газетасы чыгарылды. Аерым очракларда «кичке» басмалар рөхсәт ителде, алар, нигездә КПССның өлкә комитеты басма органы буларак һәм, чыннан да, кичке якта басылды (хәзерге мондый ваклыклар онытылды, «кичке» дип аталганнары да иртән басылып чыга). Димәк, ул елларда, эре заводлар каршында оештырылган күп тиражлы басмаларны санамаганда, каләм тирбәтүче провинциалларга сайланып тору мөмкинлеге юк иде. Андый шартларда яшьләр газетасы бик үк кулай басма булмый, әмма практик яктан алар иҗади планда иң җанлы һәм иң популяр редакция саналалар.

Журналист буларак бу ике автор да хәзер онытылып бара торган очерк жанры өстендә күп эшлиләр. Һәм алар икесе дә зур комсомол төзелешләрен яктыртуда юл салучылар булдылар. Иң мөһим төзлешләрдән Вампилов өчен – Усть-Илим ГЭСы (Ангарада беренче плотина аеруча зур әһәмияткә ия була, аның хакында Евгений Евтушенконың «Братская ГЭС» поэмасы языла. Вампилов ул чакта яшь була әле), ә Вәлиев өчен Яр Чаллыдагы Кама автомобиль заводы санала. Диас Назыйх улы 1969 елның декабрендә автошәһәр төзелеше башлану турында СССРда беренче булып хәбәр җиткергән язмасы хакында һәрчак зур горурлану белән искә ала иде. Ул чакта заводның рәсми атамасы да билгеле булмый, күпмедер дәрәҗәдә гарәпчәрәк яңгыраган «КАМАЗ» аббревиатурасын әле беркем дә ишетмәгән була.

5

Вәлиев һәм Вампилов пьесаларын чагыштырганда аларның тышкы янәшәлекләреннән үк ми-

салларны күпләп китерергә мөмкин. «Сквозь поражение» белән «Утиная охота»ны чагыштыру белән генә чикләнеп калу дөрес булмаячак. Җентекләбрәк күзәткәндә «Охота к умножению» белән «Прошлым летом в Чулимске» пьесаларында да уртаклыклар шактый. Бу ике әсәрнең дә геройлары тикшерүчеләр («следователи») булып эшлиләр. «Пророк и черт»ның баш герое һәм «Двадцать минут с чертом»дагы Хомутовны да күп кенә сыйфатлар бәйли. Мондый мисалларны күпләп китерергә була.

Авторларның соңгы пьесаларында уртаклыклар аеруча күзгә ташлана. Диас Вәлиев үзенең «Карликовый буйвол» әсәрен триллер жанры итеп билгеләсә, А. Вампилов язылып бетмәгән «Несравненный Наконечников»ын водевиль (көлкеле пьеса) дип атый. Шуңа да карамастан ике фантасмагориянең дә фарс нигезе ап-ачык. Чагыштырып тасвирланган ике авторның да бу пьесаларын язу ирегe ул әсәрләрнең иң яхшы иҗади хезмәт булуын раслый.

Ни кызганыч, «Наконечников» язылып бетмичә кала, А. Вампилов үзенең 35 еллыгы алдыннан һәлак була. Ә Вәлиевның «Буйвол»ы сәхнәгә күтәрелә алмый, чөнки анда сурәтләнгән ил юкка чыга, таркала. Ә «яңа» Россия драматургиядә үзенә яңа кумирлар сайлый.

***Воронин Александр Геннадьевич,***
*Язучы, драматург, театр тарихчысы, Россия язучылар берлегенең Татарстан бүлеге Казан оешмасы рәисе*

УДК 792.03:76

***Р.Р. Солтанова***

# ПЛАКАТ СӘНГАТЕНДӘ ТАТАР ТЕАТРЫ ТАРИХЫ (1906–1930 еллар)

Впервые на основе коллекции музеев (НМ РТ, ОРК КФУ, ЦП и МН ИЯЛИ и др.) воссоздается история возникновения и становления плакатного искусства в татарском театре. Анализируются содержание и стилистика афиш и плакатов с начала XX века до середины 1930-х гг. Акцентируется внимание на авангардных явлениях в искусстве плаката в конце 1920-х гг. Театральная афиша, в отличие от спектакля, продолжает жить автономной жизнью, полностью сохраняя свою самодостаточность во времени и пространстве, является ценным документом эпохи, повествующим о репертуарной политике театра, об авторах постановки, исполнителях; о вкусах зрителей и эстетических потребностях времени, т.е. о театральной политике своей эпохи.

**Ключевые слова:** татарский театр, зритель, афиша, театральный плакат, реклама, театральный художник, конструктивизм.

Тасвири сәнгатьнең үзенә бер төре саналган Казан плакаты турында күп кенә әдәби хезмәтләр бар [Корнилов; Улемнова, 2014; Улемнова, 2005; Червонная]. Реклама белән сәнгатьнең мөстәкыйль әсәрләре чигендә балансланган үзенчәлекле жанр ул – тулы кыйммәтле художство образы. Әмма ул әлегә тиешенчә өйрәнелмәгән һәм тулысынча җыеп бетерелмәгән.

Сәнгать тарихчысы, сәяси плакатларны өйрәнеп тикшерүче П. Корнилов Казанда плакат барлыкка килүне Февраль инкыйлабы һәм рәссам К. Чеботарев [Корнилов, с. 4] исеме белән бәйле, аның 1920 елларда Ф.П. Гаврилов җитәкләгән Дәүләт сәнгать остаханәләрендә югары үсешкә ирешүен болай дип белдерә: «Как никогда этот вид изобразительного искусства как величайшего социального фактора и средства воздействия в массы» [Корнилов, с. 1].

Рус театр плакаты тарихын өйрәнүгә беренче адымнарны Ю. Благов белән Е. Ключевский ясый [Благов, Ключевская, с. 89–99]. 2002 елда «Казань» журналында бастырып чыгарган мәкаләләрендә алар ике йөзьеллык дәвамындагы (1836 елдан алып бүгенге көнгә кадәр) театр афишаларына гомуми күзәтү ясыйлар, аннан мәгълүм булганча, иң якты үрнәкләр Казан шәһәр театры һәм Казан Зур театрына карый.

Хәзерге вакытта татар театр плакатын анализлауга багышланган махсус тикшеренүләр, Б. Гыйззәтнең газетада басылган мәкаләсеннән кала [Гиззат], юк дәрәҗәсендә. Бүгенге театр плакаты казанышлары беренче тапкыр 2003 елда «Современная сценография Татарстана» рес-

публика күргәзмәсендә күрсәтелде, аның нәтиҗәләре шул ук исемдәге каталогта басылып та чыкты [Султанова, 2003].

XX гасыр башыннан хәзерге көнгә кадәр тупланган йөзләрчә данәдәге афишаларның уникаль үрнәкләре театр архивларында, ТР Милли музеенда, С. Сәйдәшев музеенда, Казан федереаль университеты китапханәсендә, ТР ФАнең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты (алга таба – ТӘһСИ) Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана.

Аларны Татар дәүләт академия, Татар художество эшчеләр («Эшче»), Колхоз-совхоз (күчмә) театрлары афишалары тәшкил итә. Афишалар Казандагы И.Н. Харитонов типографиясендә, «Татполиграф»та 100, 200, 250 (гастроль спектакльләре өчен сирәк кенә 500) данәдә басылган. Бу плакатлар зур форматта (48×72, 97×75, 76×108) эшләнгән.

Спектакльләр Сәүдәгәрләр собраниесе, Зур театр, Шәрык клубы, «Рус Швецариясе» биналарында һәм башка йортларда куела. Татар театры формалашу чорында Казандагы театр тормышының турыдан-туры шаһиты булган афишалар аеруча кызыксыну уята. Күп кенә афишалар үзешчән дәрәҗәдә генә бизәлгән булсалар да, ул чорның плакат сәнгате татар театры тарихының гаҗәеп кызыклы сәхифәләрен ача.

Шуңа да игътибар итәргә кирәк, плакат материалларын өйрәнгәндә җитди генә кыенлыклар белән очрашырга туры килә: әйтик, даталары куелмау, үлчәмнәре, тиражлары, авторларының билгесезлеге, нәшриятлары күрсәтелмәү – болар барысы да плакатларда күтәрелгән темаларны тулырак ачыклау өчен таләп ителгән библиографияне төгәл эшләргә комачаулый.

Булган хәтле материалларны анализлау күрсәткәнчә, плакат авторлары үз эшләрен яхшы белгәннәр һәм, тамашачы зәвыгын истә тотып, реклама продукциясе булган афишаларга карата куелган төп таләпләрне үтәргә тырышканнар.

Беренчедән, һәр плакатка хас булганча, театр плакатына да күпсүзлелек рөхсәт ителми. Лаконизм, кыскалык – бу жанрда иҗат итүче рәссам өчен закон. Театр плакатын катлаулы ребуска әйләндерергә ярамый, шулай да, һәр сәнгать әсәрендәгечә, монда да тамашачыны җәлеп итү өчен ниндидер серлелек булырга мөмкин.

Сәнгатьнең синтезга нигезләнгән төре буларак, тасвири һәм сәхнә сәнгате плакатының әдәби образлылыгы түбәндәге таләпләргә җавап бирергә тиеш: композиция осталыгы, график һәм сынлы тәэсирлелек, полиграфик таләпләрне истә тоту. Шул ук вакытта афиша спектакльнең идея һәм сәнгати үзенчәлеген, конкрет бер коллективта аның стилистик гәүдәләнешен, ягъни театр постановкасының эстетик рухын тамашачыга җиткерә дә алсын.

XIX гасыр ахырында әле гаилә спектакльләре рәсми белдерүләрсез һәм билетлар сатылмыйча гына уздырыла. Алар турында тар даирә кешеләре генә белә.

Татар театр афишасы формалашу беренче театр труппалары

«Сәйяр» (1907) һәм «Нур» (1912) эшчәнлеге белән бәйле.

Татар театрының беренче афишасы 1905 елда гомум инкыйлаби күтәрелеш чорында барлыкка килә. Б. Гыйззәт язганча, ул төсле бизәлештә һәм рус телендә була [Гиззат]. Анда Россиядә беренче тапкыр мөселман артистлары труппасының рус һәм татар телләрендә спектакль күрсәтүе игълан ителә. Программада: А. Грибоедовның «Горе от ума» һәм Н. Гогольнең «Ревизор», шулай ук А. Островскийның «Свет и тьма» (ирекле тәрҗемәсе – «В чужом пиру похмелье») комедияләреннән күренешләр.

Бу, чыннан да, зур форматтагы һәм тамашачы зәвыгы, ихтыяҗы һәм үзенчәлеге исәпкә алып эшләнгән реклама афишасы була. Спектакльне оештыручылар татар хатын-кызы спектакльгә бармас, чөнки анда аңа бөркәнчексез, чит ирләр арасында утырырга туры киләчәк дип, газетада басылган белдерүләрдә дә, афишада да бельэтажның фәкать хатын-кыз тамашачы өчен генә билгеләнүе, теләгән мөселман хатын-кызлар өчен анда нәфис вуаль битлек тә булуы махсус күрсәтелә. Бельэтажга керү, коридор һәм тышкы киемне саклау өчен көйләнгән элгечләр ир-атлар үтеп кермәслек итеп көйләнә. Хезмәт күрсәтүчеләр руслар була [Кумысников, с. 35].

Оренбургта беренче профессионь труппаны оештыручы И. Кудашев-Ашказарский, тамашачыларны күбрәк җәлеп итү өчен, афишалар бизәлешендә татар публикасы яратып карый торган цирк программалары афишасы рәвешендәге кабарынкы (катлаулы) итеп эшләнгән формалардан файдалана[1]. И. Кудашев-Ашказарскийның «Наданнар илә галимнәр», А.П. Чехов хикәяләре буенча сәхнәләштерелгән «Хирургия» һәм «Гыйлем тәшрих, касыйд» спектакльләреннән соң кичә программасына, төп спектакльгә өстәмә рәвешендәге декламация, җыр, бию кебек номерлардан тыш, фейерверк та кертелә.

Дин әһелләре театр эшчәнлегенә фанатикларча каршы чыксалар да, беренче татар труппасын оештыручылар, үзләре дә кайчандыр мәдрәсә шәкертләре булганлыктан, исламга хөрмәт белән карыйлар. Мөселман бәйрәмнәре уңае белән төрле урыннарда спектакльләр күрсәтәләр. Мәсәлән, 1913 елның 28 октябрендә Корбан бәйрәме хөрмәтенә Мөселман драма артистлары ширкәтенең «Нур» күчмә труппасы Оренбургның шәһәр театрында Кавказ мөселманнары көндәлек тормышын яктырткан «Мусибәт Фәхретдин» трагедиясен (Н. Вәзир-Задә әсәре, Г. Нугайбәк тәрҗемәсе) күрсәтәләр. Анда труппадагы һәркем катнаша. Афишасы нәсех стилендә эшләнгән.

ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИнең Язма һәм музыкаль

[1] Цирк в Казани ведет свое начало от цирка братьев Никитиных, для которого в 1890 году было построено специальное здание [Татарстан: иллюстрированная энциклопедия, с. 772].

мирас үзәгендә саклаңган тагын бер афиша бар. Анда И. Кудашев-Ашказарский труппасы тарафыннан «Луна-парк» бакчасы театрында зур кичә оештырылачагы, «Әдәпсезләр» спектакле күрсәтеләчәге, шулай ук 1918 елның 30 июнендә Ураза бәйрәме хөрмәтенә «Мескен Фатих» спектакле куелачагы хәбәр ителә.

1920 еллар ахырына кадәр афишаларда цирк тамашалары элементлары кулланыла. Мәсәлән, 1918 елның гыйнварында Г. Монасыйповның «Ирем кайтты», «Имчеләр корбаны» спектакльләре өчен чәчәк орнаментлары чигелгән кулъяулык рәвешендә бизәлгән афиша программасында «На вечере дивертисмент, танцы, лотерея, американский аукцион, серпантин и др.» дигән сүзләр дә язылган [Г. Камал театры архивы].

Гастроль афишаларын бизәүдә дә цирк элементлары кулланыла. Мәсәлән, Г. Камалның «Бәхетсез егет» спектакле постановкасы өчен әзерләнгән афиша текстына диагональ буенча рус телендә һәм нәсех стилендәге (гарәп язуының бер төре) татар вариантында болай дип язылган: «Зал һәм киосклар көнчыгыш зәвыгынча бизәлә. Антракт вакытында оркестр милли көйләр башкарачак. Спектакльдән соң биюләр, конфетти көрәшләре, серпантин, бомбачыклар, очучы почта булачак» («Казан» милли мәдәни үзәгенең даими экспозициясе).

Театр афишасының беренче рәссамы дип бик хаклы рәвештә драматург Галиәсгар Камал исемен атый алабыз. Татар шрифтларының утызлап яңа төре (аларның егермедән артыгы 1909 еллардан И Харитонов типографиясендә китаплар басуда кулланыла) барлыкка килүдә дә аның хезмәте зур [Каримуллин, с. 52]. Плакат сәнгатендә татар театр афишаларының мөстәкыйль график жанры буларак формалашуы да Г. Камал исеме белән бәйле. Л. Аитов искә алганча, афишаларны, типографиядә бастырудан бигрәк, кулдан эшләргә тырышалар. Гарәп каллиграфиясен яхшы белүче Г. Камал үзенең улы Әнәс белән һәр спектаклгә 40–50 шәр афиша эшли [Аитов, б. 105–106]. Алар хәрефләрдән генә төзелмиләр, ә Г. Камал рәсемнәре төп урынны биләгән чын сәнгатьчә композицияләрне тәшкил итәләр. Авторның үз бенефисы афишасы аеруча матур бизәлгән була. Профессионал каллиграф буларак, Г. Камал афишаларда төрле типтагы һәм үлчәмдәге хәрефләрне төрле декоратив орнаментларга охшатып эшли. Әйтик, 1914 елның 22 декабрендә Яңа клубта куелган «Уйнаш», 1916 елның 15 августында күрсәтелгән «Кеч-кенә сугыш», «Җилкуарлар» спектакльләре постановкалары өчен әзерләнгән афишалар, нәсех стилендәге бизәкле каллиграфик иҗат үрнәге булып хезмәт итәләр (болар Татарстан Республикасы Милли музеенда саклана). Шунысы да мөһим, баштагы дистә елларда театр аерылып тора. Аларда, спектакль исеменнән, анда катнашучылар һәм башкаручылар исемлегеннән тыш, спектакльдән соң уздырыла торган музыкаль кичәләр яки башка

чараларның программалары да күрсәтелә. Мәсәлән, 1908 елның 24 ноябрь датасы куелган афишада түбәндәгеләр язылган: «Поиск жениха, или беда позорного объявления». Затем литературный вечер и танцы. Прочее: С. Рамиев и Г. Тукаев будут читать свои последние стихи. Оркестр татарской молодежи будет играть национальные мелодии. В спектакле участвуют: Гиззатуллина, Булгарская» (нәсех почеркы; ТӘһСИ Язма һәм музыкаль мираз үзәге архивы).

Тамашачыларны күбрәк җәлеп итү максаты белән кайчакта спектакль исеменә аңлатма бирелә. Мәсәлән: «1914 елның 22 декабрендә Яңа клубта А. Кариев җитәкчелегендәге Мөселман драма артистлары ширкәте «Уйнаш» спектаклен күрсәтә». Шунда ук аста кириллица хәрефләре белән болай дип тә өстәлгән: «Каенана өйдә булса, өйнең асты өскә килә». «Керү рекомендация буенча түгел. Антракт вакытында Фишкин җитәкчелегендә оркестр уйный».

Беренче Бөтендөнья сугышы чоры мәгълүматларга байлыгы һәм почеркларының төрлелеге белән аерылып тора. ТӘһСИ Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә куфи һәм нәсех стилендә эшләнгән плакатлар бар. Аларның да аскы өлешендә тамашачыны җәлеп итү максаты белән яки алдагы спектакльне анонслаган өстәмә мәгълүматлар урнаштырылган. Мәсәлән: «1. “Май мәсьәләсе”. 2. “Казанга сәяхәт”. Гомумроссия һавада йөзү флоты файдасына хәйрия спектакле (1913 ел, 14 июнь)». 1914 ел, 14 февраль датасы куелган икенче плакатта мондый юллар бар: «“Бер сәгатьлек хатын” спектакле. 12 яшьлек җырчы Фатыйма Гомәрова концерты. Х. Гомәров башкаруында декламация. Биюләр. Биюләр вакытында Каргапольский полкы оркестры уйнаячак».

1914 елдан башлап, афишаларда театр эмблемалары кулланыла башлый. Алар сәхнәнең ян декорацияләре рәвешендәге рамкада бирелә, башына такыя кидерелгән хатын-кыз рәсеме (элек аның урынында саз (лира) гына булган) эшләнә, нәсех стилендә спектакль исеме күрсәтелә: мәсәлән, А. Чеховның «Аю», Г. Камал куйган «Анасы кабере өстендә».

1918 елның 15 гыйнвары датасы куелган, инкыйлаби дәвер өчен типик саналган афиша: «Хәрби патриотик кичә. «Денщик Гали» спектакле. Дивертисмент (шигырьләр, музыка, җырлар, биюләр, балет, хикәя, декламацияләр; кавалеристлар, эскадроннар җырлый, курайда уйный, гимнастлар чыгышы, хәрби уеннар). Биюләр» (ТӘһСИ Язма һәм музыкаль мирас үзәгеннән).

Мондый плакатларда, инкыйлаби романтикадан тыш, ура-патриотизм элементлары һәм гади кешеләрнең газаплы тормышы, сугыштан соңгы җимерекләр авазы да чагылыш тапкан.

XX гасырның беренче дистәләрендә эшләнгән афишалар стилистика ягыннан үзләренең ачыктан-ачык декоративлыгы, гарәп язуының катлаулы формаларын куллану, үз заманы сти-

ленә (модерн) якын милли орнаментлар куллану белән аерылып торалар, шуның өстенә алар инкыйлабка кадәр басылып чыккан татар китаплары бизәлешенә (китап бите өстендәге орнамент, кайма, виньетка һәм зигзаг, ромб һ.б. рәвешендәге бизәкләр) дә охшашлар.

Шушындый төрлелеккә дә карамастан, ул чор афишалары реклама характереындагы полиграфик продукция булып кына саналалар, 1920–30 еллар плакат сәнгате кебек сәнгати кыйммәткә дәгъва кылмыйлар.

1920 елларда татар театр афишалары бизәлешендә конструктивлык һәм массакүләм агитация сәнгате эзләре күзәтелә. Бу очракта, беренче чиратта, эксприменталь театр (КЭМСТ) йогынтысына игътибар итәргә кирәк. Анда М. Барашов, К. Чебатарев, В. Фоминых, С. Хромов кебек афиша турындагы гадәтләнгән күзаллауларны юкка чыгарырга омтылган рәссамнар эшли. Афишалар артык күпсүзлелектән арындырыла, анда театрның һәм спектакльнең исемнәре куела, авторы күрсәтелә, куючыларның (режиссер, рәссам, композитор, балетмейстер, төп рольләрне башкаручыларның) исем-фамилияләре языла. Тагын бер үзенчәлеге – спектакльнең исемен эре итеп фигуралы хәрефләр белән, төп фонга контраст төстә язу (гомумән, текстны фоннан нык аерып торган төсләр белән бирү).

Рәсем графикасын кулланудан ваз кичеп, типографик алымнарга күчү текстны яңача урнаштыруга юл ача: сүзләр өлешләргә бүленә, диагональ буенча яки баскычлап һәм түгәрәк рәвешендә аркылы-торкылы урнаштырыла. Конструктив плакатларны өйрәнеп тикшерүчеләр «1917 елга кадәр театр афишаларында моның беркайчан да булганы юк иде», дип язалар [Лапина, с. 57].

Моңа мисал итеп Ш. Камалның «Ут», К. Тинчуринның «Ил» пьесалары буенча сәхнәләштерелгән спектакльләр афишаларын китерергә була. «UT» һәм «IL» сүзләре аларда ак фонга эре итеп кызыл хәрефләр белән язылган. «Отелло» спектакле плакаты да шундый кыскалыкка ия. Аның беренче хәрефе – О плакат кәгазе биеклегенә сузылган. «ODVA» (Одва) сүзенең хәрефләре кызыл флаг фонындагы визуаль орнаментны хәтерләтә. Спектакльнең исемен стильләштерелгән хәрефләр белән бирү – аның рухын һәм характерын чагылдыра (мәсәлән, Т хәрефе чүкечне хәтерләтә). Тагын бер характерлы үзенчәлек – контраст төсләрдә (кара – ак, кызыл – кара, ак – кызыл) эре хәрефләр белән өчпочмаклап һәм квадрат рәвешендә стандарт хәрефләрдән җыелган афиша текстлары татар тукучылык бизәкләрен күз алдына китерә. Хәрефләрдән тупланган гадәти типтагы афишаларда бер яки ике төстәге буяулар кулланылса, гастроль спектакльләре афишалары өчен берничә төс (сары, көрән, бронза төс) файдаланыла. Күфи стилендәге хәрефләр куллаңылу экспериментлары аеруча кызыклы, алар конструктив ачыклауга мохтаҗ.

К. Тинчуринның «Американ» пьессасы буенча 1924 елның

19 мартында сәхнәләштерелгән спектакльнең афишасы чәчәкле күфи стилендәге бормалы хәрефләр белән бизәлгән булса, ә инде кичәнең 14 февраль датасы куелган 1929 елның көнчыгыш клубтагы афишасы нәсех почеркына охшатылган геометрик күфи белән матур һәм зәвыклы итеп эшләнгән. Театрның 20 еллыгына (1926 ел) багышланган тантаналы кичә афишасы бик зур форматта һәм, шулай ук, аның бизәлешендә дә күфи стиле кулланыла.

Биредә беренче тапкыр балалар труппасы репертуары («Тычканга үлем, мәчегә көлке») һәм Театр техникумы студентлары чыгышы («Беренче адым») хакында да белдерелә.

Һәркемгә мәгълүм булганча, 1920 елларда татар театрында куелган беренче авангард спектакльләр – татар театр техникумының Р. Ишморат һәм КЭМСТ, шулай ук актер, режиссер Әсхәт Мәҗитов (1900–1946) оештырган һәм үзе үк иҗатка рухландырган «Бомба» [Солтанова, 2010, с. 549–560] коллективы белән хезмәттәшлектә алып барган эшчәнлеге нәтиҗәсе.

Кызганычка каршы, авангард спектакльләр плакатлары әз сакланган. КФУ коллекциясендә андый тамашаларның характеры һәм эчтәлеге турында күзаллау тудырырга ярдәм итә алган берничә афиша бар. Мәсәлән, сәнгать техникумының театр бүлеге әзерләп чыгарган беренче төркемнең педагоглары М. Мәһдиев җитәкчелегендәге күрсәтмә спектакле бию номерлары белән баетылган хор, оркестр катнашында уза. Рәссам Никандров (исеме күрсәтелмәгән) тарафыннан бизәлгән афишада тамашаның катнашучылары – татар театрының булачак артистлары: Үтәшев, З. Бикбулатова, Х. Гыйльманов, Ф. Нагаева, Г. Мансуров, Г. Хәкимовлар күрсәтелгән.

Нәкъ менә сулф (сул фронт) юнәлеше рәссамнары һәм режиссерлары афишалар эшләүдә беренче булып киномонтаж алымнары, цирк элементлары кулланалар. Мәсәлән «58» спектакле афишасында шундый мәгълүматлар бирелгән: С Вәлиева-Сульва иҗаты, 4 пәрдәдә, 16 күренештә, режиссеры – К. Тинчурин, музыкаль бизәлеш авторы – С. Сәйдәшев, рәссамы – П. Сперанский (латин хәрефләре белән татар һәм рус телләрендә язылган).

Театрның художство җитәкчелегенең, актерларның фотографияләре төрле конфигурациядә (җилпәзә рәвешендә, диагональ яки вертикаль буенча) урнаштырылган коллаж барлыкка килә, шунда ук алдагы репертуар (классика, оригиналь әсәрләр, тәрҗемә спектакльләр) санап үтелә, хәтта спектакльнең макеты урнаштырыла.

1920 еллар ахырында – 1930 еллар башында афишаларда әйдәүче актерларның фотографияләре бирелә башлый. Мәсәлән: 1927 елның 27 гыйнварында куелган «Таһир – Зөһрә» спектакле исеме афишада диагональ буенча нәсех стилендә язылган, ике як читендә Ф. Ильская белән М. Мәһдиев фотографияләре урнаштырылган (ТР Милли музее).

1932 елның 16–17 ноябре датасы куелган афишада төп рольләрне уйнаучы актерлар янә-

шәсендә артистка Нәфига Арапованың да катнашуы турында өстәмә мәгълүмат җиткерелә. «Отелло» спектакленең яңартылган куелышында Отелло ролендә Мөхтәр Мутин уйнаячагы белдерелә. Халык артистлары С. Гыйззәтуллина-Волжская белән Г. Болгарская, атказанган артист К. Тинчурин исемнәре афишаларда еш кабатлана.

Бу афишаларны бизәүче рәссам-авторлар турында фикер йөртеп булмый, чөнки алар имзаланмаган. Ул елларда бу эшне «Татполиграф» типографиясе хәреф җыючылары, хәреф кассаларындагы мөмкинлектән чыгып, эксперимент рәвешендә үзләре башкаралар.

XIX гасыр рус театры афишаларында киң кулланылганча, көчле индустриаль үсеш алган дәвер үзенчәлекләрен характерлый торган элементлар да барлыкка килә башлый. Ул эмблемалар күп төрле. «Үлмәс ханым» спектакленең 1926 ел, 5 февраль датасы белән эшләнгән афишасында эклектик формада гына Татар дәүләт академия театры эмблемасы урнаштырылган. Гадәттәгечә ул өстә уртага, икегә аерылган тешле тәгәрмәч фонында битләренә каурыйлар ясалган ачык китап рәвешендә бирелгән, театрның исеме рус һәм гарәп графикасында вак хәрефләр белән татар телләрендә язылган. Ә өстә – РСФСР гербы.

С. Сәйдәшев музеенда безгә 1920 еллар ахыры – 1930 еллар башында эшләнгән афишаларда тасвири элементларга бай эмблемаларны да очратырга туры килде. Беренче планда төзелеш вышкалары, биек-биек йортлар белән гәүдәләндерелгән индустриаль пейзаж, аның фонына заманча символлар: уңда трактор, сулда – китаплар урнаштырылган. Композициянең үзәгендә, тешле тәгәрмәч фонында битләренә каурыйлар һәм урак белән чүкеч фонында – театр маскасы. Шунда ук ТДТ (Татар дәүләт театры) аббревиатурасы бирелгән. Татар дәүләт эшчеләр театры эмблемасы игътибарга лаек, ул К. Чеботарев линогравюралары рухында иҗат ителгән, аның җилфердәп торган байрак фонында пролетариат фигурасы калкып тора. Режиссер Ә. Мәҗитов тарафыннан 1935 елда куелган «Саклан, шартламасын!» спектакленең премьерасында рәссам А. Силантьев исеме беренче тапкыр искә алына (аңа кадәр ул исем театрга багышланган хезмәтләрдә очрамый).

1920 еллар ахыры – 1930 еллар башындагы театр афишалары яңа пролетар тамашачы барлыкка килү турында гына түгел, ә сәнгатьнең яңа төре саналган театрга халыкны күпләп җәлеп итү максаты белән дәүләт һәм театр җитәкчелеге күргән чаралар хакында да хәбәр итә. Гади тамашачыны театрга тарту дигәндә, аның үз-үзен тотышында этик һәм эстетик гадәтләр формалаштыру күздә тотыла. Мәсәлән, афишада спектакль исеменнән тыш, тагын шундый киңәшләр дә тәкъдим ителә: «Өченче звоноктан соң тамаша залына керү тыела. Тышкы өс киемен салу мәҗбүри. Билет бәясе 50 тиеннән алып 1,5 сумга кадәр. Ташламалы билетлар сатыла».

Абонемент системасы кулланыла башлый. Мәсәлән, «Кандыр буе» спектакле афишасында мондый юллар бар: «предприятиеләр заявкалары буенча 30–40% ташлама ясала, 3, 5, 8 сумлык абонементлар сатыла». «Үз өлкә бүлекләре гаризасы буенча килешү төзегән профсоюзларга һәм фабзавместкомнарга билетлар кредитка бирелә» (1932 елның 6–9 декабре датасы белән Ф. Борнаш пьессасы буенча «Тукучы Әсма» спектакле премьерасы өчен эшләнгән афишадан. Ул КФУ коллекциясендә саклана).

Театрларга махсус рәвештә эшчеләр культпоходы оештырыла. Мәсәлән, Г. Минский пьессасы буенча С. Вәлиева-Сульва сәхнәләштергән «Одва» спектакле (рәссамы П. Сперанский) 1931 елның 11 мартында Пролетар районы эшчеләре өчен генә күрсәтелә. Ә 1933 елда К. Нәҗми пьессасы буенча режиссер К. Тинчурин куйган «Булат бабай семьясы» спектакле (рәссамы П. Сперанский, балетмейстеры Г. Таһиров) «Социалистик кырлар һәм терлекчелек» ударникларының һәм колхозчыларның II съездында күрсәтелә. Казанның хезмәт ударникларына һәм яхшы җитештерүчеләренә театр билетлары барлык сезонга да 40%лы ташлама белән сатыла, алар өчен даими урыннар калдырыла. 16 яше тулмаган балалар театрга кертелми. (К. Тинчурин пьесасы буенча куелган «Беренче чәчәкләр» спектакле премьерасының 1935 ел, 14–16 февраль датасы белән эшләнгән афишасы латин хәрефләре белән язылган. Рәссамы М. Абдуллин.)

Татар афишалары һәм плакатлар театрларның репертуарларын ачыкларга, әсәрне сәхнәләштерүчеләрнең (режиссерлар, рәссамнар, композиторлар һ.б.ның) элеккеге белешмәләрдә искә алынмаган һәм мәгълүм басма китапларга кертелмәгән исемнәрен торгызырга да ярдәм итә.

Күчмә колхоз-совхоз театры спектакльләре афишалары беренче елларыннан ук профессиональ рәссамнар тарафыннан бизәлә. Әйтик, 1935 елның 5 декабрендә режиссер С. Өметбаев куйган «Шартлау» постановкасы афишасында Грибков фамилиясе (инициалы юк) бар. «Вөждан» спектаклен (режиссер С. Вәлиева-Сульва, композиторы С. Сәйдәшев) афишасын рәссам Ю. Антонычев эшләгән. Тагын шундый формалар да булган: афишаларда төп репертуараны санап чыгу белән бергә, алдагы коцертта Ә. Камал җитәкчелегендә атаклы комик Х. Шөнкәр белән гармунчы Г. Шәүлеханов катнашачагы турында гына түгел, ә театр алдында торган төп бурычлар, әйтик, пролетар сәнгать социализм төзүдә, ленинчыл коммунистлар партиясе директиваларын тормышка ашыруда һ.б.да иң көчле корал булып саналуы да әйтелә. (КФУ коллекциясеннән).

Н. Островскийның 1938 елда сәхнәдә татарчалаштырып куелган «Корыч ничек чыныкты?» спектакле (режиссеры Б. Фердинандов, музыкаль бизәлеш авторы Б. Виноградов, хормейстры В. Красковский) афишасында беренче тапкыр А. Лугарев исеме очрый.

1930 еллар уртасында татар театры даирәсенә беренче профессиональ рәссам М. Абдуллин килгәч, афишаларда куелышта катнашкан техник персоналның да төп составын (монтаж өлеше мөдирен, сәхнә машинистын, костюмнар цехы мөдирен, парикмахерны) күрсәтә башлыйлар. Элек күзәтелмәгән бу күренеш профессионализмның дәрәҗәсе күтәрелүен, кадрларның шәхси җаваплылыклары артуны дәлилли торган факт. Безгә татар театры спектакльләренә тәүге профессиональ рәссамнарының берсе саналган П.Т. Сперанский тарафыннан бизәлгән афишаларны ачыкларга насыйп булды: алар – «Рабиндар» (Х. Вафа, 1930 ел), «Камиль» (Һ. Такташ, 1931 ел), «Кара күләгәләр» (А.-Т. Рахманкулов, 1931 ел), «Одва» (Г. Минский, 1931 ел), «Таулар» (Ш. Камал, 1931 ел), «Сөрем» (Х. Җәми, 1931 ел), «Өермә» (А. Зөлкарнәев, 1932 ел), «Тургай» (К. Тинчурин, Р. Ишморат, 1932 ел), «Мәкер һәм мәхәббәт» («Коварство и любовь». Ф. Шиллер, 1932 ел). Спектакль афишалары бизәлешендә төгәлсезлекләр киткән булган. Мәсәлән, Ф. Борнашның 1934 елда сәхнәләштерелгән «Яшь йөрәкләр», К. Тинчуринның 1935 елда куелган спектакльләренә афишаларны П. Сперанский түгел, ә М. Абдуллин эшләгән булган.

Татар театры тормышы турында, аның афишалары һәм плакатлары гына түгел, шул чор матбугаты битләрендә дә кызыклы гына белешмәләргә тап буласың. Мәсәлән, «Йолдыз» газетасы үз укучыларына 1915 елның 18 декабрендә Г. Кариев җитәкчелегендә «Сәйяр» труппасының «Гаепсездән гаеплеләр» («Без вины виноватые») спектакле куелачагы, аның өчен махсус декорация эшләнүе турында хәбәр итә. 1923 елның 15 апрелендә куелачак. «Күк палас» («Голубой палас) спектаклендә Үзбәк ролен К. Тинчурин уйнаячагы, махсус декорация һ.б. эшләнүне хәбәр итеlә. Г. Девишевның «Адашкан кыз» постановкасы куелган көнне – 1927 елның 13 ноябрендә татар сәхнәсендә әйләнмә түгәрәк эшли башлый, диелгән (ТР Милли музее). 1927 елда «Хөсәен Мирза» (режиссеры – Г. Девишев, рәссамы – П. Беньков) спектакле барганда беренче мәртәбә прожекторлардан файдаланыла (С. Сәйдәшев музее).

Анализлар күрсәткәнчә, КЭМСТ эшен туктатуга һәм авангардчы рәссамнарның күбесе таралып бетүгә карамастан, афишалар бизәлешендәге стильдә давыллы дәвер чаткылары 1930 еллар уртасына кадәр саклanып кала: әйтик, спектакльләрнең исемнәре чиктән тыш эре хәрефләр белән яки диагональ буенча бирелә, я булмаса афиша читләре буйлап урнаштырыла. Ә инде 1930 еллар ахырында афишаларның конструктивистик концепциясен татар китаплары бизәүдәге бертөрлелек һәм шаблон системасына йөз тоткан «неоклассицистик тенденцияләр» алыштыра [Улемнова, 2005, с. 26].

Шулай итеп, театр афишасы, спектакльдән аермалы буларак,

вакыт һәм пространство аралыгында үз әһәмиятен саклаган хәлдә, үз дәверенең кыйммәтле шаһиты булып яшәвен дәвам итә; афишаларда театрның репертуар сәясәте, постановкалар авторлары, рольләрне башкаручылар, тамашачылар зәвыгы һәм заманның эстетик ихтыяҗы хакында күп төрле мәгълүматлар саклана. Минемчә, бүгенге театр җитәкчеләренә, менеджерларына алардан үрнәк алырлык мисаллар аз түгел.

Соңгы елларда республикада театр эше киңрәк колач ала барган саен афишалар һәм плакатларның роле дә, реклама продукциясе сыйфатында гына булмыйча, зур кыйммәткә ия сәнгать әсәре дәрәҗәсенә күтәрелә. Шуңа күрә барлык афишалар коллекциясен бер урынга туплау, алар белән кызыксынучы тамашачылар өчен дә, аларны тикшереп өйрәнүчеләр өчен дә бу хәзинәгә юлны ачу максатка ярашлы булыр иде.

**Әдәбият**

*Аитов Л.* Безнең остазыбыз // Г. Камал турында истәлекләр. Казан: Татар китап нәшр., 1979. С. 105–106.

*Благов Ю., Ключевская Е.* Мир театральной афиши // Казань. 2002. № 3–4. С. 89–99.

*Гиззат Б.* Первая театральная афиша // Советская Татария. 1956. 30 дек.

Г. Камал театры архивы.

*Каримуллин А.* Татарская книга начала ХХ века. Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. 320 с.

*Корнилов П.* Казанский плакат. Казань, 1929. 29 с.

*Кумысников Х.* Истоки сценического реализма. Казань: Татар. кн. изд-во, 1982. 136 с.

*Лапина К.* Конструктивизм на марше: театральный плакат 1920-х – 1930-х годов // Сцена. 2013. № 5 (85). С. 57–61.

*Султанова Р.* КЭМСТ и татарский театр // Искусствознание. 2010. № 1–2/10. С. 549–560.

*Султанова Р.* Современная сценография Татарстана. Казань, 2003. 48 с.

Татарстан: иллюстрированная энциклопедия / под общ. ред. А.М. Мазгарова, Г.С. Сабирзянова. Казань: ГУ «Институт Татарской энциклопедии АН РТ», 2013. 828 с.

*Улемнова О.Л.* Сметая веками насевшую пыль... Графический коллектив «Всадник» (1920–1924). Каталог выставки. Казань, 2014. 264 с.

*Улемнова О.Л.* Искусство графики Татарстана 1920-х – 30-х годов // Автореф. дис. ... канд. искусствоведения. М., 2005. 29 с.

*Червонная С.М.* Искусство Советской Татарии. М.: Изобразительное искусство, 1978. 296 с.

***Солтанова Рауза Рифкать кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*тасвири һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге мөдире*

УДК 792.03

***Р.Ә. Абзалина***

# БЕРЕНЧЕ ТАТАР СПЕКТАКЛЬЛӘРЕ
## *(Рокыя Габитова хәтирәләре)*

В статье освещаются первые татарские театральные постановки в начале XX века по воспоминаниям Рукии Габитовой из фондов Национального музея Республики Татарстан.

**Ключевые слова:** первые татарские театральные постановки, воспоминания Рукии Габитовой, Национальный музей Республики Татарстан.

Татарстан Милли музее фондларында Казанда сәхнә тарихына кызыклы булырдай кечкенә генә истәлек дәфтәре саклана. Аны музейга 1953 елда Рокыя Габитова тапшырган. Истәлекләр рус телендә, төгәл, логик яктан бик эзлекле язылган. Татарчалаштыргач эчтәлеге кыскача түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

*«1903 ел ахыры һәм 1904 ел башларында Казан сәнгать мәктәбе укучысы Исмәгыйль һәм аның бертуганы Гариф Габитов Казанда укучы мөселман яшьләре өчен түгәрәк оештыралар. Мин “мөселман” сүзен түгәрәккә йөрүче татар, башкорт, кыргыз, мишәр яшьләрен гомумиләштереп бирү өчен кулланам. Түгәрәктән кавказлылар гына никтер читтә калган. Бу түгәрәкнең максаты яшьләрне берләштерү белән бергә мөселман көнчыгышы, бигрәк тә татар әдәбияты белән танышу.*

*Түгәрәккә йөргән укучылардан дәүләт уку йортлары студентларының күбесе рус һәм көнбатыш әдәбияты белән беркадәр таныш булса да, туган телдәге әдәбияттан аерылган гына түгел, ә аңа бөтенләй игътибар бирми. Түгәрәккә студентлар, мәдрәсә шәкертләре, урта мәктәпләрдә укучылар IV сыйныфтан кертелә, взнослар алынмый, бәлки, моңа мөмкинлеге булган кешегә әдәби әсәрләр алып килергә тәкъдим ителә.*

*Дәресләргә зыян килмәсен өчен түгәрәк җыеннары ялга каршы шимбә көннәрендә уздырылганга, аны “Шимбә” дип атаганнар.*

*“Шимбә” түгәрәген оештыручылар арасында бер-берсен мәктәп сыйныфларыннан яхшы белгән тар даирә танышлар, шулар арасында ул вакыт Казан реаль мәктәбе студенты Мулла-Нур Вахитов һәм “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе шәкерте, язучы Фатих Әмирханов та була.*

*Алга таба “Шимбә” әгъзаларының саны аны оештыручылар тәкъдиме белән 1904 ел ахырына 39 кешегә җитә: 10 студент, 2 се сәнгать мәктәбеннән, 3 гимназист, 7 гимназистка, 6 сы реаль мәктәптән, 4 мәдрәсә шәкерте. Милләтләре буенча: 1 башкорт, 2 мишәр, 5 кыргыз, калганнары – татарлар.*

*Җыеннар үз гаиләләрендә торган әгъзалардан гына җыела*

*иде. Алар безнең гаилә, Терегуловлар, Әхмәровлар һәм Сәиновлар.*

*Һәр җыелу шул көнгә сайланган әдәби әсәрләрне уку һәм тикшерүдән башлана. Бу бигрәк тә драма әсәрләре була, соңыннан төрле күңел ачулар оештырыла. Шул чакта өй шартларында гына булса да туган телдә татарча спектакль кую теләге туа.*

*Исмәгыйль Габитов йорт шартларына туры китереп декорация юнәлтүне, пьеса сайлау, рольләрне катнашучыларга бүлеп бирүне үз өстенә ала. Калганнар бөтен көчләрен салып бу проектны башкару өстендә эшли башлый.*

*Спектакль кышкы каникулга (Рождество) туры китереп, бар кеше укулардан азат вакытка куела. Спектакль өчен төрек тормышыннан алынып татарчага тәрҗемә ителгән "Гыйшык баласе" пьесасы сайлана. Ул вакыт без "Первая Гора"да Суханов йортында (хәзер Ленин урамы, 31) тора идек. Залыбыз бик зур арка белән икегә бүленгән. Кечкенә ягында, аның икенче бүлмәгә тоташуы безгә сәхнә өчен, ә зур ягы тамашачылар өчен бик уңай иде.*

*Тамашачылар "Шимбә" әгъзаларының якын танышлары, туганнары – барысы 50 ләп кеше җыела иде.*

*Бу театр сәнгатенә таба самими бер адым булды.*

*"Шимбә" җыены "яшел" яшьләрдән торып сәясәткә катнашы булмаса да, полиция безнең белән кызыксына башлады һәм акрынлап таралышырга туры килде. Кайберләребез укуларын бетереп билгеләнгән эш урыннарына яки укуларын дәвам итү өчен башка шәһәрләргә китеп бардылар.*

*1906 елда тагын бер марксистик әдәбият өйрәнү түгәрәге оештырып каралды, башлап йөрүче Мулла-Нур Вахитов иде. 7–8 кешедән торган түгәрәк Мулла-Нурның Варламская урамындагы кечкенә генә бүлмәсендә узды. Ул бер ике утырыштан соң полиция тарафыннан бастырылып таратылды.*

*1911 елда Европа әдәбиятын антик чордан башлап өйрәнү буенча тагын бер түгәрәк оештырылды. Аның җитәкчесе – Хөсәен Ямашев. Түгәрәк бары тик студент егет-кызлардан тора. Анда укытучы профессорлар ярдәме белән бик җитди мәсьәләләрга багышланган әдәби-эстетик темалар күтәрелә инде, шулай ук полиция тарафыннан матур итеп эшли башлауга тиз генә сүндерелде.*

*Ләкин "Шимбә" түгәрәге тарафыннан мирас булып калган татар телендә спектакль кую идеясе генә яшьләр күңелендә сакланып аны халык өчен күрсәтү мәшәкате 1906 елның 22 декабрендә реаль төс ала. Лядской урамында "Новый клуб" бинасында (хәзерге Горький урамындагы имгәнүләрдән соң тернәкләндерү клиникасы) Казанда беренче мәртәбә татарча беренче спектакль куела.*

*Бу яшьләрнең гөнаһлы шөгыльләре шәһәр картларын борчый, алар җитәкче органнарның берсеннән икенчесенә йөгереп спектакльне туктатырга ирешергә тели.*

*Никадәр мәшәкать бушка китә: губернатор спектакль куерга рөхсәт итә. Аннан бабайлар үзбаштан бу күренешкә бәйле бөтен нәрсәне җимерергә карар кылып, бу эшкә тавыш-гауга яратучы бар халыкны үз ягына тарталар. Хәзер инде спектакль оештыручыларның үзләренә полициягә ярдәм сорап мөрәҗәгать итергә туры килә.*

*Спектакль куелган көнне "Новый клуб" бинасы атлы полиция белән әйләндереп алынган. Алар кайтып баручы тамашачыларны өйләренә кадәр озата барып, бу тамаша тыныч кына үтеп китә.*

*Бу кичтә ике спектакль "Кызганыч бала" һәм "Гыйшык бәласе" куела – икесе дә төрек тормышыннан, татарчага тәрҗемә ителгән.*

*Тамаша уйнаучылар өчен дә, карап утыручылар өчен дә көтелмәгән уңыш белән тәмамлана. Һәр артистның сәхнәгә чыгуы алкышлар, чәчәк һәм конфетти сибүләр белән каршылана. Хәтта бу эшнең ахырын җирәнеп көтеп торган тамашачылар да ихтыярсыз бу гомуми искитмәле кызык халәткә буйсынып, башларына килгән ямьсез уйларын онытып җибәрергә мәҗбур булдылар.*

*Шагыйрь Сәгыйть Рәмиевның спектакльдә уйнаучы яшьләргә багышлап язган шигырендә бу үзәнчелекле тасвирлана.*

*Билгеле, артистларның уйнауларында да, техник яктан да җитешсезлекләр – байтак иде. Ләкин алар бит тәҗрибәсез һәвәскәрләр.*

*Спектакльнең уңышы уенда гына түгел, ә гасырлар буе йоклаган татар кешесен театр сәнгатенә кертеп җибәрү булды.*

*Беренче спектакльнең репетицияләре рөхсәт алганчы "Приказчиклар клубында (Большая Красная урамында (Хәзерге Молотов урамы, 29 йорт)) узды.*

*Рөхсәт алгач репетицяләр спектакль куелырга тиеш "Новый клуб" бинасында күчте.*

*Репетиция вакытында уйнаучылар гына түгел, ә булышырга телегән бик күп яшьләр катнаша, үз өлешен кертә иде.*

*Һәвәскәр спектакльләр 1911 елга кадәр дәвам итте, бәлки аннан ары да. Яңа труппалар туа торды. Хәтта хатын-кызлар өчен аерым спектакльләр куела, мондыйларда барлык рольләрдә дә бары хатын-кызлар гына уйный.*

*Фото № 1. Ләкин бу бердәмтелекле күренеш булды һәм озакка сузылмады.*

*Тамашачылар һәр кеше керә ала торган спектакльләргә бик тиз ияләште.*

*Бу беренче спектакльдә катнашучылар:*

*1. Әминә Терегулова (Гәрәева); 2. Зәйнәп Габитова Терегулова (Хаҗиева яки Сөянова); 3. Әбүбәкер Терегулов (Юнусов); 4. Шакир Мөхәммәдьяров (Бәдри Җамалов); 5. Г. Сәйфел-Мөлеков (Газизов); 6. Сөнчәләев (Субаев); 7. Габитова (Тарханова).*

*Калган спектакльләрдә соңрак катнашкан кешеләр: Гафур Коләхметов (Ширгали), Суфия Коләхметова (Мурадова).*

*Төп рольләрне башкаручылар: Әминә Терегулова (Гәрәева),*

*Зәйнәп Терегулова (Солтанова), Суфия Коләхметова (Мурадова), Г. Габитова (Азраил), Г. Сәйфел-Мөлеков (Газизов), Ш. Сөнчәләев (Субаев), А. Мостафин (Алмазов).*

*Суфлер һәрвакыт Г. Ногайбәков иде».*

Музейда сакланган афиша фотокопиясендә 1906 елның 22 декабрендә куелган беренче спектакльнең афишасында «Татар телендә татарлар тормышыннан театр уены уйналачак» – диелгән.

Куелачак нәрсәләр: «Кызганыч бала» (авторы күрсәтелмәгән) – драма, өч пәрдәдә һәм «Гыйшык бәласе» – комедия, дүрт пәрдәдә. Уйнаучы кызлардан: Хәнифә Морадова (С. Коләхмәтова), Сәлимә Тарханова (Габитова), Газизә Хаҗаева (Зәйнәп Терегулова), Хәдичә Шакирова һәм Гыйззәтбану Шәмсетдинова; ирләрдән: Һәрмаз Бәзәрҗумһаров (Шакир Мөхәммәдъяров), Мидхәт Сами, Галим Бакиров, Вәли Газизов (Г. Сәйфел-Мөлеков?), Әхмәт Исмәгыйлев, Кәрим Тиниев һәм Ибраһим Хәйбушев. Җәя эчендә уйнаучыларның чын исемнәре булырга мөмкин. Театр белгече Исмәгыйль абый Һилалов бу эшләрдә үзе катнашкан кеше буларак актерларның сәхнә исемнәре спектакльләрнең мәгърифәтчелек максаты белән кулланганын һәм уйнаучыларның тарихка үз исемнәрен кертеп калдырырга оялуларыннан дип әйтеп калдырган иде.

Ул вакыт бер сыер 5 сум торган дип исәпләсәк, билет бәяләре бик аз түгел: 1–2 рәтләр – 3 сум, 3–5 рәтләр – 2 сум 50 тиен, 6–7 рәтләр – 2 сум, 8–9 рәтләр – 1 сум 50 тиен. Басып торучылардан – 75 тиен, шәкертләргә – 50 тиен. Билет бәясеннән артыграк итеп түләргә теләүчеләр булса – рәхмәт әйтеп кабул ителәр, чөнки спектакльдән килгән бар акча «Казан дөрелфөнүнендә (университетында), укучы фәкыйрь студентларга ярдәм итү җәмгыятенә» тапшыралачак диелгән.

Музей фонды Гайшә Шәрипова архивында Гаяз Исхакыйның «Өч хатын белән тормыш» спектакленең кызлар труппасы тарафыннан фәкать хатын-кызлар өчен генә куелган спектакльдә катнашучыларның фотосы саклана (ГМТР № 125694а-167). Нәкъ шундый ук вариант егетләр труппасы да тарихи фотога кереп калган (ЦМТР № 118157 – № 118158).

Татар театрының беренче адымнары булган бу хәрәкәт әхлакый-эстетик тәрбия максатларыннан һәм студентларның бер-берсе белән зыялы аралашу мөмкинлеге буларак татар мәгърифәт идеологы Фатих Әмирхан һәм аның фикердәшләре тарафыннан гасырлардан килгән милли тәрбия традициясенең XX гасырга таба нечкә һәм дөрес форматта дәвам итүен тәэмин итте.

***Абзалина Рәмзия Әсрар кызы,***
*Татарстан Республикасы Милли музее өлкән фәнни хезмәткәре*

УДК 792:377

***Р.Р. Вәлиев***

# КАЗАНДА МАХСУС УРТА ТЕАТР БЕЛЕМЕ

Статья посвящена развитию театрального образования в Казани. В статье указаны основные этапы этого процесса, их особенности, освещены наиболее значимые проблемы как творческого, так и административного характера. Раскрывается роль театрального образования в культурном строительстве, показаны трудности и достижения, названы наиболее значимые имена.

**Ключевые слова:** среднее профессиональное театральное образование, театральное училище, театральный техникум.

Татарстан АССР 1920 елда төзелә. Республиканың туган көне татар театры бинасына нигез салыну белән дә истәлекле. Милли театрның беренче тапкыр дәүләт статусы алуы да шуннан башлана. 1922 елның 26 сентяберендә, Татарстан АССР һөнәри белем бирү коллегиясе карары нигезендә, татар дәүләт театрына белгечләр әзерләү максаты белән Татар театр техникумы ачыла.

Бу уку йорты белән идарә итү Зәйни Солтановка йөкләнә, шул ук вакытта ул, рус театрының күренекле режиссеры Зинаида Михайловна Славянова катнашы белән, оештыру эшләрен дә алып барырга тиеш була.

Беренче вакытларда техникумның үз бинасы да булмый. Аны Петропавловский (хәзер М. Җәлил) урамындагы «Идел» номерлары ишегалдына урнаштыралар. Техникумның аудиторияләре дә, тулай торагы да шунда була. Техникумның беренче директоры итеп инкыйлабка хәтле үк эшләгән театрның танылган артисты Зәки Баязидский билгеләнә. Аннан тыш, техникум укучылары арасыннан укучылар комитеты, аның рәисе итеп Хәким Сәлимҗанов сайлана. Директорлар бик еш алышына, 5 ел эчендә бу вазифада 5 кеше эшләп ала.

Зәки Баязидский 1923–1924 елларда эшли; 1924 елда аны Хәмит Солтанов алыштыра; 1925 елда – Юмай, 1925–1928 елларда М. Мәһдиев, ә 1928 елдан Муса Зәитов директор була.

Техникумда эшнең һәркайсын: уку-укыту планнарын һәм программаларын, көн тәртибен һәм тәртип кагыйдәләрен, сәхнә эше һәм театрлар тарихы буенча махсус дәреслекләрне – барысын да яңабаштан эшләргә туры килә.

Алар техникумның беренче завучы Б. Симолин җитәкчелегендә әзерләнә. Өч ел белем бирү курсын күздә тоткан программа профессиональ яктан әзерлек һәм тирән белемле белгечләр белән тәэмин итүгә юнәлдерелә.

Театр техникумының баштагы контингенты бу һөнәр белән кызыксынучылардан туплана. Кабул итү актерлык сәләте буенча имтихан аша оештырыла. Сәхнә артистлары әзерләүче махсус уку йортында Татарстан, Башкортстан, Кырым, Урта Азия регионнарыннан, Урал, Себер авылларыннан җыелган укучылар белем

ала. Уку елы башында укучылар саны 16 булса, ел ахырына алар инде 30 га җитә. Техникумны элеккеге кызлар өчен эшләгән Мария гимназиясе бинасына (хәзер Рәхмәтуллин урамы, 2, Петропавел соборына каршы почмак йорт) күчерәләр.

Техникумга укытучылар итеп театр сәнгатенең җирле иң яхшы белгечләре һәм педагоглар чакырыла. Алар арасында татарлар да (гомум белем һәм һәрьяклы үсеш фәннәре буенча), руслар да (театр фәннәре буенча) була. Беренче педагоглар – татар һәм рус сәхнәләренең күренекле эшлеклеләре Зәйни Солтанов (мөдир), Салих Сәйдәшев (җыр), Фатих Әмирхан (татар әдәбияты), Бари Тарханов белән Зинаида Славянова (сәнгатьле уку), Михаил Прыгунов (дөнья мәдәнияте тарихы). Географияне Мөхәммәтов, пластиканы Каракович, татар телен Биккулов, актерлык практикасын Тинчурин алып бара. Күптән түгел генә Зур театр студиясен тәмамлаган К. Романычева рус теле тарихын укытырга, булачак халык артисты В. Белокуров грим белән эшләүне өйрәтергә җәлеп ителәләр.

Беренче чыгарылыш 1926 елда була. Күренекле актерлардан Х. Сәлимҗанов, Г. Кайбицкая, Г. Булатова, Г. Нигъмәтуллина, драматург Риза Ишморат һ.б. заманында шушы техникумны тәмамлаган булалар. К. Бариев белән К. Тумашева техникумнан соң ук анда укытучы булып эшли башлыйлар. 1927 елның җәендә Г. Девишев белән И. Ингвар җитәкчелегендә бер төркем укучылар гастрольгә чыгалар.

Шул ук 1927 елда татар театр һәм сәнгать техникумнары берләштерелә һәм К. Маркс урамындагы бинага күчерелә. Бу уку йорты Казан берләштерелгән сәнгать һәм театр техникумы дип атала башлый. Шуны билгеләр үтү мөһим, ике уку йортын болай кушуның сәбәбе, беренчедән, чыгымнарны кыскарту, аннан рациональ файдалану булса, икенче яктан, бердәм техникум төзеп, бу өлкәләр буенча белем бирүне камилләштерүгә юл тоту дип санарга кирәк.

1929 елда техникумны ТАССРның булачак халык артистлары Галимә Ибраһимова, Габделгазиз Зыятдинов, шулай ук Луиза Салиәскәрова (соңрак ул техникумда укыта) тәмамлый.

1930/1931 уку елы барышында Казан берләштерелгән сәнгать-театр техникумы Көнчыгыш музыка техникумы белән берләштерелә һәм Татар сәнгать техникумы дип атала башлый. Техникум Жуков урамына урнаша. Анда театр, музыка, сәнгать бүлекләре эшли.

Төрле авырлыклар кичерүгә карамастан, 1923–1930 елларда Татарстанда театр, сәхнә сәнгате белеме бирү камилләшә һәм үзенең җимешләрен дә бирә. Театр техникумында укучылар, беренче елларыннан ук, академия театрында спектакльләрдә күмәк күренешләрдә катнаша башлыйлар. Аны тәмамлагач, академия театрында эшлиләр һәм күбесе күренекле артистлар булып танылалар.

Бөек Ватан сугышы башлангач, Татарстанда театр белеме бирү туктап кала. Студентлар һәм техникумны тәмамлаучылар сугышка китә. Шулай итеп,

1941 елның җәендә Сәнгать техникумы бөтенләй ябыла.

1943 елда, фронт сызыгы әкренләп Көнбатышка күчә башлагач, татар артистлары әзерләү мәсьәләсе кабат күтәрелә.

«Татарстан АССРда театр сәнгате кадрлары әзерләү чаралары турында» ВКП(б) өлкә комитеты бюросының 1943 ел, 17 июль һәм ТАССР Халык Комиссарлары Советының 1944 ел, 1 март карарлары нигезендә Казанда Татар театр көллияте ачыла. Аның директоры итеп ТАССРның атказанган артисты С.С. Булатов билгеләнә (аңа 1200 сум күләмендәге персональ эш хакы раслана) [Милли архив. Ф. 5795, оп.1, эш 1, б. 2].

Әмма күрелгән барлык чараларга да карамастан, татар театр көллиятенә укучылар туплау эше һаман сузыла бара. Укулар 1945 елның 17 сентябрендә генә башлана.

1945/46 уку елы башында көллияттә 17 укытучы эшли: аларның 14 е – бер үк вакытта ике урында эшләүче, 11 е югары, 6 сы махсус урта белемле була. Исемдәрәҗәләргә ия 6 укытучы эшли. Актер осталыгы педагоглары Ширияздан Мөхәммәтҗан улы Сарымсаков белән Кәшифә Җамалетдин кызы Тумашева Дәүләт театр сәнгате институтының (ГИТИС) режиссерлык факультетын тәмамлап эшлиләр. Сәхнә телен Габдулла Шамуков (соңыннан СССР халык артисты) белән Луиза Салиәскәрова укыта, грим буенча Касыйм Шамил, биюләрне Петр Якушев, сәхнә хәрәкәтләрен Пейсахов, татар әдәбиятын КДУ профессоры Хатип Госманов укыта.

1949 елда Татар театр көллияте театрларыбызны беренче мәртәбә өстәмә көчләр белән тулыландыра. Шул елның җәендә СССРдагы татарлар күпләп яши торган шәһәрләргә һәм эшчеләр бистәләренә гастрольләр оештырыла.

Дүрт ел дәвамындагы киеренке эшләр һәм җитди белем бирү нәтиҗәсез булмый. 1949 елның 25 маеннан 1 июльгә кадәр күрсәтелгән диплом спектакльләре (алар – бишәү) чын-чынлап иҗади хисап тотуга әверелә. Ул спектакльләрнең һәркайсы күпсанлы тамашачыларны җәлеп итә (алар арасында дәүләт җитәкчеләре, җәмәгатьчелек вәкилләре, мәдәният һәм сәнгать хезмәткәрләре, язучылар, рәссамнар бар) [Милли архив. Ф. 5795, оп. 1, эш 49, б. 3]. Имтихан барган көннәрдә көллият тормышын һәм белем бирүне чагылдырган материаллардан махсус күргәзмә оештырыла. Дәүләт имтиханнарын тапшыру 30 студентның 28 енә рөхсәт ителә. Чыгарылыш имтиханнарын алты студент иң яхшы билгеләргә генә тапшыра. 1949 елгы чыгарылыш нәтиҗәләре көллияттә югары квалификацияле, дөрес методлар белән коралланган, яхшы педагоглар советы булган коллектив эшләвен раслый.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк, 1949 елгы сугыштан соңгы чыгарылыш сәхнә реализмы нигезендә тәрбияләнә, һәм шушы елда кулына диплом алган яшьләр арасында эшли-эшли зур танылуга ирешүчеләр дә бар. Мәсәлән: Алсу Илялова, Рауза Ибраһимова, Айрат Арсланов СССРның халык артисты; Гата

Нуруллин – ТАССРның халык артисты; Шәүкәт Биктимеров – СССРның һәм Татарстанның халык артисты, К.С. Станиславский исемендәге Дәүләт һәм Г. Тукай исемендәге ТР Дәүләт премияләре лауреаты.

Татар дәүләт театр көллиятенең хезмәтләре нәтиҗәле булуга карамастан, СССР Министрлар Советының 1952 ел, 13 июнь карары белән ул эшләүдән туктатыла.

ТАССР Мәдәният министрлыгы һәм шәхсән министр Булат Миңнулла улы Гыйззәтуллин тырышлыгы белән 10 елдан соң ТАССР Министрлар Советының 1962 ел, 12 май карары нигезендә Казан театр көллияте [Милли архив. Ф. 5795, оп. 2, эш 1, б. 5] яңадан эшли башлый.

Яңа ачылган бу уку йортының директоры итеп күптән түгел Мәскәүнең М.С. Щепкин исемендәге театр көллиятен тәмамлаган Дамир Бәдретдинов билгеләнә.

1962/63 уку елында Казан театр көллиятенең белем бирү өчен үзенең матди базасы булмый. Дәресләр төрле урыннарда (Педагогика институтының икенче бинасында, Г. Камал һәм В. Качалов исемен йөрткән театрларда, «Динамо» спортзалында һәм Театр җәмгыяте бинасында) уздырыла. Тиздән, хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр Советы башкарма комитеты карары (1963 ел, 30 март, № 200) белән Театр көллияте өчен Гоголь урамында ике йорт (№ 2а һәм 2/35) бирелә.

Әмма объектив һәм субъектив сәбәпләр аркасында башкарма комитет карары өлешчә генә үтәлә, чөнки күрсәтелгән биналарның төп өлешенә Республика ветеринария лабораториясе һәм тагын 15 гаилә урнашкан була. Театр көллияте 200 м$^2$ мәйданны биләгән 6 бүлмәдә генә эшләргә мәҗбүр була.

Театр көллиятендә директор һәм аның рәислегендәге педагоглар советы түбәндәге мөһим мәсьәләләрне хәл итә: театр көллияте бурычларын тормышка ашыру, укучыларның агымдагы өлгерешен тәэмин итү, имтихан сессияләренә әзерләнү, укучылар арасында алып барылган тәрбия эшләре буенча сыйныф җитәкчеләренең хисап тотуы, укытучыларның квалификациясен күтәрү һ.б. Педагоглар советы эшеннән тыш, актерлык осталыгы һәм сәхнә теле буенча циклы комиссияләр дә эшли [Милли архив. Ф. 5795, оп. 2, эш 14, б. 4].

Театр көллиятендә һөнәри белем бирү һәм актерлык тәрбияләү системасының нигезен театрның үз казанышлары, К.С. Станиславский белән И.Н. Данченконың, шулай ук аларның шәкертләренең педагогик һәм иҗади тәҗрибәләре тәшкил итә.

Көллиятнең дәрәҗәсе арта бара, моны анда укырга керергә теләүчеләрнең гаризалары саны раслый. Әйтик, 1966 елда татар актерлары әзерләү бүлегенә 137, курчак театры артистлары әзерләү бүлегенә 104 гариза кергән. Шулардан татар актерлары бүлегенә 25 кеше (14 егет һәм 11 кыз; 12 се урта белемле, 3 се 9 нчы сыйныфны, 10 сы 8 нче сыйныфны тәмамлаучы) кабул ителгән. Курчак театры бүлегендә 20 кеше (10 егет һәм 10 кыз; 6 сы урта белемле, 5 се 9 нчы сыйныфны, 9 ы

8 нче сыйныфны тәмамлаган) укый башлаган.

Көллиятнең һәм аны тәмамлап эшләүчеләрнең уңышлары хакында матбугатта басылып чыккан мәкаләләрдән укып та белергә мөмкин. Театр белгече К. Кривицкий «Театр учится у жизни» дигән мәкаләсендә көллиятне тәмамлап Татарстан АССР күчмә театрында эшләүче В. Хөснетдинованы мактап яза [Советская Татария. 1966. 14 июня]. В.И. Качалов исемендәге Казан театры спектакленә багышланган «Ради тебя... помни» дигән мәкаләдә театр белгече Золотарев көллиятне тәмамлаучылардан Н. Сикорова белән В. Кирюханцев иҗатына югары бәя бирә [Театральная жизнь. 1966. № 10]. «Они и мы» спектакленә язган рецензиясендә Бердичевский көллиятне тәмамлагач Казан яшь тамашачылар театрында эшли башлаган А. Кокурин һәм Жаворонкова турында «они не только доносят до зрителя мысли автора и режиссера, но и интересное собственное понимание образа» дип яза [Комсомолец Татарии. 1966. 30 июля]. Казан яшь тамашачылар театрында куелган «Мужчина 17 лет» спектакле буенча язган рецензиясендә филология фәннәре кандидаты Богдановның түбәндәге юлларын укый алабыз: «...выпускники Казанского театрального училища А. Кокурин, Т. Мычилкина, Н. Казанцев – правдиво и интересно создают основные образы» [Советская Татария. 1967. 14 марта]. Шул ук театрның репертуарына багышланган «Героическая тема обязывает» дигән мәкалә авторы В. Гудкова болай яза: «...выпускники Казанского театрального училища А. Кокурин и Т. Мычилкина – это актеры умеющие играть и думать на сцене» [Советская Татария. 1967. 14 марта].

Тормыш раслаганча, катлаулы, киңкырлы организм саналган театрга талантлы профессионалларыннан башка театр сәнгатенең барлык юнәлешләре буенча да уңышларга ирешү мөмкин түгел. Шуңа күрә 1964 елда көллияттә бутафор рәссамнар бүлеге ачыла. Бүлекнең оештыручысы һәм әйдәүче остасы итеп Татьяна Андреевна Зуева билгеләнә. 1968 елда бутофор рәссамнарның беренче чыгарылышы була. Т. Зуева берничә буын рәссамнар әзерли, аның шәкертләре арасыннан, театр сәнгате өлкәсендә генә түгел, сынлы сәнгать һәм графика буенча да күренекле осталар үсеп чыга.

Казан театр көллияте әкренләп киңәя бара, театр өчен кирәкле белгечләр әзерләүче күп профильле уку йортына әверелә. Киң күңелле һәм талантлы педагоглар һәр укучы күңеленә ачкыч таба беләләр, аларга сәләтләрен тулысынча ачарга, һәрьяклы үсешкә ирешергә ярдәм итәләр. Көллият педагогларының төп принцибы – театр сәнгатен үстерү өчен лаеклы алмаш тәрбияләүдән гыйбарәт. Ә татар төркемендә белем алып чыккан буын милли театрларыбызның нигезен тәшкил итә, еллар узган саен алар югары дәрәҗәдәге сәнгать осталарына әйләнә баралар.

***Вәлиев Рамил Равил улы,***
*«Татар тудэй» интернет сайты корреспонденты*

УДК 78:398

*Э.М. Галимова*

## С. ГАБӘШИ МУЗЫКАСЫНДА ФОЛЬКЛОР ЧАГЫЛЫШЫ

Творчество Султана Габяши явилось неким фундаментом и определило в какой-то мере основное направление в развитии татарского музыкального искусства, особенно благодаря первым попыткам синтеза народных музыкальных традиций и средств европейской классической музыки. Музыкальное наследие композитора позволяет во многом по-новому взглянуть на формирование татарского профессионального музыкального искусства. Его многогранная деятельность не потеряла своей актуальности в области искусствоведения, музыковедения и музыкальной фольклористики.

**Ключевые слова:** Султан Габяши, татарская музыка, татарское профессиональное музыкальное искусство, музыковедение, музыкальная фольклористика.

Музыкант, композитор, фольклорчы, мәгърифәтче Солтан Габәшинең иҗади чаткылары бик яшьли, XX гасыр башы татар мәдәниятенең рухи күтәрелеше атмосферасында формалаша. Иҗади мөмкинлекләрен һәрьяклап ачу омтылышы көчле булган үсмер чоры исә Совет хакимиятенең баштагы катлаулы елларына туры килә, ул вакытта илдә тоталитар режим һәм идеологик чикләүләр хөкем сөрә, сәнгатьне сәясәтләштерү процессы көчәя. Аның ислам тарихы һәм мәдәнияте белән кызыксынуы яңа хакимияткә карата оппозициягә басуы булып кабул ителә. Идеологик һәм социаль характердагы күп кенә сәбәпләр нәтиҗәсендә композитор, фольклорчының иҗади мирасы музыкантлар һәм татар мәдәниятен өйрәнеп тикшеренүчеләр игътибарыннан читтә кала килә. С. Габәшинең халык иҗатына караган кайбер хезмәтләре әлегә кадәр нәшер ителмәгән. Түбәндә күрсәтелгән хезмәтләре дә фәкать XX гасыр ахырында гына дөнья күрә: «Национальные мелодии. Тюрко-татарские песни» (1910–1920 елларда эшләнгән); «Отчет экспедиции по изучению народного творчества» (Татарстан районнарында йөреп кайткач, 1931 елда язылган); «Сто башкирских народных песен» җыентыгы (30 нче елларда А. Ключарев һәм К. Рәхимова белән бергә әзерләнгән). Этномузыколог Г. Макаров фикеренчә, «Национальные мелодии. Тюрко-татарские песни» тематикасы буенча гаять киң эчтәлекле. Күпчелек язмаларның татар халык җырлары һәм башкортларның, казакъларның халык музыкасы үрнәкләре белән бирелгән. Җыентык төгәл жанрлар классификациясенә, бүлекләргә аерылмаган. Нигез итеп XX гасыр башында киң таралган лирик җырларның үрнәкләре, шулай ук С. Габәшинең әтисе Хәсәнгатадан, әнисе Шәмсеруйдан, туган авылы Сулабаштагы мәдрәсә шәкертләреннән һәм авылдашларыннан язып алган ислам конфессиональ сәнгате (касыйдә, зикер,

мөнәҗәтләр) белән бәйле вокаль-поэтик әсәрләр алынган [Макаров, с. 144].

С. Габәшинең татар музыкасы һәм халык иҗатын яктырткан «Татар сәхнәсендә музыка», «Татар музыкасы турында», «Татарстан курайчылары һәм гармунчылары» дигән мәкаләләре аерым игътибарга лаек. Кызганычка каршы, авторның 1921 елда тупланган «Киргизские и казахские народные песни» һәм «Башкирские народные песни» югалган булып санала. Солтан Габәшинең халык традицияләре, татар тарихы, үз чорының милли лирик җырлары характер үзенчәлекләре хакындагы гаять киңкырлы белеме аның, музыкаль-этнографик эшчәнлек дәрәҗәсен күтәрүгә генә түгел, ә рус, гарәп, фарсы һәм төрек телләрендәге чыганаклар белән эшләвенә дә ярдәм итә. Әлбәттә, С. Рыбаков, В. Мошков, Н. Никольский, соңрак А. Эйхенвальд хезмәтләре дә аңа киңкырлы музыкант буларак формалашырга көчле йогынты ясый.

Солтан Габәшинең музыкаль-этнографик эшләрен өйрәнгәндә, аның нота язмалары методикасы үзенчәлекләренә игътибар итми мөмкин түгел. Квантитатив ритмик төзелешле көйләре һәм бай орнаментика белән иҗекләп көйләү югарылыгы һич кенә дә Европа метрикасы акценты белән туры килми. Монда шул ачыклана, С. Габәши татар халык көйләрен кәгазьгә төшергәндә (расшифровкалаганда) нотага салуның (нотациянең) гомум кабул ителгән кысаларыннан чыкмаска тырыша. Шуңа күрә аның кайбер язмаларында логика сакланмый. Ул үзенең расшифровкаларында аерым ритмик һәм мелодик фигураларны европалылар үрнәгендәге нотациягә туры китерергә тырыша. С. Габәшинең нотага салу ысулларын аңлау өчен, әсәрнең музыкаль жанрына яки фольклор үрнәкләренә, көйнең структурасын һәм ритмын чагылдыручы шигъри текст төзелеше үзенчәлекләренә игътибар итәргә кирәк.

С. Габәши тарафыннан тупланган материаллар, татар халык инструменталь сәнгате генезисының күп кенә проблемаларын аңларга ярдәм итүче чыганак буларак, аеруча зур кыйммәткә ия. Аның аккош, торна тавышларына охшатып курайда, скрипкада гармунда уйналган инструменталь яңгырашлар язмасы, чыннан да, уникаль ачыш булып санала [Макаров, с. 154]. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы тикшеренүчеләре мондый үрнәкләрне теркәп бармадылар. Инструменталь башкару үрнәкләре ачык яңгырашы белән башкортларда һәм казакъларда нык аерылып тора, ә татарларда ул зур үзәкләрдән бик еракта урашкан авылларда гына күзәтелә. Солтан Габәшнең халык иҗатын өйрәнеп тикшерү осталыгы аркасында гына андый инструменталь яңгыраш үрнәкләре теркәлеп, язып калдырылган. Хәзер исә андый материалларны табып язу мөмкинлеге юк диярлек.

Солтан Габәши үзенең иҗади эшчәнлеген 1909 елда башлый. Аның беренче иҗади хезмәтләре: инструменталь пьесалар, романслар һәм Г. Тукай белән С. Рәмиев шигырьләренә җырлар;

бераз соңрак, драма спектакльләре өчен үзешчәнлеге белән аерылып торган музыка яза. Соңгы әсәре музыкаль теленең моңга байлыгы, үзенә бер төрле ладлар гармониясенә ия борылышлары белән җәлеп итә. Тагын шунысы кызыклы, С. Габәши, кайчандыр, бик популяр саналган мелодекламация жанрына (әмма ул чакта композитор «аңа әһәмият бирмәгән була») бик еш мөрәҗәгать итә. Ул аларны беркайчан да тоташ язып алмый, ә карала-ма-шпаргалка рәвешендә генә теркәп бара, һәм, әлбәттә инде алар бик тиз югала торган булалар. Композиторның «Таһир – Зөһрә», «Бүз егет», «За стенами Старой Казани», «Җир уллары», «Сак-Сок» һ.б. музыкаль драмаларны сәхнәгә чыгару өлкәсендәге эшчәнлеге дә игътибарга лаек. Аларда яңгыраган кайбер көйләре, фольклорлашып, халык иҗаты рәвешендә татар җәмәгатьчелеге көнкүрешенә үрелеп китә.

Бу мәкаләдә Солтан Габәши образындагы күптавышлы фикерләүгә сәләтле феноменның хор иҗаты өлкәсендәге кайбер үзенчәлекләренә тукталып үтү урынлы булыр. Хор өчен әсәрләр иҗат итә башлаганчы, С. Габәши шактый гына композиторлык тәҗрибәсе туплап өлгергән, инструменталь һәм вокаль әсәрләре дөнья күргән, театр постановкалары өчен берничә музыка язган була инде. Шулардан Г. Исхакыйның «Зөләйха» (1917), Ф. Борнашның «Таһир-Зөһрә» (1918) спектакльләре С. Габәши тарафыннан иҗат ителгән хор номерлары белән җанландырыла. Алар, композитор үзе әйткәнчә, унисон җырлау була, ягъни «тавышларга бүленмичә» җырлана [Яңалиф, б. 68]. Ул үзенең хор өчен язган әсәрләрен «Кыйгак-кыйгак» дигән җырдан саный башлый, һәм, тавышлар өчен язылган көйләр фактурасын истә тотып, «күптавышлы» хор дип билгеләп бара [ОРТ ИЯЛИ. Ф. 60, оп. 1].

Шунысын дә әйтеп үтәргә кирәк, Солтан Габәшинең хор өчен иҗат иткән әсәрләренең күпчелеге татар халык җырларын күптавышлы итеп эшкәртүдән гыйбарәт. Аның чыганакларын композиторның шәһәр татарларыннан кайчандыр үзе язып алган көнкүреш җырлары тәшкил итә [Бражник, с. 173].

Музыка белгече Ф. Салитова фикеренчә, Солтан Габәши музыкасы белән бизәлгән спектакльләр татар музыкаль драмасының кайбер характерлы үзенчәлекләренә ия, алар, еллар узгач, Салих Сәйдәшев иҗатында үз биеклеген яулый [Салитова, с. 194]. Композиторның спектакльләргә язган музыкасының уңышы аның фольклор белеме югары булу белән дә бәйле. Ул аларны иҗат иткәндә татар халык җырларындагы кайбер өземтәләрдән, яки аларны хор өчен эшкәртүдә башлангыч чыганаклардан оста файдалана, йә булмаса, аларны европача яңа лад гармоникасы рәвешендә куллана, яки үз музыкасын халык көйләре стиленә сала.

Театр өчен иҗат ителгән музыкаль әсәрләрнең безнең көннәргә кадәр сакланып калган өлеше аларның татар музыкаль фольклоры (аеруча озын көй

жанры, мөнәҗәтләр һәм бәетләрнең китаби башкарылуы) элементы традицияләренә тугрылыгын раслый.

Композиторның Көнчыгыш халыклары сәнгате белән нык кызыксынуын билгеләп үтәргә кирәк. С. Габәшинең театр өчен иҗат иткән музыкаль әсәрләре композиторның замандашлары даирәсе өчен генә киң мәгълүм, бүгенге буын алар хакында хәбәрдар түгел. Шуңа да карамастан, алар профессиональ музыка сәнгате үсешендә мөһим фактор булып санала.

1923 елда С. Габәши, Г. Әлмөхәммәтов һәм В. Виноградов составындагы авторлар коллективы «Сания» операсы (Г. Әлмөхәммәтовның шул исемдәге либреттосы буенча) өстендә эшли башлыйлар. Спектакльне әзерләүдә дирижер А. Литвинов, рәссам П. Сперанский, балетмейстер Ю. Муко, җырчылар Г. Әлмөхәммәтов, З. Байрашева, Р. Садыйкова, А. Хисамов, хор һәм Көнчыгыш музыкаль техникумы укучылары оркестры катнаша. Аның премьерасы 1925 елның 25 июнендә була, һәм ул ТАССР төзелүнең 5 еллыгына багышлана. Солтан Габәшинең бу операның постановкасын әзерләүдә композитор, музыкаль тәнкыйтьче, музыкантларның тулы бер буынын тәрбияләп чыгарган педагог булып кына түгел, ә оештыручы һәм, хәтта, башкаручы буларак та катнашуы мәгълүм. Операның мелодиясе нигезен, халык көйләре белән бергә, авторның татар, башкорт лирик җырлары стиленә охшатып иҗат иткән, әлегә кадәр кабатланмаган әсәрләре тәшкил итә. Операда төп урынны, ул чор музыка сәнгате өчен әле яңалык булган, хор номерлары били. Аерым жанрларны чагылдырган сәхнә күренешләрендә фольклор мотивлары яңгырау да халык чыганаклары йогынтысының ачык мисалы булып тора. Баш геройлар – Сания белән Зыяның орнаментикага бай вокаль партияләре көчле лиризм белән сугарылган. Мәсәлән, Зыяның Сания белән очрашуын көткәндәге ариясендә башкорт җыры «Коңгор бага» көе элементлары чагыла [Исанбет, с. 15][1].

Вариацияләр белән үрелеп барган куплет формасында булуына карамастан, *озын көйгә* якын торган күп арияләр күренешләрдәге характеры һәм максаты белән классик операның сәхнә вокал формасына тәңгәлләшәләр. Операның күптөрле мелодик һәм жанр башлангычлары, һичсүзсез, аның авторларының музыкаль телне халык күңеленә якын итәргә омтылышын чагылдыра. Әсәрдә фольклор тематикасының төрлелеген «Сания» операсы персонажларының аерым эпизодик вокаль номерларында күзәтергә була.

Гөлбикә образы шул ягы белән истә кала. Авторлар бу музыкаль образның мелизмнарга бай җыры мелодиясен дини

[1] И. Илялов аңлатканча, 1938 елдан соң, Г. Әлмөхәммәтов исеменә яшерен тыелу кертелгәч, композиторның бу әсәре халыкныкы дип йөртелә, шуның белән бергә репертуарда башкорт башкаручылары сакланып кала.

«Мөхәммәдия» көенә нигезләп иҗат итәләр. Гөлбикәнең музыкаль фразаларында озын көйле «Зиләйлүк»тәге сузып җырлана торган борылышлар да, кызу ритмлы, импулсив («Пар ат»тагы кебек) яңгырашлы урыннар да бар. Гомумән, операда җырның строфалылыгы, бик урынлы рәвештә, жанр эпизодларына бәйләнешле итеп бирелеүе күзәтелә. Опера авторлары татар һәм башкрот көйләрендәге интонацион материалдан иркен файдаланып, интуитив рәвештә, турыдан-туры үсешкә омтылалар. Шуның белән бергә, опера авторлары төрле җырлардагы аерым интонацияләрне берсенә берсен кушалар, аңа үзләренең мелодик материалларын да өстиләр.

Операдагы кайбер гадәти җитешсезлекләрне аны иҗат итү чоры һәм шул чордагы шартлар белән бәйләргә кирәк. Милли операларның барлыкка килүе, музыкаль культураларның күпчелеге өчен, билгеле бер этапта озакка сузылган эволюцион үсеш белән характерлы. «Сания» операсы – көйне гармунчыга кушылып бер кеше башкару шартларында, аны традицион һәм Европаның классик музыкасына нигезләнгән яңа тасвирый чаралар белән баету нәтиҗәсендә барлыкка килгән әсәр. Шуны да билгеләп үтү мөһим, опера авторларының күп кенә сәнгати табышлары татар композиторларына музыкаль формалар һәм опералар иҗат итүгә юл салды.

1930 елда премьерасы күрсәтелгән «Эшче» операсының сюжеты нигезен 1905–1907 еллар рус буржуаз-демократик инкыйлабы чорында барган вакыйгалар тәшкил итә. М. Фәйзиллаева билгеләп үткәнчә, «Если в первой опере композиторы очень осторожно обращались с народной песней, в точности сохраняя её структуру, то здесь «Тэфтилэу», заключена в стройную трёхчастную форму, крайние части которой являются куплетами песни, середина – развивающего типа» [Файзуллаева, с. 33].

Шунысы кызыклы, дүртенче пәрдәдә хореографик сюитадагы балет номеры Ф. Яруллинның «Шүрәле» балетындагы вальс ритмына салынган «Тәфтиләү» көен кулланунының беренче үрнәген тәшкил итә. Операның бию күренешләрендә дә, җыр номерларында да вакыйганың мөһим драматургик мизгелләрен тасвирлаганда кулланылган халык көйләренә аерым тукталу урынлы булыр. Мәсәлән: «Казан сөлгесе» көе беренче пәрдәдә баш герой Нигъмәтнең хатыны Хәмидә партиясендә яңгырый; Себер татарларының «Тамчы тама» җыры халыкның музыкаль бәясен тәшкил итә. Операдагы кайбер арияләр һәм хор күренешләре башкортларның җырларын һәм бию көйләрен хәтерләтә. Шуны да билгеләп үтү мөһим, бу опера революцион көрәшнең массакүләм сәхнә күренешләре белән аерылып тора, аларда беренче мәртәбә, музыкаль тема буларак, «Марсельеза» һәм «Интернационал» чыгыш ясый.

«Эшче» операсының музыкаль теле шактый төрле. Авторлар милли сәнгатьтә әлегә кадәр тиңдәше булмаган яңа темалар

тудыру өчен, традицион пентатоника кысаларыннан аңлы рәвештә чыгарга тырышалар. Мисал итеп, чын халыкчан персонаж сыйфатында Гали бабайны һәм беренче күренешнең төп герое Шаһибәкне китерергә була. Операның дүртенче пәрдәсендә рус-япон сугышы вакытында иҗат ителгән татар халык җыры «Порт-Артур» көеннән файдаланылуы истә кала. Халыкның сугышка карата тискәре йогынтысын ассоцияцияләү өчен, авторлар махсус рәвештә шушы җырга мөрәҗәгать итәләр.

«Сания» һәм «Эшче» операларының әһәмияте хакында 1986 елда ук инде музыка белгече М. Нигъмәтҗанов болай дип яза: «они свидетельствовали о возможности создания татарской оперы на основе национального мелоса и опыта оперной классики» [Нигмедзянов, с. 41].

Йомгаклап, шуны әйтергә кирәк, композиторның иҗаты, халыкның музыкаль традицияләре белән Европа классик музыкасы чараларын кушуда беренче омтылышны ясаучы буларак, татар музыкаль сәнгатенең билгеле бер дәрәҗәдәге фундаментын тәшкил итә һәм аның үсешендәге төп юнәлешләрнең берсен били. Солтан Габәшинең музыкаль мирасы күп ягы белән татар профессиональ музыкаль сәнгате формалашуга яңача якын килергә мөмкнлек бирә. Аның күпкырлы эшчәнлеге сәнгать белеме, музыка белеме һәм музыкаль фольклористика өлкәсендә үзенең актуальлеген югалтмый.

**Әдәбият**


Бражник Л.В. Феномен модального многоголосия в хоровых произведениях Султана Габяши // Султан Габяши: материалы и исследования. Казань, 2000. С. 171–193.

Исанбет Ю.Н. На пути к национальной опере // Газиз Альмухаметов и Султан Габяши в Казани: материалы и документы. Уфа, 1995. С. 7–64.

Макаров Г.М. Султан Габяши и народная музыка // Султан Габяши: материалы и исследования. Казань, 2000. С. 140–156.

Нигмедзянов М.Н. Султан Габяши // Композиторы и музыковеды Советского Татарстана. Казань, 1986. 206 с.

Салитова Ф.Ш. Музыкально-театральные произведения Султана Габяши // Султан Габяши: материалы и исследования. Казань, 2000. С. 193–202.

ОРТ ИЯЛИ. Ф. 60, оп. 1, ед. хр

Файзулаева М.П. Первые татарские оперы «Сания» и «Эшче» // Музыкальная культура народов Поволжья. М., 1978. С. 28–37.

Яңалиф. 1931. № 3. С. 68.



***Галимова Эльмира Мөнир кызы,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге мөдире*

УДК 78:929

*Н.Җ. Айдаров*

# МУЗЫКАГА БАГЫШЛАНГАН ГОМЕР

## *Җ.К. Айдровның хәтер сандыгыннан*

В статье представлены архивные материалы Ж.К. Айдарова – участника первого исполнения в блокадном Ленинграде 7-й симфонии. Д. Д. Шостаковича. Освещается процесс подготовки легендарной премьеры 9 августа 1942 года, работа с дирижером К.И. Элиасбергом, быт и творческая жизнь оркестра Радиокомитета. Воспоминания музыканта публикуются впервые.

**Ключевые слова:** 7-я симфония, Д. Л. Шостакович, К. И. Элиасберг, блокада.

*«Каждый раз по пути в Ленинград на очередную годовщину исполнения Седьмой симфонии я невольно задумываюсь: «Боже! Неужели это было? Неужели истерзанные войной и голодом мы были способны достойно воспроизвести партитуру сложнейшего произведения?» Но, придя в белоколонный Большой зал филармонии, увидев там портреты Шостаковича и дирижера Элиасберга, обняв, увы, немногих коллег, уже не сомневаешься – было»*[1].

Бу юлларның авторы Җәүдәт Кәрәмәтулла улы Айдаров (1918–2000) легендар вакыйгада – Ленинград блокадасы көннәрендә Д.Д. Шостаковичның Җиденче симфониясен беренче башкаруда катнашкан шәхес. Аның тормышы көтелмәгән борылышларга бай. Совет хакимиятенең беренче елларында Үзбәкстанга сөргенгә озатылган мулланың улы Җәүдәт музыкант була...

Җәүдәт Айдаров ун яшендә чакта Ташкентка килеп чыга. Ул да, әти-әнисе тәрбиясеннән аерылган меңнәрчә балалар кебек, балалар йортына барып эләгә. Анда ул язмыш ихтыяры белән үзенең талантына юл ача һәм профессиясен таба. Кечкенәдән музыкага сәләтле Җәүдәт балалар йорты каршында оештырылган тынлы инструментлар оркестрына трубачы булып билгеләнә. Уңышлары да озак көттерми: Айдаровның сәләтен бик тиз абайлап алалар. Ул хәрби маневрлар вакытында атаклы полководецлар С.М. Буденный белән О.И. Городовиков каршында кавалерия сигналларын уйный. Әмма, җәрәхәтләнү сәбәпле, Айдаровка, трубаны гына түгел, башка тынлы уен коралларын да калдырырга туры килә, һәм яшь музыкант бик тиз арада бәрмә уен коралларын үзләштерә.

Үзенең укытучысы Анатолий Тольский киңәше белән Айдров Ташкентта яңа гына ачылган опера һәм балет театры оркестрында уйный башлый. Ә бер елдан соң ул оркестрант юлын Горький һәм Киев шәһәрләре театрларында дәвам итә, шул заманның күренекле дирижерлары җитәкчелегендә концертларда чыгышлар

ясый. Музыкантның осталыгы арта һәм аның 1937 елда Ленинградның Киров исемендәге (хәзер Мария) театрына (конкурсны уңышлы узып) эшкә урнашуы да очраклы хәл түгел. Бер үк вакытта Айдаров М.П. Мусоргский исемендәге музыкаль көллият студенты да (А.И. Чулюкинның бәрмә инструментлар классында) була.

Бөек Ватан сугышы башланганда Җәүдәт Айдаров Ленинград хәрби комендатурасы үрнәк оркестрында эшли. Камалышта калган Ленинград халкы белән бергә, ул да шәһәрне саклап калуга булыша: ныгытмалар төзелешендә катнаша, һава һөҗүменә каршы оештырылган җирле командада экспедитор вазифасын башкара. 1941 елның 16 июлендә әнисенә язган хатында болай ди: «После объявления войны работаем как комендантская команда. Насчёт отправки на фронт ничего не слышно пока»[2]. Бу тема шулай ачык хәлдә кала – аны алгы сызыкка җибәрмиләр, ул «музыкаль фронт сугышчысы» бурычын үтәвен дәвам итә. Җ.К. Айдаровның туганнарына язган сакланып калган хатларында «барысы да тәртиптә», «сау-сәламәтмен» дигән юлларны еш очратабыз, әмма, чынлыкта аның хәлләре яхшы булмый. Күрәсең, камалыштагы Ленинградтан җибәрелгән хатларда рухландыргыч сүзләр, шәһәр турында гомуми мәгълүматлар гына язу рөхсәт ителгәндер, чөнки барлык корреспонденцияләр дә хәрби цензура контроле аша уза торган була. Шуңа күрә Җәүдәт тә күргән газаплары хакында сугыш беткәннән соң гына сөйли.

Блокада чорының иң авыры 1941–1942 еллар кышына туры килә. Ачлык һәм зәһәр суыклар, бомбага һәм артиллерия утына дучар ителү ленинградлыларның үзәгенә үтә. Җәүдәт Кәрәмәтулла улы сөйләвенчә, иптәшләре белән ул да, чарасызлыктан, «рус рулеткасы» уены белән мавыгалар. Пистолет бер патрон белән корыла, барабанны әйләндергәннән соң аны чигәгә куеп, курогын басалар – «йә исән каласың, йә юк». «Һәрчак коточкыч булып пистолет аткан тавыш чыга, һәм шуннан соң син тагын исән...» Әмма тиздән бу мәгънәсез уен туктатыла: анда катнашучыларның барысын да гаупвахтага утырталар. Гаилә хроникасында башка хатирәләр дә саклана: клейстр пешерү процессы һәм аны куллану, соядан шпрот ясау, тире каештан аш пешерү, 200 грамм блокада икмәге өчен чиратлар тору, йорт түбәләрендә дежур торып, фашистлар авиациясе ташлаган яндыргыч бомбаларны сүндерә бару, әсир төшкән немец солдатларын конвоирлау...



Камалышның беренче кышында кичергән коточкыч авырлыкларга карамастан, Айдаров исән кала, аның тормышы зур үзгәрешләр кичерә. 1942 елның язында махсус указ нигезендә ул, вакытлыча, К.И. Элиасберг оркестрына билгеләнә, аның житәкчелегендә Д.Д. Шостаковичның Җиденче симфониясен башкаруга әзерлек барган чак була. 1942 елның җәендә һәркөн диярлек репетиция уздырыла. Аларның ничек үткәрелүе турында Җәүдәт Кәрәмәтулла улы болай яза: «Было очень голодно, холодно. Люди обессилены. Почти все музыканты жили в здании радиокомитета на казарменном положении. Все мы были солдатами МПВО. Во время налетов авиации дежурили на крышах и тушили зажигательные бомбы. Репетировать подряд 3–4 часа не было сил. Губы у духовиков, руки у музыкантов плохо подчинялись музыке. Репетировали в 3 приема понемногу. Но К.И. Элиасберг – дирижёр требовательный, строгий, хотя сам тоже обессиленный, похожий на вопросительный знак – умел добиваться чистого звучания и верного интонирования»[3].

Җиденче симфония репетицияләре вакытында барабанчы тормышында фаҗигале хәл дә килеп чыга. Бер көнне ул репетициягә килми. К.И. Элиасбергның «Ударник кая?» дигән соравына «Ул үлекләр бүлмәсендә», дип җавап бирәләр. Дирижер, ышанмыйча, тикшерергә үзе китә. Җ.К. Айдаров, чыннан да, ачлыктан аңын югалтып, мәетләр арасында ята икән. Аны терелтәләр; өстәмә бер сынык ипи аңа көч өсти, үлемнән коткарып кала. Бу вакыйга музыкант күңеленә гомерлеккә сеңә.

Тыныч заманнар өчен кеше ышанмаслык очраклар блокадада калган оркестрантларның хәлен үзенән-үзе билгели. Әйтик, маракасның «тавыш эчлеге» (мәгълүм булганча, анда үсемлек орлыклары – гадәттә барчак яки карабодай салына) үзенең турыдан-туры максатында, ягъни азык буларак файдаланыла. Ә үсемлек орлыкларын кадаклар алыштыра... К.И. Элиасберг, репетиция вакытында башка төрле тембр яңгыравын ишетеп, гаеплеләрнең хәлне төзәтүен таләп итә.

1942 елның 9 августында булган премьераның ничек узуы хакында Җәүдәт Кәрәмәтулла улы төрле иҗади кичәләрдә күп тапкырлар сөйли. Бу мәкаләдә музыкантның шәхси архивындагы истәлекләрдән түбәндәге өзекне тәкъдим итәбез.

«Я, как участник первого исполнения 7-й симфонии Шостаковича в Ленинграде, всегда, когда меня просят рассказать об этом, выполняю просьбу с волнением, с чувством большой ответственности. Ибо это не просто рассказ о большом историческом событии в жизни советской музыки. Это – низкий поклон перед светлой памятью погибших во время блокады музыкантов, низкий поклон перед светлой памятью гениального композитора нашей эпохи Дмитрия Дмитриевича Шостаковича, низкий поклон перед памятью замечательного дирижера Элиасберга. Именно они, ленинградские музыканты,

вместе с бойцами Ленинградского фронта, показали стойкость, мужество советских людей.

Первое исполнение 7-й симфонии – и для меня незабываемое событие на всю жизнь.

А было это так. Идут ожесточённые бои. Враг стремится в Ленинград. В начале августа 1941 года дан приказ эвакуировать творческие коллективы. Эвакуировался Заслуженный коллектив республики – симфонический оркестр Ленинградской Филармонии в г. Новосибирск, в Пермь – Театр оперы и балета им. СМ. Кирова, в Оренбург – Малый Оперный театр. Консерватория была эвакуирована в Ташкент.

Большой симфонический оркестр Ленинградского Радиокомитета и Театра музыкальной комедии – единственный музыкальный коллектив – остался в осаждённом Ленинграде. Оркестр каждый день выступал по Радио. Обратим внимание на то обстоятельство, что тогда не было записи на магнитофон. Было ежедневное, ежеминутное живое непосредственное выступление у микрофона! Симфонический оркестр ежедневно играл. В программе – Чайковский, Глазунов, Бетховен, Моцарт, Брамс... Ленинградские музыкальные передачи транслировались для Англии, Франции... Весь мир знал, что Ленинград борется, что в Ленинграде жизнь кипит.

Оркестр работал под управлением крупного дирижера – Карла Ильича Элиасберга. Он, как большой, эрудированный, высококвалифицированный и одаренный дирижер, умел вести оркестр к цели, умел добиваться идеального звучания оркестра. Он также умел давать возможность каждому из нас проявлять свое творческое отношение к произведению. Карл Ильич был таким музыкантом, который не шел позади композитора, а стремился встать рядом с ним. Симфонические радиоконцерты часто шли под бомбежкой и артиллерийским обстрелом. Почти все музыканты жили на казарменном положении, состояли в команде МПВО – во время воздушных налетов дежурили на крышах и чердаках, тушили зажигательные бомбы.

Недалеко от Радиокомитета в гостинице “Астория” создали стационар для особо истощенных, дистрофиков. Сюда был направлен со своей женой – замечательной пианисткой, концертмейстером радио, Надеждой Дмитриевной Бронниковой, дирижер Карл Ильич Элиасберг. Здесь же, в “Астории”, находился истощенный голодом выдающийся пианист Владимир Владимирович Софроницкий.

В симфоническом оркестре в начале войны было свыше 100 музыкантов. Каждый день смерть уносила их жизни, и оркестранты рассказывали, что после каждой передачи они кого-то уже заставали мертвым. Музыкантов оставалось мало. Всего 27 человек. Оркестр уже не мог давать концерты симфонической музыки. В то время из Куйбышева на самолете штаба Ленинградского фронта спецрейсом была достав-




лена партитура 7-й симфонии Шостаковича. Симфония, посвященная Ленинграду, должна звучать в Ленинграде.

Встал вопрос о необходимости пополнения оркестра. Решили обратиться в штаб Ленинградского фронта, ведь многие музыканты с оружием в руках защищали город. Просьба Радиокомитета была удовлетворена. Музыканты, находившиеся в армии и во флоте, получили предписание прибыть в Ленинград на ул. Малую Садовую, 6 – в Радиокомитет, имея при себе музыкальные инструменты. Учтите, товарищи, это происходило в самое тяжёлое время блокады. Когда были на учете каждый боец, каждая винтовка, каждая крошка хлеба. Я тоже был откомандирован из своей воинской части.

Обновленный состав оркестра возобновил симфонические концерты по радио и выступал в знаменитом Большом зале. Ленинградской Филармонии, носящей теперь имя Шостаковича. Этому коллективу выпала честь первым исполнить в осаждённом Ленинграде Седьмую симфонию, посвященную городу Ленина.

Это было 9 августа 1942 года, в 19 часов. Осажденный Ленинград. Поразительная тишина. (Перед этим наши артиллеристы огнем подавили вражеские батареи, выполняя приказ "80 минут тишины") Зал был переполнен. Много было военных, рабочих, много интеллигенции. Были на концерте известные писатели Николай Тихонов, Ольга Берггольц, Всеволод Вишневский и другие. Вот на эстраду выходят музыканты, кто в гимнастерках, кто в кителях, кто в ватниках. Музыканты одеты, кто во что. Последним выходит наш строгий, требовательный, удивительно обаятельный Карл Ильич. Он очень высокий, худой, и от голода, кажется, он согнулся как

вопросительный знак. Он поднял руки. Дирижерская палочка трясется от волнения. Я исполнял на ударных инструментах тему нашествия врага и, наверно, с ожесточенным чувством ненависти к фашизму. Оркестр играл вдохновенно. Симфония окончена. В зале воцаряется небывалая тишина. Дирижер Элиасберг стоит не двигаясь. И вдруг буря аплодисментов. Маленькая девочка преподносит Элиасбергу букетик цветов с запиской: "С признательностью за сохранение и исполнение музыки в осажденном Ленинграде. Семья Шнитниковых". [...]

Симфония транслировалась по радио. Из Москвы в тот же вечер Шостакович прислал нам телеграмму с поздравлением.

Через 3 года после окончания войны в гостинице "Астория" произошла встреча Ленинградской интеллигенции с группой приехавших из Германии немецких специалистов. Сидящие на банкете невольно вспомнили, что именно здесь, в "Астории", Гитлер назначил торжественный банкет в честь победы над Ленинградом. Уже были отпечатаны пригласительные билеты...

Вдруг к Элиасбергу (а он был приглашен на этот банкет [по случаю завершения Великой Отечественной войны и победы над фашизмом. – *Н.А.*] подошли двое из гостей [бывших советских бойцов. – *Н.А.]* и попросили перейти к другому столику. Один из них был крупным инженером, он рассказал, что был артиллеристом на фронте под Ленинградом в Петергофе, что он – любитель музыки, слышал все передачи симфонического оркестра и даже записал даты и программы концертов.

Он спросил: "Как удалось Вам создать в таких нечеловеческих условиях первоклассный оркестр и сделать так, чтобы он играл! Я потрясён!".

Тогда советский дирижёр рассказал, как он зимой 1942 года лежал на 7-м этаже этого самого здания, как лежали и умирали от голода, дистрофии многие музыканты. Элиасберг рассказал, как застывшими пальцами занимался на рояле Софроницкий, готовя свои программы. Как ему самому, падающему от голода, люди помогли подняться и встать за дирижёрский пульт»[4].

Ленинград блокадасында калган көннәрдән башлап, К.И. Элиасберг Айдаров өчен дә, аның гаиләсе өчен дә иң якын кеше булып китә, алар хатлар алышып яшиләр. Язмыш аларны берничә мәртәбә очраштыра. Шулар арасыннан күңелендә аеруча хисләр уяткан очрашулары хакында Җ.К. Айдаров үзенең мәңге онытылмас укытучысының, өлкән иптәше, дустының якты истәлегенә багышланган хатирәләрен язып калдыра.

1970 еллар ахыры датасы куелган түбәндәге документта авторның үз стиле тулысынча саклана, баш һәм юл хәрефләре бирелеше генә дөрес язуның бүгенге нормалары нигезендә бирелә, күренеп торган хаталар һәм төшереп калдырылган тыныш билгеләре махсус искәртеп үтелә. (Текст, автор үзе язганча, рус телендә тәкъдим ителә. – *Ред.*).

**«Великий мастер оркестра**

Первые впечатления у музыкантов – самые сильные и очень стойкие. Они обычно остаются на всю жизнь. И хотя мои встречи с К.И. Элиасбергом не были постоянными, он сохранился в памяти как великий мастер оркестра, как заботливый педагог и требовательный руководитель.

Знакомство с Большим симфоническим оркестром и К.И. Элиасбергом произошло в 1939 году. Предыстория была такова. В начале этого года при Ленинградском Радиокомитете был организован малый симфонический оркестр. Он целиком состоял из артистов симфонического оркестра Ленинградского государственного академического Театра оперы и балета имени С.М. Кирова. А организатором и инспектором, точнее, душой вновь созданного коллектива музыкантов был М.И. Ратнер – концертмейстер группы виолончелей. Михаил Исаакович – великолепный музыкант, очень хороший человек, отзывчивый товарищ. Он пользовался большим уважением оркестра. Главным дирижером был Семен Осипович Брог. Он остался в моей памяти как человек большой культуры и интеллигентности. В этот Малый симфонический оркестр приглашен был и я. В то время не было еще даже понятия о записи. Оркестр выступал непосредственно у микрофона. Исполнение было, как сейчас говорят, “живым”. Оно шло прямо в эфир. Наш малый симфонический оркестр, в основном, исполнял произведения популярной классической музыки. [...]

Видимо, меня заметили на радио, и однажды инспектор БСО Алексей Романович Прессер пригласил для участия в исполнении Фантастической симфонии Берлиоза партии 2-х литавр в IV части симфонии “Шествие на казнь”. На репетиции симфонии состоялось мое первое знакомство с К.И. Элиасбергом. [...]

Встречи с К. И. Элиасбергом вне музыки для меня остались настоящей школой культуры в быту. Его короткие, меткие замечания не только врезались в память, но и принимались, как правило, действия. Его отношение к людям, к родным, к близким были для меня также добрым примером.

Летний день 1943 года. В редкий час, когда не было артиллерийского обстрела, К.И. Элиасберг предложил мне поехать с ним на кладбище, на могилу его родителей. Едем. Он и я на велосипедах. Я как-то нечаянно наехал на Карла Ильича. Он выругал меня.

Выругал внушительно. Доехали. Подошли к могиле. Помнится надгробие из белого мрамора. Он сел около памятника, на руку положил голову и минут 15 сидел задумчиво, молчаливо. Я остановился чуть дальше от него. Я не смел расспрашивать о его родителях. В его молчании, задумчивости, казалось, была невысказанная боль утраты близких.

Карл Ильич особо радовался в обществе музыкантов. В [блокадный] Ленинград приехал Эмиль Гилельс. Был он у Карла Ильича в гостях. Шел радушный разговор о музыке И.Ф. Стравинского. В этот приезд Эмиль

Гилельс исполнил “Петрушку” Стравинского. Исполнять Стравинского в те годы (1944 г.) было большой смелостью.

С 1963 года в городах Поволжья, где проходила жизнь В.И. Ленина, стали проводить музыкальный весенний фестиваль Поволжья, посвященный дню рождения вождя. В 1965 году на Ленинский фестиваль был приглашен Карл Ильич. В Казани он дирижировал 9-й симфонией Бетховена. Симфонические концерты прошли с небывалым успехом[5]. Карл Ильич радостный пришел к нам домой. Много шутил. По татарскому обычаю жена моя Зайнаб[6] приготовила пельмени с бульоном. Пельмени мелкие. (Есть обычай у татар: чем почетнее гость, тем мельче должны быть пельмени). Это Карла Ильича рассмешило. Он все просил ответить, могут ли быть пельмени еще меньше размером, чем те, которые были в тарелке перед ним.

Нежно говорил о Надежде Дмитриевне [Бронниковой]. Надежда Дмитриевна, отличная пианистка, блестящий концертмейстер Ленинградского радио, была для Карла Ильича любящей женой, заботливой матерью, настоящим другом, советчиком. Я преклоняюсь перед их взаимопониманием.

Настал час расставания. Карл Ильич стоит у дверей. На нем демисезонное светло-серое пальто. Сшито оно очень хорошо, красиво облегает стройную фигуру нашего гостя. Мы с женой говорим ему об этом; а он нам серьезно отвечает:

– Надо красиво одеваться. Все должно быть аккуратно. Шьют хорошо в Риге. Заказывать себе одежду я езжу в Ригу. Советую и Вам, Джаудат, следи за своей стрижкой. И здесь нужна опрятность. Волосы от висков должны быть короткими. Это придает лицу моложавость и аккуратность. Запомни.

Таким веселым разговором мы расстались с ним в конце апреля 1965 года.

1970 год. Май. Празднуем 30-летие Победы над фашизмом. По приглашению Ленинградской филармонии прилетел я на встречу с музыкантами оркестра Ленинградского радио. В Доме композиторов шёл вечер, посвященный этому торжеству. Встречаемся с Карлом Ильичем. Он нас приглашает к застолью композиторов. Первый тост произносит Андрей Петров. С воспоминаниями о фронтовых поездках с юмором рассказывает В.П. Соловьев-Седой. Карл Ильич больше слушает, говорит мало. На другой день мы с ним встретились в зале Ленинградской филармонии. На концерте исполнялась Седьмая симфония Д.Д. Шостаковича. Вступительное слово сказал М.С. Вайнберг. Зал горячо аплодировал первым исполнителям Седьмой Симфонии Шостаковича в осаждённом Ленинграде 9 августа 1942 года. В антракте слушатели потянулись к музыкантам-блокадникам за автографами. Особо горячо аплодировали ленинградцы поэту Ольге Берггольц и К.И. Элиасбергу. В этот вечер Карл Ильич не дирижировал. Почему? Этот вопрос остал-

ся для меня непонятным. Карл Ильич молчал. Молчал он и на банкете, состоявшемся после концерта. Какая-то несправедливость давила его. Так мы решили с женой. С грустью вспомнили слова Надежды Дмитриевны: "Ему не дают работать".

1974 год, 24-е января. Большой зал Московской консерватории. Концерт Симфонической музыки. В программе Поэма "Памяти жертв блокады Ленинграда" для струнных, труб, органа, двух фортепиано и ударных Андрея Петрова и 9-я симфония Бетховена. После окончания концерта спешу в артистическую. Комната полна гостями. Карл Ильич в окружении артистов хора и музыкантов. Горячо его поздравляет И.С. Козловский. Карл Ильич счастлив, рад. Он улыбается и говорит, что у него на завтра назначена репетиция и запись, будет работа. Ведь Карл Ильич видел свое счастье только в творчестве. Таким он мне запомнился в последний раз. Берегу программку этого концерта с его автографом: "Дорогой друг Джаудат! Горячо тебя обнимаю, часто вспоминаю и желаю тебе доброго здоровья! К. Элиасберг. 27/1 1974"»[7].

Җ.К. Айдаров гомере буе бөтен барлыгы белән сәнгатькә хезмәт итә. Педагогик хезмәткә күп көч куя, Идел буе регионының күренекле мәдәни эшлеклесе дәрәҗәсенә күтәрелә[8]. Ул чын мәгънәсендәге зыялы шәхес. Профессионал-музыкантка хас булганча, югары интелектуаль сыйфатлар аның гомерлек юлдашы булып кала. Мөгаен, бу очраклылык түгел. Ленинград камалышы вакытында кичергән газаплары аның характерын ныгыта, яшәешнең тәрбиялелек, ярдәмчелек, игелеклелек һәм гаделлек кебек сыйфатлары аның шәхесенә тирән тамырлана.

Яшь музыкантлар каршында ясаган чыгышларының берсен ул мондый юллар белән тәмамлый:

«Мне часто задают вопрос: "Как Вы исполняли Седьмую симфонию Шостаковича? Вы же были все обессиленные?" С тех пор прошло более 40 лет. Естественно, многие детали стерлись из памяти. Но одно незабываемо: чувство радости от того, что наш симфонический оркестр живет, что слушать нас пришли Ленинградцы – самые стойкие люди страны – и чувство ненависти к фашизму. Эти два чувства наполняли нас несказанной силой. Скажу со всей ответственностью, что мы играли неплохо. Симфония звучала убедительно. Всем известна истина: судьба произведения, его будущее – в руках исполнителей. Мы донесли до слушателей изумительное содержание симфонии Шостаковича.

Силу нам давала вера в победу. Желание жить и победить заставляло нас играть как можно лучше. [...]

Из пережитого делаю один вывод: велика сила музыки. Она объединяет людей, она поднимает людей на подвиг. Если бы мне предложили заново начать жить, заново выбрать себе профессию, я остался бы верен музыке. Стал бы музыкантом, но приложил бы все свои способности быть еще лучшим»[9].

## Искәрмәләр

[1] *Айдаров Д.* «Ленинградская» – навсегда останется симфонией подвига // Вечерняя Казань. 1992. № 176 (436). 18 декабря. С.3.

[2] Мәкаләдә китерелгән өзекләр һәм документлар Җ.К. Айдаровның шәхси архивында саклана.

[3] Җ.К. Айдаров 1984 елның 17 февралендә Казан укучылары белән очрашу өчен әзерләгән истәлекләрнең фрагменты. Ул гаилә архивында саклана.

[4] Текст 1982 елның 16–18 октябрендә язылган.

[5] Концерт СССР дәүләт оркестры катнашуында 1965 елның 19 апрелендә була.

[6] Зәйнәп Шәйхулла кызы Хәйруллина (1916–2010) – музыка белгече. ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе (1991). 1932–1958 елларда (өзеклекләр белән) Татарстан радиосында (диктор, мөхәррир, сәнгать тапшырулары җитәкчесе), 1958–1961 елларда Казан телевидениесе студиясендә (директор, мөхәррир), 1962–1973 елларда ТАССР Композиторлар берлеге җаваплы сәркатибе. 1944 елдан башлап, 1976 елга кадәр, әйтеп үтелгән вазифалардан тыш, Татарстан филармониясендә концерт программаларын алып бара, лекцияләр укый. Татар музыкаль сәнгатенә караган хезмәтләр авторы. Җ.К. Айдаровның күп кенә текстлары, шул исәптән биредә бирелгәннәре дә, тормыш иптәше З.Ш. Хәйруллинаның турыдан-туры катнашында языла.

[7] Әлеге хатирәләр тексты 1970 еллар ахырында язылган.

[8] Җ.К. Айдаров 1951 елда Ленинград консерваториясенең дирижер-хор бүлеген (А.В. Михайлов классында) тәмамлый. Чита радиокомитетында Халык уен кораллары оркестры дирижеры (14951–1952 еллар), Ленинградтагы Ижор заводының хор капелласы сәнгать җитәкчесе (1953–1958 еллар), Карелия «Кантеле» ансамбле хормейстры һәм Мәскәүдә уздырылган Карелия сәнгате ункөнлегендә баш хормейстр (1958–1959 еллар), ТАССРның җыр һәм бию ансабле сәнгать җитәкчесе (1959–1965 еллар), Казан консерваториясенең халык уен кораллары кафедрасы укытучысы (1965–1975еллар), Казан консерваториясе каршындагы махсус музыка мәктәбе директоры (1969–1973 еллар), Казан музыка көллияте укытучысы (1975–1998 еллар) була.

[9] Текст 1982 елның 16–18 октяберендә язылган.

*Мәкалә авторы, эшлекле киңәшләре һәм изге теләкләре өчен, Андрей Николаевич Крюковка, Виктор Васильевич Козловка һәм Инна Васильевна Селивановага тирән рәхмәтен белдерә.*

***Айдаров Нәдим Җәүдәт улы,***
*Россия сәнгать тарихы институты фәнни хезмәткәре*
*e-mail: n.aidarov@yandex.ru*

УДК 791.43

*Д.Р. Фәрдиева*

# XII ХАЛЫКАРА МӨСЕЛМАН КИНОСЫ ФЕСТИВАЛЕНӘ КҮЗӘТҮ

В статье дается обзор XII Казанскому международному фестивалю мусульманского кино. Фестиваль проходит в Казани с 2005 года. В программу фестиваля отбираются фильмы, отражающие общечеловеческие духовно-нравственные ценности и культурные традиции, несущие идеи миротворчества, веротерпимости и гуманизма вне зависимости от вероисповедания автора.

**Ключевые слова:** фильм, режиссер, фестиваль, картина, номинация, автор.

2016 елның 5–11 сентябрь көннәрендә Казаныбызда XII Халыкара мөселман киносы фестивале булып узды. Әлеге фестиваль 2005 елдан бирле уздырыла һәм Татарстанның күркәм традициясенә әверелде. Бу дәвер эчендә Татарстанда исемнәре шактый яңгыраган, популярлык казанган кино-режиссерлар, кино белгечләре булып китте. Елдан-ел фестивальдә катнашучыларның, тәкъдим ителгән картиналарның саны арта бара. Чарада гомумкешелек кыйммәтләрен беренче планга куйган картиналар тәкъдим ителә. Мөселман киносы фестивале, төрле илләр режиссерларының иҗаты белән танышып, сәнгатьнең бу төренә дөньякүләм мәдәният киңлегеннән якын килергә ярдәм итә. Фестиваль программасына авторларның, нинди диндә булуына карамастан, тынычлыкка, игелеклелеккә, гаделлеккә өндәүче әсәрләрен экранлаштырган кинематографлар эшләре сайлана. Быелгы фестивальгә төрле илләрдән 700 дән артык гариза килгән, конкурс программасына фильмнарны кино белгече Сергей Лаврентьев җитәкчелегендәге комиссия сайлап алган. Фестиваль бүләкләре өчен 33 илдән тулы метражлы уен, кыска метражлы уен, тулы метражлы документаль, кыска метражлы документаль, анимацион метражлы фильм номинацияләрендә 60 номинант көрәште. Татарстаннан 18 фильм сайлап алынган иде, конкурс программасы кысаларында шуларның алтысы күрсәтелде.

«Халыкара мөселман киносы фестивале кинематография ягыннан да, үзара мөнәсәбәтләрне көйләү ягынннан да бик үзенчәлекле вакыйга. Монда бик борынгы мәдәнияте һәм кино өлкәсендә зур традицияләре булган илләр тәкъдим ителә», – диде фестивальнең жюри рәисе, атаклы кинорежиссер, Россиянең халык артисты Александр Прошкин. Ул бу проектта әле яңа кеше, моңарчы бу чара турында хәбәрдар булмавын да яшермәде. Жюри рәисе, шулай ук, Мөселман киносы фестива-

ленең илдә үз урынын яулавын, башка илләрдә дә кызыксыну уятканын бәян итеп узды. Әлеге фестивальнең максаты – Россия мәдәни эшлеклеләренең үзара тәҗрибә уртаклашуы һәм бөтен дөнья кинематографистларының иҗади казанышларын халыкка таныту. Бәйге программасына гомумкешелек, рухи-әхлакый кыйммәтләрне һәм мәдәни горефгадәтләрне чагылдырган, төрле диндәге авторларның диннәргә тигез карашын һәм гуманизм идеяләрен алга сөргән фильмнар сайлап алынган. Быелгы фестиваль чаралары Россиядә кино елы шигаре астында узды. Фильмнарга тамашачыларны җәлеп итү чаралары да арткан. Фильмнар, «Родина» һәм «Мир» кинотеатрларыннан тыш, «Корстон» сәүдә үзәге кинотеатрында һәм, беренче тапкыр, Иннополиста, «Акт» театрында күрсәтелде.

Алдагы еллардан аермалы буларак, быелгы конкурс программасына сайлап алынган фильмнар бу фестивальне үз иткән тамашачылар өчен генә түгел, киң аудитория өчен дә кызыклы булды. Фестивальнең үзенчәлеге шунда ки: биредә, яшь режиссерларның фильмнары белән бергә, инде дөнья күләмендә танылган режиссерларның эшләрен дә күрү мөмкинлеге туды. Быелгы фестивальнең тематикасын мондый төп юнәлешләргә аерырга була: традицион исламның тарихы, Сүриядәге һәм Әфганстандагы сугыш, аерым шәхесләрнең батырлыгы, иммигрантлар, бәйсезлек һәм суверенитет темалары. Тәкъдим ителгән фильмнарның географик колачы да шактый киң – Гыйрак, Иран, Бәһрейн, Һиндстан, Төркия, Бангладеш, Россия, Әфганстан, Франция, Кыргызстан, Ливан, Катар, Таҗикстан, Швеция, Мисыр, Беларусь, Грузия, Гарәп Әмирлекләре һ.б.

Фестиваль башланган көнне тамашачыларга Иран режиссеры Мәҗид Мәҗидинең «Мөхәммәд – Аллаһ илчесе» дигән картинасы тәкъдим ителде. Фильм конкурстан тыш программада күрсәтелде, ягъни фестивальне ачып җибәрде. Мәҗиди әлеге әсәрен ун елга якын төшергән. Фильм Мөхәммәд пәйгамбәрнең балачагын яктырта һәм ул «Мөхәммәд пәйгамбәрнең тормышы» трилогиясенең беренче өлеше. Шулай ук фильм ислам дине барлыкка килүнең Көнбатышта артык билгеле булмаган тарихи чорын тасвирлый. Режиссер Мәҗиди үзе бу фильм турында болай сөйли: «Мин бу фильм белән бөтен дөньяга рәхмәт өчен җибәрелгән Пәйгамбәребезнең шәфкатьлелеге аша Ислам диненең тынычлык, мәхәббәт, игелеклелек һәм гуманлылык дине икәнлеген күрсәтергә омтылдым. Ислам дине кешенең бөеклеген барыннан да өстен куя». Чыннан да, «Мөхәммәд – Аллаһ илчесе» фильмы кеше шәхесенең бөтен матурлыгын һәм гуманлылыгын күрсәтә. Мөхәммәд образы аша тамашачыларга Ислам диненең хаклыгы, сафлыгы җиткерелә. Гомумән, «Мөхәммәд – Аллаһ илчесе» фильмы, югары дәрәҗәдә эшләнүе белән, хәзерге Иран кино сәнгатенең йөзен ачык күрсәтте һәм Казан мөселман кино фестиваленә символик старт бирде.

Фестивальнең төп номинациясендә – тулы метражлы уен фильмына Сергей Потаповның «Божество Дьесегой» (Россия, Якутия), Антоний Дончевның «Женщина моей жизни» (Болгария, Гыйрак-Курдистан, Македония, Румыния), Абу Шахед Эмонның «Җәләл язмышы» (Бангладеш), Баянерулның «Норжмаа» (Кытай), Досхан Жолжаксыновның «Кунанбай» (Казакъстан), Дастан Жапар углы һәм Бакыт Мукулның «Ата васыяте» (Кыргызстан) һ.б. картиналар күрсәтелде. Әлеге номинация фильмнары фестиваль бүләкләренең күбесенә лаек булды: алар – «Иң яхшы ир-ат роле», «Иң яхшы тулы метражлы уен фильмы», «Иң яхшы тулы метражлы уен фильмы операторы», «Иң яхшы тулы метражлы уен фильмына сценарий», «Иң яхшы хатын-кыз роле», «Иң яхшы тулы метражлы уен фильмы режиссеры».

«Иң яхшы тулы метражлы уен фильмы» итеп Иран режиссеры Һади Мохагхехның «Үлемсез» картинасы танылды. Биредә бөтен гаиләсен югалткан 60 яшьлек ир-ат турында сүз бара. Әлеге фильм «Тулы метражлы уен фильмында иң яхшы оператор» бүләгенә дә ия булды (фильм операторы Рузбех Райга). «Иң яхшы тулы метражлы уен фильмы режиссеры» итеп Якутиядән Сергей Потапов («Божество Дьесегой» фильмы өчен), ә «Иң яхшы сценарий авторы» итеп Сербиядән Вук Ршумович («Ничье дитя» картинасы өчен) билгеләнде. «Ничье дитя» фильмында урманда кыргый булып үскән малайның яңа тормыш шартларына җайлашуы турында сүз бара. Аны балалар йортына алып килеп, сугышта катнаштыру өчен әзерлиләр. Вакыйгаларның мондый көтелмәгән борылыш алуы тамашачыда шомлы тәэсирләр калдыра.

Фестивальдә аерым урынны Ренат Хәбибуллинның «Мәрҗани мәчете. Гамәлгә ашырылган гореф-гадәтләр тарихы» дигән фильмы алды. Бу фильм «Кыска метражлы документаль фильм» номинациясендә катнашып, Казан шәһәре мэрының махсус бүләгенә ия булды. Фильм Мәрҗани мәчетенең тарихын бәян итә. Кино тәнкыйтьчеләре әлеге кыска метражлы фильмны «тирән мәгълүмат бирүче әсәр» дип атады. Ә «Иң яхшы кыска метражлы документаль фильм» номинациясе җиңүчеләре итеп ике фильм билгеләнде – Алижан Насыровның «Ата Бәйит» (Кыргызстан) һәм Руслан Вәлиевның «З/К» (Россия, Татарстан). «З/К» фильмының героинясы татар кызы Рәйхан Әфган сугышы вакытында Кабул госпиталендә эшли һәм 1990 елгы вакыйгалар турында сөйли. Сугыш утында булып, үлем һәм җәрәхәтләнүләрне күп күргән, яраланган солдатларга үз канын биргән кыз, үз илендәге үзгәртеп корулар чорында түрәләрнең түбәнсетүе, эшендәге хезмәттәшләренең кырын карашлары белән очраша.

«Ата Бәйит» картинасында исә сүз, күренекле язучы Чыңгыз Айтматовның атасы (репрессия корбаны) Торакул Айтматов кабереn эзләве турында бара (Т. Айтматов 1938 елда атып үтерелә). Фильм кыска метражлы булганга

күрәдер, Ч. Айтматовның үзенә аз тукталганнар.

«Анимацион фильм» номинациясендә Россия авторларының фильмнары әйдәп барды (П. Минаеваның «Душа короля», Алена Ребезованың «Долесу», Сергей Киаровның «Стрела наследия», Марина Карпованың «Мама цапля», Елизавета Стариковaның «Никому» картиналары). Россия фильмнарыннан тыш, әлеге номинациядә Иран, Төркия, Украина авторларының эшләре дә катнашты.

Гадәти номинацияләрдән тыш, быелгы фестивальдә «Яшь Россия» дип аталган яңа бәйге номинациясе кертелгән иде. Аңа Россия режиссерларының төрле жанрлардагы фильмнары һәм альманахлары керде. Номинация кысаларында шулай ук «Гыйшык алмасы», «Антигона», «Пилорама», «Ялгызлык җире», «Шишел-мышел» фильмнары тәкъдим ителде. Иң яхшы фильмнар итеп Кирилл Плетневның «Мама» һәм Андрей Носковның «Личное дело» картиналары танылды.

Россия белгечләренең һәм кино тәнкыйтьчеләре гильдиясенең махсус бүләген – «Фестиваль сөрәненә туры килгән һәм гаилә кыйммәтләренә үзенчәлекле караш өчен» Тунку Мона Ризаның (Малайзия) «Көндәмлек» дигән фильмы алды. Шулай ук әлеге фильм Татарстан Республикасы Президентының «Кино сәнгатендә кешелеклелек өчен» дигән бүләгенә дә ия булды. Ә «Иң яхшы ир-ат роле» бүләген бу фильмда уйнаган актерлар Хариц Хазиг, Иззи Риф, Намрон алдылар. «Көндәмлек» фильмы Мона Ризаның дебют фильмы булса да, ул Казан тамашачыларында тирән тәэсирләр калдырды. Картина аутист балалар темасын яктырта, аларның социаль адаптацияләнү һәм дөньяви мөнәсәбәтләре турында сөйли.

Россия кино белгечләренең һәм кино тәнкыйтьчеләре гильдиясенең «Рәссам язмышына карата игътибар һәм иҗади бердәмлек өчен» дипломына рус-испан фильмы «Заговор сумашедших» (режиссеры Альгис Арлаускас) һәм «Баланың сугышсыз дөньяга ышанычын гәүдәләндерү өчен» дипломына Сүрия фильмы «Ясмин» (режиссеры Әлмөхәммәд Кальфум) ия булдылар. Жюри шулай ук режиссер Мурад Ибраһимбәковны «Дагстаным. Тәүбә истигъфар» (Россия, Дагстан) фильмы өчен бүләкләде. Фильм шагыйрь Рәсүл Гамзатовның атаклы китабы «Дагстаным» мотивлары буенча төшерелеп, аның тормышын яктырта. Биредә шагыйрь турында туганнары, дус-ишләре, сәясәтчеләр, актерлар һәм шагыйрьләр үзләренең истәлекләре белән уртаклашалар. Параллель рәвештә шагыйрь хатирәләреннән өзекләр һәм аның шигырьләре укыла.

Башка еллардан аермалы буларак, быелгы фестивальдә жюри ике секциядә эшләде: беренчесе төп конкурс программасына кертелгән картиналарны тикшерсә, икенчесе «Яшь Россия» номинациясендә катнашучы әсәрләргә бәя бирде.

Паралелль программаларның берсе кысаларында татар әдәбияты классиклары М. Җәлил,

Г. Тукай, Г. Әпсәләмов иҗатларына багышланган фильмнар күрсәтелде («Моабит дәфтәре», «Батырлык гасырларда кала», «Тукай», «Шүрәле», «Сүнмәс утлар», «Фильм турында фильм. Ак чәчәкләр»). Шулай ук танылган режиссерлар Сиддик Бармак, Алексей Барыкин, Александр Прошкин, Усман Сапаровлар төшергән фильмнарның ретроспективасы тәкъдим ителде.

Фестивальнең белем бирү өлешен «Кино заманы II» форумы тәшкил итте. 2015 елда ул беренче тапкыр уздырылды һәм профессионаллар тарафыннан уңай бәя алып, зур кызыксыну уяткан иде. Быелгы форумда исә Россиянең төрле кино мәктәпләре, шул исәптән Никита Михалков академиясе мөгаллимнәреннән төрле презентацияләр һәм мастер класслар уздырылды. Шулай ук фестивальдә катнашучылар белән иҗади очрашулар, актуаль кино мәсьәләләренә багышланган түгәрәк өстәлләр һәм пресс-конференцияләр уздырылды.

Җиде көн дәвамында барган кинофестивальнең ябылу тантанасы М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинсында булды. Җиңүчеләргә Казан фестивале символы – Сөембикә манарасын сурәтләгән истәлекле сыннар тапшырылды. Мөселман киносы фестивале елдан-ел камилләшә, ә иң мөһиме – кыйбласын ачыклый бара. Әлеге сыйфат сайлап алынган картиналарда да чагылыш таба.

***Фәрдиева Динара Радий кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге фәнни хезмәткәре*

# АЛИШЕВ С.Х. ГАЛИШАҺ МОРЗА НӘСЕЛЕ

Отзыв посвящен последнему труду известного татарского историка доктора исторических наук Саляма Хатиповича Алишева (1929–2015), жанр которого автор определил как «роман-хроника». В нем повествуется о представителях десяти поколений рода Алишевых (потомков мурзы Галишаха). Произведение состоит из трех книг, каждому из которых соответствует определенная историческая эпоха: вторая половина XVI – XVII вв.; XVIII век и XIX – первая половина XX вв. О жизни и деятельности представителей рода С.Х. Алишев повествует на широком историческом фоне, часто привлекая документальные источники, а также «деревенские легенды» своих предков. Благодаря этому возникает проникновенная картина мира, состоящая из трех частей: «история рода», история народа» и «история страны».

В первой книги «романа-хроники» через образ Галишаха и его сыновей воссоздана жизнь татарских мурз, с этнографической точностью излагаются сюжеты об основании новой деревни, свадебных обрядах и женитьбе представителей татарской элиты.

После приписки Петром I татарских мурз в государственные крестьяне, потомки мурзы Галишаха превратились в представителей податного сословия. Поэтому во второй и третьей книгах «романа-хроники» главные герои – деревенские муллы, жизнь и повседневные заботы которых показаны на фоне трудовых забот, горестей и радостей крестьян-хлебопашцев. Автор не уделяет внимания на теологические вопросы и сосредоточился, главным образом, на социальном поведении мулл, на их взаимоотношениях с прихожанами. Наряду с исполнением религиозных обязанностей, потомки Галишаха во многом выступают в качестве лидера односельчан, через родственные связи формируют клан духовных лиц в округе. Наиболее видным представителем этого клана, завоевавшим большой авторитет среди населения, является ишан д. Кизляу Губайдулла (1751–1823). Роман завершается рождением в 1929 г. у муллы Хатипа сына Саляма.

Написание историком-профессионалом историко-художественного произведения требует определенной смелости. Как правило, творческое начало, фантазия писателя и историческая реальность – несовместимые вещи, очень часто противоречат друг другу. «Роман-хроника» С.Х. Алишева в этом отношении представляет исключение: мысли историка и писателя взаимно дополняют друг друга. В этом, на наш взгляд, заключается успех исторического произведения, посвященного представителям рода мурзы Галишаха.

**Ключевые слова:** род мурзы Галишаха, С.Х. Алишев, исторический роман, ишаны, муллы.

Күренекле татар тарихчысы Сәлам Хатыйп улы Алишев мөселман өммәтендәге татар морзаларының язмышларына багышланган мәкаләсендә аларның, Россиядәге яңа иҗтимагый-сәяси шартларга яраклашып, бер өлеше – сәүдәгәр, икенче төркеме – руханилар, өченчеләре игенчеләр булып китүен шәрехләгән иде. Үзе морзалар нәселеннән булган галим мондый нәтиҗәне тарихи чыганакларны өйрәнеп кенә түгел, ә үз нәселнәсәбәтенең үткәнен дә яхшы белгән хәлдә ясаган икән.

2009 елның 24 мартында Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтында тарих фәннәре докторы Сәлам Хатыйп улының 80 еллык юбилее уңаеннан «XV–XIX гасырларда Урта Идел төбәге халыкларның тарихи язмышлары» исемле бөтенроссия фәнни практик-конференциясе уздырылган иде. Шушы фәнни чарада юбиляр «Галишаһ морза нәселе» исемле темага доклад укыды, һәм ул конференция материалларында басылып та чыкты. Әлеге доклад галимнең үз нәсел тарихына кагыла: «Мин үземнең шәҗәрәне төрлечә тикшереп карадым. Бер яктан Ш. Мәрҗани, Риза казый Фәхретдин язмалары, икенче яктан җир-йорт, җан исәбен алу язмалары (писцовые, переписные книги и ревизские сказки) белән чагыштырып карадым. Ш. Мәрҗани үзенең атаклы «Мөстәфадел–әхбар...» китабында бу шәҗәрәне Нигъмәтулла хәзрәттән башлый һәм аны Галишаһ – Галиш – Алиш морза белән тәмамлый. Галишаһны Ш. Мәрҗани Тау ягындагы (Дагстан яисә Җәбәлстан дип тә атаганнар) Шонгаты – Олы Әтрәч авылыннан ди. Олы Әтрәч XIV гасырда болгарларның әмирлек үзәге булган. Аңда Исан дигән әмир акча да суктырган. Безнеңчә шәҗәрә болай була: Галишаһ (җир-йорт исәбен алу кенәгәсе – «писцовая книга» буенча, XVI йөзнең икенче яртысы – XVII йөзнең беренче яртысы), аның улы Әлмәтулла (XVII гасырның беренче яртысы). Ул «болгар бабаларыбызның урынын яңадан үзләштерәм», дип Кама аръягына чыгып, Мораса елгасына Гәрәй суы кушылган җиргә каршы, хәзерге Иске Әлмәт авылын төзи... балалары Сөрмәт, Килка, Өрмәмеш, Нурмый була. Шулардан улы Сөрмәт (1620 елларда туып, шул гасыр ахырында үлә) Сәмәркәнд шәһәрендә укый, Коръән хафиз, ягъни Коръәнне яттан белүче була. Сөрмәт улы Ибраһим (1690–1780) – 1744 елгы сан алу буенча аның балалары: Хөсәен – 20, Җәгъфәр дигәне – 15, Зәйни – 12 яшьтә булалар. Җәгъфәр (1729–1796) – зур галим, китаплар авторы...».

Юбилейдан соң озакта үтми Сәлам Хатыйп улы нәсел-нәсәбәте хакында «Галишаһ морза нәселе» исемле китап тәмамлый. Аннан бер өзек «Петр Беренче заманы» исеме астында «Мәгариф» журналында (2009, №3) да дөнья күргән иде. Кульязманы нәшер итү төрле сәбәпләр белән тоткарланды һәм, ниһаять, узган ел бу әсәр басылып чыкты (Алишев С.Х. Галишах морза нәселе. Казан: Мәгариф – Вакыт, 2015. 559 б.). Сәлам Хатыйп улы 2015 елның 5 маенда фатирында миңа яңа гына «табадан төшкән» китабын бүләк итте. Олпат галимнең ул көнне минем белән бу дөньяда үз миссиясен үтәгән кеше буларак сөйләшкәнен мин бераз вакыттан соң гына аңладым. Озак та үтмәде, 2015 елның 23 июнь көнне, Сәлам Хатыйп улы вафат булды.

Жанры «роман-хроника» дип билгеләнгән китапта Галишаһ морза нәселе вәкилләренең Сәлам Алишевка алып килүче 10 буыны тасвирлана. Китап, беренче чиратта, шушы нәселдән чыккан күпсанлы милләтләшләребез өчен

зур бүләк (алар арасында Абдулла Алиш, журналист Илсөяр Сөнкишева һ.б. бар). Бер үк вакытта хезмәт татар тарихы белән кызыксынучылар өчен дә зур вакыйга. Биредә татар элитасына кергән ике төркем – морзаларның һәм руханиларның – көнкүреше, язмышы яктыртыла.

Шунысы мөһим, автор текстта борынгы бабаларыннан калган язмаларны, «авыл тарих»ларын, «нәсел тарихлар»ын, гарезнамәләрне, бәетләрне, халык иҗаты үрнәкләрен файдалана, халык санын алуга кагылышлы чыганаклар аңа күренекле нәсел вәкилләренең туган һәм үлгән, өйләнгән елларын, гаилә әгъзаларының санын, алар яшәгән авылларда өй-хуҗалык санын тергезергә мөмкинлек биргән.

Автор, тарихи чорларны исәпкә алып, әсәрен өч өлешкә (китапка) бүлгән. Беренче китапта XVI–XVII йөзләргә, икенчесендә XVIII гасырга, өченче китапта XIX йөз – XX гасырның беренче яртысына бәйле вакыйгалар бәян ителә.

С.Х. Алишев Галишаһ нәселе дәвамчыларының яшәешен, кылган гамәлләрен киң тарихи фонда яктыртырга омтыла һәм, әйтергә кирәк, бу алым уңышлы килеп чыккан. Уку барышында «нәсел тарихы» – «милләт тарихы» – «ил тарихы» чылбыры күз алдына килә.

Иң уңышлы, «маҗаралы» бүлек дип беренче китапны атау дөрес булыр. Вакыйгалар барышы тарихи әдәбиятта «болганчык заман» («смутное время») дип аталган XVII гасыр башы күренешләрен колачлый, Борис Годуновның хакимлекне саклап калу өчен көрәшен һәм рус хакимияте астында ярты гасыр яшәгән Тау ягы тормышын тасвирлый. Төбәктә тыныч түгел, шуңа күрә хакимият авылларда йогынтылы кешеләрнең балаларын әмәнәт (заложник) итеп кирмәннәрдә асрый, шулар аркылы халыкны үзенә буйсындыра. Китапта Зөя кирмәненә Борындык авылы мулласының гаиләсеннән әмәнәт итеп алынган һәм архимандрит тарафыннан чукындыруга ният ителгән, качып китеп, 1609–1611 елларда ихтилалны җитәкләгән һәм, аннары, исемен үзгәртеп, хакимияттән эзен җуйган Җангали Шөгеровка бәйле сюжет линиясе бирелә.

Үзләрен «болгар әмирләреннән» дип санаган Галишаһ морзага бәйле сюжет аның атасы Хәкимҗанның бабасы, Казан ханы Сафагәрәйгә каршы чыгып, аның белән килешмичә, Иван IV гә хезмәткә керүе һәм аңа рус патшасының Кострома шәһәрендә йорт һәм җир бирүе, шулай ук Олы Әтрәч авылы янында да җирләре булу турында сөйләүдән башланып китә. Хәкимҗан морза Кострома шәһәрендә, Урта Идел буеннан китертелгән йомышлы татарлар отряды җитәкчесе булырак, булачак патша Михаил Романовның гаиләсен саклый. Аның улы Галишаһ хакимиятнең Себер походларында, башка йомышлы татарлар белән бергәләп 1594 елда нигез салынган Тара шәһәрен төзүдә катнаша.

Галишаһка авыру әтисе белән тарихи ватанына, Олы Әтрәчкә кайтырга рөхсәтне кенәз Ф.И. Шереметьев бирә. Әтисенә

хезмәтләре өчен 500 дисәтинә җир биләргә хокук та бирелә. Галишаһ морзаның Олы Әтрәчтәге утары төбәк хакимиятенең филиалына әйләнеп, аның кул астындагы Тау ягы авылларында көн күргән 500 йомышлы хезмәт иткән. Галишаһның, морза булуына карамастан, рус хакимияте белән риза булмаган мөселманнар, шул исәптән качып йөрүче Җангали Шөгеров белән аралашуы, аның җитәкчелегендәге 1616 елгы йомышлы татарлар һәм ясаклылар баш күтәрүенә яшерен ярдәм күрсәтүе ул заман татар җәмгыятендә социаль каршылыкларның кискен булмавы, һәм төрле катлам вәкилләренең рус хакимиятенә карата карашлары шактый охшаш булуы турында сөйли.

Нәсел тарихын сурәтләүдә С.Х. Алишев тарихи мәгълүматларны уңышлы файдалана. Мәсәлән, 1646 елгы «Писцовая книга» буенча Казан шәһәрен һәм бистәләрен, биредә көн күрүчеләрнең кайсы сословие вәкилләре булуларын һәм кәсепләрен бик оста тасвирлый, Җангали җитәкчелегендәге ихтилалга бәйле воеводалар һәм башка чиновниклар язган рапортларны куллана.

Автор Галишаһ морзаның улы Әлмәтулланың бер төркем кешеләр белән Кама елгасының аргы ягында, «болгар бабалары» яшәгән урында, яңа авылга (Иске Әлмәт) нигез салып күченүе, йорт салу күренешләрен мавыктыргыч итеп сурәтләгән. Гомумән, китапта XVII гасыр татар морзаларының көнкүреше, туй йоласы, өйләнү күренешләре этнографик яктан да төгәл бирелүе белән игътибарны җәлеп итә.

Икенче һәм өченче китапларның төп геройлары – мөселман руханилары. Нәсел дәвамчылары халык арасында үзләренең югары дәрәҗәләрен саклыйлар – алар авыл муллалары булып китәләр, гыйлем туплау, игенчеләрнең балаларын укыту һәм тәрбияләү, ислам дине кануннарын пропагандалау һәм авыл халкының әхлагын саклау белән шөгыльләнәләр. Руханиларның көнкүреше авыл җәмгыяте кысаларында сурәтләнә. Шул сәбәпле, авылдагы булган вакыйгаларга игътибар бирелә. Менә авыл кешеләре илнең яңа башкаласын – Петербургны – төзергә ел саен 20 ир-атны эшкә җибәрәләр, 1718 елдан, лашманнар буларак, империя флотын төзү өчен урман кисә һәм чыгара башлыйлар, бу авыр эштән муллаларын гына азат итәләр. Шулай итеп, XVIII гасырның икенче чирегеннән Галишаһ оныклары түбән статуста – крестьян булып тормыш итә башлыйлар, халык аларга «чабаталы морза» дигән кушамат тага. Автор биредә дә тарихка экскурс ясый, XVIII гасырда Урал төбәгендәге ихтилаллар турында, хөкүмәтнең чукындыру сәясәте, лашманнарның дәүләт алдындагы бурыч-йөкләмәләре, дәүләт реформалары һ.б. вакыйгаларны бәян итә.

Морза нәселе вәкилләре руханилыкны да, дөньявилыкны да тигез алып барырга тырыша. Иске Әлмәт мулласы Ибраһимның (1690-1762) улы Җәгъфәр (1729–1796) яңа авылга нигез сала – Мораса елгасының уң ягына чыгып, Яңа Әлмәтне төзи,

авылдашларына яңа җирләр алуга ирешә. Гыйлемле гаиләдә тәрбияләнгән Җәгъфәрнең улы Гобәйдулла (1751–1823) Оренбург губернасының Каргалы (Сәет) бистәсендә атаклы мәдрәсәдә белем алып, Кизләү (Корманай) авылында мәдрәсә ачып, гыйлем иясе, ишан буларак дан ала, күпсанлы муллалар-мөритләр тәрбияли. Шулай итеп, XVIII гасырның икенче яртысында Галишаһ морза оныклары күренекле рухани-суфый буларак танылалар. Әсәрдә чапанлы Галишаһ оныкларының төбәктә руханилар кланнары формалаштыруда актив катнашулары, ул өйләндереп, кыз биреп, туганлык мөнәсәбәтләре урнаштыруы ассызыклана. Автор фикеренчә, муллаларның үзара берләшүе татар милләтенең оешуына зур ярдәм иткән (365 б.). Яңа Әлмәт авылы мишәрләренең 1828 елда беренче тапкыр Сабантуен уздырулары бу бәйрәмнең тарихи күренеш икәнен тагын бер кат раслый.

Китапта шәкертләрнең Казанның Күл буе мәдрәсәсендә укуларын, указ алгач, муллаларның тук һәм мәшәкатьле тормышларын оста сурәтләве дә игътибарга лаек.

С.Х. Алишев укучы игътибарын данлыклы Гобәйдулла ишанга түгел, ә Яңа Әлмәткә мулла итеп чакырылган аның улы Нигъмәтуллага (1775–1853) юнәлтә. Нигъмәтулла авыл мәктәбендә укыта, татар авылларында сирәк күренеш – мәхәлләнең җиләк-җимеш бакчасын булдыра. 1812 елда, Франция Россиягә каршы сугыш ачкач, Чистайда халык алдында мөселманнарны Ватанны саклаучы ополчениягә язылырга өндәп чыгыш ясый. Алдынгы карашлы мулланың халык арасында таралган «Бәрәңгенең файдасы» исемле кулъязмасы, мөселманнарны хакимиятнең яңа чарасына – 1840 нчы еллар башында мәҗбүри рәвештә авылларда бәрәңге утыртуга каршы ихтилалдан саклап кала. Чыннан да, бу шәхес күпләрнең игътибарын җәлеп иткән. Әйтик, йортында Казан губернаторы Боратынскийны кунак иткәндә ул үзенең карашлары турында болай дип сөйли: «Барлык диннәрне дә бергә кушылып, дөньяда бер генә дин булырга кирәк дигән уйны алга сөрәм... Төп ышаныч шулай булгач (халыкларның Алланы бер дип тануы. – *И.З.*), нигә башка төрле вак ышанычларны бергә тупламаска. Ләкин мондый фикер – ерак киләчәк эше. Икенче маддә моннан гыйбарәт. Кеше үзенең тууыннан алып табигате белән ерткыч түгел. Ә тормышта кайберәүләр, усалланып, кеше үтерүгә җитәләр яки икенче кешене кыерсыталар. Мин усаллыкны шәфкатьлелек белән җиңеп булыр дип уйлыйм. Җәбер, золым күрсәң, битараф бул, усаллыкны усаллык белән җиңеп булмый» (434 б.). Мулланың икенче фикеренең Нәкышбәндия тарикате тәгълиматенә тәңгәл килгәне күренә.

Автор дини тәгълиматка зур игътибар итми, шулай да Россия Госманлы дәүләте белән сугышкан елларда Нигъмәтулланың улы Хәйрулланың (?–1888) мөселман мөселман белән сугышырга һәм бер берсенең канын түгәргә тиеш түгел дип сөйләве

татарларны армиягә бармаска этәргән сәбәпләрнең берсе булгандыр дип әйтергә нигез бар.

Китапта вакыйгалар Хәйрулланың улы мулла Хатыйпның 1929 елда Сәләм исемле малае туу белән тәмамлана.

Профессиональ тарихчы-галимнең әдәби-тарихи китап язарга алынуы – зур кыюлык сорый торган адым. Чөнки иҗади фикер һәм язучының фантазиясе белән тарихи чынбарлык тәңгәл түгел, гадәттә, еш кына каршылыкка килә. Әйтергә кирәк, бу китапта галим һәм язучы фикерләре бер-берсен тулыландырып тора. Галишаһ морза нәселе дәвамчыларына багышланган тарихи әсәрнең уңышлы килеп чыгуының төп сәбәбе шундадыр.

***Заһидуллин Илдус Котдус улы,***
*тарих фәннәре докторы, Ш. Мәрҗани исем.*
*Тарих институтының яңа заман тарихы бүлеге мөдире.*
*zagik63@mail.ru*

# ӘХМӘТОВА ДИНӘ. ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ФОТОГРАФИЯЛӘРДӘ
## (Ахметова Дина. Габдулла Тукай в фотографиях)

Бөек шагыйрьнең 130 еллык юбилее Г. Тукай тормышы һәм иҗаты белән бәйле яңа фәнни тикшеренүләргә этәргеч бирде. Шуларның берсе –әлегә кадәр аз өйрәнелгән, Г. Тукайның исән чагында төшкән фоторәсемнәренә багышланган монографик басма дөнья күрде. Китапның авторы – ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИның тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре Д.И. Әхмәтова. XX гасыр башында татарлар арасында фотографиянең популярлашуы шул чордагы тарихи, иҗтимагый-сәяси, социаль-гуманитар факторлар йогынтысы астында барган мөһим үзгәрешләрне ачык аңларга ярдәм итә. Г. Тукай фотографияләре тарихы шул үзгәрешләрнең үзенә бер турыдан-туры чагылышы булып санала. Г. Тукай фотографияләренең тарихы фәкать бер генә дистә елны эченә ала, шулай да аларда шагыйрьнең Җаектагы чоры да, шөһрәт казанган еллары да, соңгы көннәре һәм, хәтта, соңгы сәгате, җирләү мәрасиме дә чагылган. Кызганычка каршы, аның төп нөсхәдәге фоторәсемнәре бик аз сакланган, әмма ул комплексны Г. Тукайның исән чагындагы һәм үлгәннән соң төшерелгән фотолары белән эшләнгән открыткалар, шулай ук төрле басмаларда нәшер ителгән рәсемнәре тулыландыра. Нәкъ менә шулар бөек татар шагыйрен безнең күз алдында дөрес итеп гәүдәләндергән кыйммәтле мирас булып саналалар.

Тикшеренүче галимә шагыйрь фотосурәтләренең тулы җыелмасын өйрәнүне, фоторәсемнәрнең авторларын ачыклауны, кирәк урында өстәмә атрибуцияләр уздыруны бурыч итеп куйган.

Г. Тукай фотографияләрен караганда, аны исән чагында фотога төшергән фотографларның да эшчәнлеген игътибарсыз калдыра алмыйсың. Алар – В.П. Онуфриев (Җаек), С.И. Иванов һәм И.М. Якобсон (Казан), И.М. Бочкарев (Әстерхан). Китап авторы фотога төшерү осталарының биографияләрен яктыртырга, алар эшләгән фотоательларның адресларын күрсәтергә омтыла, чөнки алар барысы да Г. Тукай белән, аның эзләре белән бәйле истәлек. Әлегә кадәр Г. Тукай фотографияләренең авторлары тикшеренүчеләр игътибарыннан читтә кала килде, шуңа күрә, ниһаять тә авторлык темасының күтәрелүен хупларга гына кала. Бу юнәлештә тикшеренүче кызыклы гына нәтиҗәләр ясый. Шагыйрь язмышындагы мөһим мизгелләрне визуаль чагылдыруда Казан фотографы Иосиф Мееровnatural Якобсонның роле зур әһәмияткә ия, аның Г. Тукай гомеренең соңгы елларында эшләгән (ассызыклап әйткәндә, һәркемгә мәгълүм, аеруча киң таралган) портертлары тулы бер серия тәшкил итә.

Шагыйрь гомеренең Клячкин хастаханәсендәге соңгы сәгатьләре, шулай ук үлгәннән соңгы маскасы һәм Г. Тукайны җирләү мизгелләре аның тарафыннан гәүдәләндерелә, алар открытка рәвешендә таратылалар. Боларны фотографның шагыйрьнең үзе белән дә, аның дуслары һәм наширләр белән дә тулы мәгънәсендәге эшлекле хезмәттәшлеге дип атарга мөмкин. Тикшеренүче визуаль анализ нигезендә киң таралган кайбер фотографияләрне яңача атрибутлаштыра. Әйтик, Г. Тукайның Ф. Әмирхан белән парлап төшкән, шулай ук, сакланып калган фрагментлардан чыгып, Ф. Әмирхан һәм бертуган Коләхмәтовлар белән төшкән фотоларны, ышандырырлык анализлар ярдәмендә, 1911 елда И.М. Якобсон тарафыннан эшләнгән булуы ихтимал дигән нәтиҗәгә килә.

Г. Тукай фотолары тарихында Әстерхан остасы, җирле татарларның этнографик фотолары белән танылып өлгергән Иван Митрофанович Бочкаревның һәрьяклап катнашуы да кызыклы күренеш. Бочкарев Г. Тукай поэзиясе сюжетлары буенча аларны сәхнәләштерүгә көйләнгән фоторәсемнәр сериясен эшли. Аларның кыйммәте шунда, автор, визуаль чыганакларны өйрәнүдән тыш, шуларга охшаш мемуар чыганакларны да файдаланып, фототарихның чикләрен киңәйтә һәм гәүдәләнешен җанландыра.

Автор Г. Тукайның һәркемгә мәгълүм барлык сурәтләрен дә барлауны үзенә бурыч итеп куя, һәм шуңа ирешә дә, ул сакланып калган фоторәсемнәрнең оригиналларын гына түгел, төп нөсхәсе сакланмаган фотоларның күчермәләрен дә өйрәнеп тикшерә. Эш барышында кулына килеп кергән фотографияләрне хронологик тәртиптә урнаштыра, шулай ук тематик яктан һәм авторлары буенча төркемнәргә аера, сәнгати күзлектән чыгып тасвирламалар бирә.

Г. Тукайның баштагы фотографияләре аның Җаектагы мәдрәсә тормышын һәм анда укуын чагылдыра. Анда ул үзенең дусты, булачак актер Габдулла Кариев белән таныша, шулай ук мәдрәсә укытучысы Камил Мотыйгый-Төхвәтуллин белән тыгыз хезмәттәшлек итә. Г. Тукайның Җаектагы иптәшләре арасында төшкән фотографиясе шагыйрьнең анда аралашып яшәгән даирәсен күзалларга ярдәм итә. Г. Тукайның печатник (типография эшчесе) булып эшләгәндә төшкән фотографиясе яшь шагыйрь биләгән социаль позициянең ачык чагылышы.

Казан фотографияләре – болары инде шагыйрь кичергән эволюцияләрне сурәтли. «Әлислах» газетасы редколлегиясе әгъзалары белән төркемләп төшкән фотографиядә Г. Тукайның Казан әдәбиятчылары арасында тарсынып торуы сизелсә, ә 1908 елда төшкән фотосында Г. Тукайның әдәби мохиттәге урыны үзгәргән – ул инде дәрәҗә казанган мәһабәт кыяфәттә. Шунысы да мәгълүм, аның бу портреты наширләр заказы буенча эшләнгән һәм китап, журналлар тышлыгын бизәгән, аерым открытка булып та басылган. Шуннан соңгы биш ел

дәвамында Г. Тукайның мондый кыяфәттәге портретлары берничә тапкыр эшләнә, аларның кайберләре төрле нәшриятларның милкен тәшкил итә, һәм бу – әлеге сурәтләрнең коммерция максатларында эшләнүе хакында сөйли.

Г. Тукайның дуслары – шагыйрьләр, язучылар, наширләр белән төшкән фотографияләре дә кызыклы гына. Бик үк рәсми булмасалар да, ул рәсемнәр шагыйрьнең аралашкан даирәсе һәм үзе якын күргән затлар хакында сөйли. Һәм, мөгаен, алар арасыннан күңелне иң дулкынландырганы әдипнең дусты Фатыйх Әмирхан белән төшкән фоторәсемедер.

Г. Тукайның өч фотосы аның Санкт-Петербургка Әстерханга баруы белән бәйле.

Шагыйрьнең соңгы фоторәсеме Г. Клячкин хастаханәсендә вафатына бер көн кала эшләнгән, аны соңгы юлга да шушы хастаханәдән озаталар. Г. Тукайны җирләү мәрасимендә бик күп кеше катнаша, бу күренешләр дә фотографияләрдә мәңгеләштерелгән.

Монографиядә шулай ук визуаль рәвештә һәм мемуар чыганаклар ярдәмендә шагыйрьнең килеш-килбәтендәге үзгәрешләр, аның тышкы киемгә, чәч йөртү манерасына игътибар итүе, социаль статусы үзгәрү (мәдрәсә шәкертеннән башлап, гадәттән тыш популяр, киң танылуга ирешкән шагыйрь, татар милләтенең кумиры) киң чагылыш тапкан, әлегә кадәр Г. Тукай тормышы яктыртылган хезмәтләрдә боларга беркайчан да әһәмият бирелмәде. Фотографияләр, визуаль документ буларак, Г. Тукай тормышын ике төрле кабул итүгә этәрәләр иде: берсе – аның реаль тормышы; икенчесе – үзе исән чакта ук шагыйрьне мифик образ итеп күзаллау, шулай ук аның тарихын коммерция максатлары белән бәйләү.

Бөек шагыйрьнең фотографик тарихы яңа юллар, яңа фактлар белән баетылган, шунсыз бу тикшеренү тулы булмас иде. Мәсәлән, Кәбир Бакирның «Тукай Петербургта» (1914) дигән китабы тышлыгында, Г. Тукайның билгесез бер сурәте урнаштырылган була, бу хезмәттә ул беренче мәртәбә басыла. Монда Г. Тукайны җирләү мәрасимендә төшерелгән билгесез бер фото да урын алган. Шулай ук Г. Тукайның Клячкин хастаханәсендә әле исән вакытында төшереп алынган, әмма ерткаланган фоторәсеме дә беренче мәртәбә шушы хезмәттә тәкъдим ителә. Бу фоторәсем шагыйрьнең башка фотографияләренең оригиналлары, 1913 елда эшләнгән почта открыткасындагы һәм 1927 елда журналда басылган фоторәсемнәре ярдәмендә нөсхә хәленә китерелгән. Г. Тукайның соңгы фотографиясеннән, коммерция максаты белән, шагыйрьнең дуслары кисеп алынган һәм әлеге фотографик документның бөтенлеге югалган була.

Басманың полиграфик эшләнеше ягыннан җитешсезлекләре дә шактый, әйтик, китапның бизәлеше бик үк сыйфатлы түгел, иллюстрацияләр бик вак, бу – шагыйрьнең фотографияләре белән тулы итеп танышуны кыенлаштыра.

Гомумән алганда, тикшеренүче үзе хаклы рәвештә билгеләп

үткәнчә, Г. Тукайның тормышы һәм үлеме белән бәйле күп нәрсә мөселман мәдәниятен кабул итүнең традицион чикләрен киңәйтә. Шагыйрьнең исән чагында төшкән фоторәсемнәре, аларның басма һәм коммерцион язмышлары, Г. Тукайның хастаханә палатасында үлем түшәгендә яткандагы фото-рәсемнәре, мәетнең йөзе, үлгәч алынган маскасы милли даирәдә формалашкан аңның һәм гадәтләрнең традицион стереотипларн шактый җимерде. Шагыйрь Габдулла Тукай кыска гына гомерендә дә, үзе исән чакта ук, чиксез зур танылу яулап өлгерде. «Тукай в фотографиях» дигән әлеге фәнни басмада гаҗәеп шәхес, тарихи һәм әдәби феномен тулы итеп, яңа ракурста ачыла.

***Рәмиев Зөфәр Зәйни улы,***
*филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге баш фәнни хезмәткәре*

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИЛЛИ МУЗЕЕ БАСМАЛАРЫНА РЕЦЕНЗИЯ

**1. «Окна» Победы. Каталог коллекции плакатов «Окна сатиры» 1941–1945 гг. Национального музея Республики Татарстан / Авт.-сост. В.В. Иванова, Н.В. Фомина. – Казан: Заман, 2012. – 136 с.: ил.;**

**2. Плакаты Победы. Каталог коллекции плакатов, изданных в Казани в годы Великой Отечественной войны 1941–1945 гг., из собрания Национального музея Республики Татарстан / Авт.-сост. В.В. Иванова, Н.В. Фомина. – Казань: Заман, 2014. – 72 с.: ил.**

Татарстан Республикасы Милли музееның киң күләмле тасвирый материаллар фондының бер өлешен тәшкил иткән, Бөек Ватан сугышы елларында Татарстанда эшләнгән плакатларның рецензияләнгән бу ике басмасы да киң катлау кызыксынучылар өчен аз билгеле, әмма алар бик зур әһәмияткә ия хезмәтләр.

Беренче басма Мәскәүдә нәшер ителгән «Окна ТАСС» «Окна сатиры» дип аталган һәм «Татхудожник» берләшмәсе бастырып чыгарган плакатларга багышланган. Республиканың әйдәп баручы рәссамнары Н.М. Сокольский, И.Е. Бобровицкий, Э.Б. Гельмс, А.Н. Кашаев һ.б., Казанның танылган шагыйрьләре Б.И. Зернитов, А.Г. Бендецкий һ.б. белән бергәләп, сугышның беренче көннәрендә үк, фронттагы һәм тылдагы мөһим вакыйгаларга җәһәт рәвештә мөнәсәбәтләрен белдереп, шушы плакатларны чыгарганнар. Алар трафарет басма техникасында эшләнгәннәр, тиражлары 300 данәдән артмаган.

Икенче басма шул ук теманы дәвам итеп, асылда, Татар дәүләт нәшрияты, ТАСС Эчке эшләр халык комиссариатының Казан шәһәр янгыннан саклау бүлеге һәм СССР Сәламәтлекне саклау Халык комиссариаты Медгизы тарафыннан күпмеңле тиражлар белән Казандагы типографияләрдә – Ташполиграфта, К. Якуб исемендәге китап фабрикасында типографик ысул ярдәмендә каталогта Мәскәүнең күренекле осталары Д.С. Моор, В.Н. Дени һ.б.ның татарчага тәрҗемә ителеп Казанда чыгарлыган плакатлары бирелгән. Танылган татар рәссамнары Б.М. Альменов, Р.Ф. Сәйфуллина һ.б.ның басып алучыларга көрәшкә, тылда фидкарь хезмәткә, фашистларның мәкерлеген һәм ерткычлыгын фаш итүдә уяулыкка чакырган, совет кешеләренең батырлыгын данлаган үзенчәлекле рәсемнәре буенча эшләнгән плакатлар аеруча кызыксыну уята һәм ул җыентыкның кыйммәтен көчәйтә.

Ике басма да фәннилек һәм популярлык белән сугарылган. Барлык плакатларның да фәнни тасвирламасы бар, рәссамнарның биографияләрен, автор текстларын, библиографияләрне эченә алган белешмәләр аппараты урын алган. Кереш мәкаләләрдә сугыш чорында плакатлар нәшер итү буенча Республика эшчәнлеге-

нең төп этаплары, рәссамнар эше спецификасы, хәрби плакатлар коллекциясен саклауда һәм популярлаштыруда музейның роле ачыклана. Әлеге басмаларның мөһим үзенчәлеге шунда, барлык плакатлар да югары полиграфик сыйфат белән эшләнгән; бу аларның музейдагы сугыш елларына багышланып, 1940 һәм 1960 елларда басылып чыккан башка басмалардан сыйфат ягыннан күпкә югары булуын раслый.

Рецензияләнгән басма музей хезмәткәрләре – ТР ММ тасвирый һәм документаль бүлеге мөдире Н.В. Фомина белән ТР ММ Татарстан тарихы һәм мәдәнияте бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре В.В. Ивmanaged күпьеллык фәнни-тикшеренү һәм саклаучылык эшләре нәтиҗәсе булып тора. Басмаларның фәнни яктан югары дәрәҗәдә башкарылуы ТР ММ генераль директоры тарих фәннәре докторы Г.Р. Нәҗипова һәм аның фәнни-тикшеренү эшләре буенча урынбасары С.Ю. Измайлова җитәкчелегендәг редакцион коллегия эшчәнлеге белән дә бәяләнә. Полиграфик яктан сыйфатлы булуы – күп еллар дәвамында музей һәм сәнгать әсәрләре бастыру буенча специальләшкән «заман» нәшрияты коллективы тырышлыгы нәтиҗәсе.

ТР Милли музее тупланмасындагы сугыш еллары плакатларынынң 2012 һәм 2014 елларда нәшер ителгән каталогы бүгенге тарихи шартларда илебездәге плакатлар сәнгатен өйрәнүдә һәм популярлаштыруда, фашизмга каршы совет пропагандасын өйрәнүдә әһәмиятен торган саен арттыра бара.

***Улемнова Ольга Львовна,***
*сәнгать фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының тасвирый һәм декоратив-гамәли сәнгать бүлеге әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

**30 с**ентябрьдә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең 25 еллыгына багышланган тантаналы җыелыш булып узды. Тантанада Татарстан Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев тә катнашты. Ул үз чыгышында Татарстан Фәннәр академиясен бәйрәм белән котлап: «Без республика үсешен булдыра алабыз, әмма фәнни-техник алгарыштан, инновацияләрне гамәлгә кертүдән һәм фәнни көчләрдән башка бу хакта уйлау да мөмкин түгел. 25 ел – матур юбилей. Бу еллар эчендә күпме кыю карарлар кабул ителде һәм берсе дә отышсыз булмады», диде һәм 14 ел Татарстан фәннәр академиясен җитәкләгән академик Мансур Хәсәновны зур хөрмәт белән искә алып, Фәннәр академиясе президиумының аның исемен мәңгеләштерү турындагы тәкъдим белән чыгуын әйтте. Шулай ук ТР мәгариф һәм фән министры Энгель Фаттахов, Россия фәннәр академиясе вице-президенты Талия Хәбриева, югары уку йортлары, фәнни оешма җитәкчеләре, Абхазия, Азәрбайҗан, Кыргызстан, Румыния, Төрекмәнстан һәм башка илләрнең фәннәр академияләре вәкилләре дә үзләренең котлауларын җиткерделәр.

Тантанада ТР Фәннәр академиясенең күренекле хезмәткәрләренә дәүләт бүләкләре тапшырылды.

**11 октябрьдә** Ашхабадта Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов Төрекмәнстан Президенты Корбангулы Бердымөхәммәдов белән очрашты. Бу очрашуда ТР ФА президенты М. Сәлахов та катнашты. Р. Миңнеханов сәламләү сүзендә Төрекмәнстанның бәйсезлек алуына 25 ел тулу уңаеннан котлап, татарстанлылар исеменнән иң җылы теләкләр ирештерде, Татарстан һәм Төрекмәнстан Республикалары арасында күркәм мөнәсәбәтләрнең урнашуы икътисад, мәгариф һәм мәдәни багланышларны үстерү җәһәтеннән дә мөһим икәнен ассызыклады. Корбангулы Бердымөхәммәдов: «Халыкларыбыз арасында уртаклыклар күп – тел, дин, милли традицияләр. Бүгенге буынның тугандаш мөнәсәбәтләрне саклап калуы һәм дәвам иттерүе күңелдә канәгатьлек хисләре тудыра», – дип билгеләп үтте. Ике яклы әлеге очрашуда Татарстан һәм Төрекмәнстан Республикасы Фәннәр академиясе президентлары М. Салаһов һәм М. Ашырбаев та фәнни-техник хезмәттәшлек турындагы меморандумга кул куйдылар.

**24 октябрьдә** Казан Кремленең «Манеж» күргәзмәләр залында «Тукайга сәяхәт» дип исемләнгән күргәзмә ачылды. Күргәзмә Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Казан Кремле» дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы, ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән берлектә хәзерләнде. Проект партнерлары арасында Россия Дәүләт тарих архивы, Татарстан Республикасы Милли музее,Татарстан Республикасы Дәүләт архивы,Татарстан Республикасының Милли китапханәсе, РФА Казан фәнни үзәге, Казан федераль университетының

Н.И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе дә бар.

Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулуга багышланган әлеге күргәзмәне ачу тантанасында катнашкан ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин аның Татарстанның мәдәни тормышында зур һәм мөһим вакыйга булуын билгеләп үтте. «Казан Кремле» музей-тыюлыгы директоры Зилә Вәлиева: «Тукай безгә зур мирас – татар теленең энциклопедиясен калдырып китте. Монда сез Тукайның шәхси әйберләрен күрә аласыз. Алар күп түгел, әмма кызыклы» дип, эчтәлекле күргәзмәне булдыруда өлешен кертүчеләргә рәхмәтен белдерде. ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры К.М. Миңнуллин Кулъязмалар һәм музыкаль мирас үзәгендә сакланган Тукай фондының туплану тарихы, шагыйрь мирасын барлау юлында эшләнгән эшләр хакында аерым тукталды, Г. Тукайның алты томлы академик басмасы дөнья күрүен һәм Тукай энциклопедиясе белән дә тиздән укучыларның таныша алачагын әйтеп узды.

Күргәзмәдә шагыйрьнең кулъязмалары, шәхси әйберләре, Тукайның Анна Ахматова тарафыннан тәрҗемә ителгән шигырьләренең төп нөсхәләре, Тукай үзе исән вакытта басылып чыккан 33 китабы һ.б. үзенчәлекле экспонатлар урын алган. Шулай ук монда шагыйрьнең шәхси әйберләрен дә күрергә мөмкин.

«Тукайга сәяхәт» күргәзмәсе бу елның 22 декабренә кадәр эшләячәк.

**19 октябрьдә** КФУның Филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институтында А. Гыйләҗевнең (1928–2002) «Аргамак» журналы битләрендә урын алган «Давайте помолимся!» романын тәкъдим итү кичәсендә язучы белән бергә ГУЛАГ михнәтләрен узган тәрҗемәче, рәссам венгерлы Арпад Галгоци белән очрашу да булды.

Арпад Галгоци – Аяз Гыйләҗевнең сәяси тоткынлыкта үткәргән алты елга якын гомеренә багышланган «Йәгез, бер дога!» исемле романының герое. Аның турында беренче тапкыр быел татар җәмәгатьчелеге Аяз Гыйләҗев иҗатын өйрәнүче галимә, Казан федераль университетының татар әдәбияты кафедрасы доценты Миләүшә Хабетдинова аша белгән иде. Аяз Гыйләҗевнең туксанынчы еллар башында язып тәмамлаган һәм тәүге тапкыр 1993 елда «Казан утлары» журналында дөнья күргән «Йәгез, бер дога!» исемле романы рус теленә тәрҗемә ителгән. Әсәрнең беренче һәм икенче бүлекләре «Аргамак» журналында басылып чыкты, киләсе елда романның китап булып чыгуы көтелә.

**19 октябрьдә** Казан федераль университетында барган «Державин укулары» XII Бөтенроссия фәнни-гамәли конференциясе үз эшен төгәлләде. Конференциядә хакимият структурасы һәм төрле иҗтимагый оешма вәкилләре, галимнәр һәм Россиянең 25 югары уку йортыннан килгән студентлар, магистрантлар катнашты.

Конференциядә катнашучыларның фәнни кызыксынуы Россия хокук системасының барлык спектрларын да колачлый, шуңа күрә укылган докладларда терроризм куркынычы, наркоҗинаятьчелек,

коррупция, балалар һәм үсмерләр белән бәйле җинаятьләр – балигъ булмаганнар кылган җинаятьләр, чит илләр гражданнары тарафыннан Россия балаларын балалыкка алу кебек глобаль темалар яктыртылды. Бөтенроссия дәүләт юстиция университеты ректоры Ольга Александрова конференциянең йомгаклау утырышында Укуларның кабул ителгән резолюциясен дә яңгыратты.

**3 ноябрьдә** «Казан Кремле» музей-тыюлыгында урнашкан Татарстан Республикасы дәүләтчелеге тарихы музеенда «Татар мәдәнияте коды: беренче татар театрына 110 ел» күргәзмәсе ачылды. Күргәзмә ачылу тантанасын Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артистлары Наилә Гәрәева, Ренат Таҗетдинов, Луара Шакирҗанова, Әзһәр Шакиров иҗади кичә рәвешендә алып бардылар. «Казан Кремле» музей-тыюлыгында Татарстан Республикасы һәм татар халкы дәүләтчелеге тарихы музееның житәкчесе Мария Давытова күргәзмәгә әзерлекнең май аенда ук башлануын, үзенең хезмәт эшчәнлеге дәверендә иң кызыклыларыннан берсе булуын җиткерә: «Биредә Сәхибҗамал Гыйззатуллина-Волжская, Ильясбәк Кудашев-Ашказарский һ.б. шәхесләргә кагылышлы уникаль экспонатлар тупланган», – ди ул.

Күргәзмә 110 еллык тарихы булган, миллионлаган тамашачысының мәхәббәтен, башка милләт вәкилләренең чиксез хөрмәтен һәм соклануын яулаган мәдәни мирасыбыз – театрыбызның үсешен күзалларга ярдәм итә.

Биредә театр белән бәйле архив документлары, спектакль афишалары, буклет һәм программалар, костюмнар, декорация сызымнары, фотографияләр белән танышырга мөмкин. Шулай ук К. Тинчурин, Г. Камал, Г. Кариев һ.б.ларның шәхси әйберләре күргәзмәнең кызыклы өлешен тәшкил итә.

Күргәзмәне Г. Камал театры Татарстан Республикасы Дәүләт архивы белән берлектә оештырган. Анда Татарстан Милли музее һәм КФУның Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе материаллары файдаланылган.

Научное издание

**НАУЧНЫЙ ТАТАРСТАН**
На татарском языке

Фәнни басма

**ФӘННИ ТАТАРСТАН**
2016. № 4

Бизәлеш авторы – Э. Бәшәрова
Компьютерда биткә салучы – Н. Абдуллина

Басарга кул куелды: 18.11.2016.
Офсет ысулы белән басыла. Гарнитура «Times».
Кәгазь форматы 70×108 1/16.
Басма табак 11,25. Тираж 500. Заказ

Журнал Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында әзерләнде

Редакция адресы:
420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31
«Фәнни Татарстан» журналы редакциясе
Тел. (843) 292-76-59, 292-71-80
E-mail: f_tatarstan@mail.ru

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты
420111, Казан шәһ., Бауман ур., 20